PRESSA.RU

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№6 (294) – ИЮНЬ 2016

ТАТАРСТАН

1920 елдан нәшер ителә

KazanSummit: Шәрык һәм Гареб очрашкан урын

Илһам дәвере

Казан борынгырак түгелме?

БАЛАЧАКНЫ БӘХЕТЛЕРӘК ИТИК

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Рөстәм Шакиров
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Владимир Матылицкий
Татьяна Колчина
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская, bond@tatmedia.com
Авторлар: Катерина Котова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыктагы фото: Ната Смирнова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ №ФС77-37630, 01.10.2009.

Тираж: 3500 данә, шул исәптән татар телендә – 1100.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-1442

Басарга кул куелды: 17.06.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com, тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Айваз Диндаров, aivazid@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КОЯШ ҮЗЕБЕЗДӘ ЧАКТА

Безнең географик киңлектә җәй – һәрчак бәйрәм ул. Чынлыкта хезмәт бәйрәме булса да Татарстан басуларында эшнең гөрләп барган вакыты. Ә бит кояш яктыртып кына түгел, ә нәкъ менә курорттагы кебек, җылытып та торганда, эш тә дәртлерәк бара, күңел ачуы да күңеллерәк. Хәтта үзебездә дә. Хәтта кичләрен һәм ялларда гына тәтесә дә ул ял. Хәтта отпускта булмасак та. Чөнки, җәй ул шулкадәр көтеп алынган фасыл, ләззәтен вә ямен берни боза алмый. Бу елда алагаем булып буй үстереп алган озынборыннар да хәтта. Җәйгә чыккач, традициягә әйләнгән кайнар суны ябып кую йоласы да, кайберәүләр әле кинәнә ала – аларда ябып өлгермәгәннәр. Яшәү рәхәт, кыш кайдадыр ерак-еракта – Лениногорск таулары аръягында, җәй әле бар хозурлыгында ачылып кына килә! Әйдәгез, аның, газизебезнең, кадерен белик: озын-озак кышкы кичләрдә, без, ниһаять, ялга җыенып, дөньяның икенче бер читенә качкан кояшны шунда барып күзәнәкләребезгә сеңдерергә мәҗбүр булгач та, үзебездәге бу хозурлыкны сагынып искә алырлык булсын. Бездән әле җиңел генә берәүнең дә качып котылганы юк! Куып та тотарбыз, узып та китәрбез!

ҖӘЙДӘН ИЗРӘГӘН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы: «Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче: «Татмедиа» АҖ

420097, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
892 сум 32 тиен

АРЧА. САБАНТУЙ

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Ишегалды ишегалдына. Безнең урам спортчылары кайда җыела?

10. Шәрык белән Гареб очрашкан урын. KazanSammit-2016 – ислам банкингының Россиядәге перспективалары турында

16. Иң югары рухият. Болгар ислам академиясе кемнәрне әзерләячәк

20. Татарстан WorldSkills Russia ярышларында. Бронзаның алтыннан кадерлерәк чагы

24. Акылны эшкә җигәргә. «Студент»-җитәкчеләрне нәрсәгә өйрәтәләр

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

36. Илһам дәвере. «Татар сандугачы» Ростроповичны ничек тәэсирләндергән

38. Нефть фронтында җиңү. СССР картасында «икенче Баку» ничек пәйда булган?

40. Елга буйлап. Татарстан шәһәрләрен нинди яр буйлары бизәячәк

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

52. Татар чәй ашлары. Авылда кунакта.

56. Тарих сәхифәләре. Казан борынгырак түгелме?

60. Индус Таһиров: «Дәүләт үз халкы белән татарча сөйләшергә тиеш»

66. Кирәксез балалар. Аларны ничек бәхетле итәргә?

72. Ник Вуйчич фикерләре. Иң шәп кешеләр ни өчен топ-модельләргә охшамаган

74. Без барыбыз да балачактан. Өч сүз эченә сыйган балачак

76. Китап киштәсе. Укырга яратучы гаиләләр кайда яши

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

27.05

Владимир Путин, РФ Президенты, – «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме утырышында катнашучыларны сәламләп:

– «Ислам дөньясының Россия йөзендә һәрвакыт глобаль каршылыкларга һәм янауларга каршы торуда ярдәм итәргә, мөһим проблемаларны хәл иткәндә теләктәшлек күрсәтергә әзер булган ышанычлы дус һәм союзник табачагына басым ясап әйтәсем килә».

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

20.05

Олег Морозов, Татарстаннан Федерация Советы әгъзасы, – KazanSummit 2016да:

– «Дөнья шулкадәр төрле, үз элемтәләреңне традицион партнёрлар белән генә чикләү – дөрес түгел. Партнёрлык банкингы – бу үзара мөнәсәбәтләрнең махсус системасы. Һәм Татарстанның үзен Россия белән ислам финанс дөньясы арасындагы үзара мөнәсәбәтләр темасын тикшерү мәйданчыгы итеп тәкъдим итүе, һичшиксез, әһәмиятле вакыйга».

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.05

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Казан Сабантуенда:

– «Сабантуй күптән республика чикләрен үтеп чыкты, ул Россиянең 57 төбәгендә һәм дөньяның 27 илендә үткәрелә. Ул инде татар бәйрәме генә түгел – ул халыкларны берләштерә».

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Безнең урам спортчылары **КАЙДА** җыела

Ислам академиясе **КАЙЧАН** эшли башлаячак

Илебездә иң яхшы таш шомартучы **КЕМ**

«Студент»-җитәкчеләрне **НӘРСӘГӘ** өйрәтәләр

PRESSA.RU

Автор:
Айдар Сәгъдиев

КАНДИДАТЛЫК МИНИМУМЫ

«Бердәм Россия»нең булып узган праймеризына нәтиҗә ясап, аны күзәтүчеләр дә, партия әгъзалары үзләре дә бу масштаблы һәм моңарчы күрелмәгән ачык акция булды, дигән уртак фикергә килделәр.

Асылда, ул шулай булырлык итеп оештырылган да иде. Бүгенге икътисадый шартларда һәм елның төп сәяси вакыйгасы – сентябрьдә узачак РФ Дәүләт Думасына сайлау алдыннан «бердәмроссия»леләр, электоратның мөмкин кадәр зуррак өлешенең ихтыяҗларын истә тоткан хәлдә, үз көн тәртипләрен сынарга, һәм, әлбәттә, праймеризның төп максаты – сайлау алдыннан партиянең төп «физик затларын» карау мөмкинлегеннән файдаланырга карар кылдылар.

Бу җәһәттән «Бердәм Россия» башкалардан аерылып тора – ул үзенең «кандидатларга кандидатларын» партия әгъзалары яки, әйтик, махсус сайлаучылар фикере буенча гына түгел, ә барлык гражданнар фикеренә таянган хәлдә сайлаган бердәнбер партия булып чыкты (шуны әйтеп үтик: бу юлы үз кандидатларын сайлау процедурасын демократизацияләргә карар кылган Россиянең тагын бер партиясе үзенең алдан тавыш бирүен ябык рәвештә уздырды).

Әмма, билгеле булганча, игълан итү генә аз әле – сайлау участогында тавыш бирү мөмкинлегеннән тыш, агитация кампаниясенә карата кызыксынуны тәэмин итү дә мөһим. Моның өчен теләгән һәр кешегә «үз» кандидатын табарга мөмкинлек бирә торган ачык көндәшлек мәйданчыгы булдыру кирәк иде. Ул төрле ысуллар белән – праймеризда катнашучыларның Татарстан шәһәр һәм районнарында сайлаучылар белән очрашуы (аларның саны 500дән артып китте), агитация материалларын тарату, ике каналда оешырылган туры эфирда һәм язмада карау мөмкинлеге булдырылган дебатлар һәм теледебатлар аша тормышка ашырылды.

Ә иң кызыгы: фикер алышуның сыйфатына да зыян килмәде. Бу бигрәк тә дебатларны уздыру дәрәҗәсендә күренде – кандидатларның «мин шундый, моны яхшы эшлим» моделе буенча чыгыш ясаулары кимеде, күтәреп чыккан мәсьәләләр һәм бәхәсләшү мөмкинлеге артты. Тыелган темалар булмады, ә менә сәнәгать һәм авыл хуҗалыгын, импортны алыштыру, социаль тармак, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча тәнкыйди һәм эшлекле тәкъдимнәр шактый яңгырады. Мондый ачык фикер алышуны, чынлыкта, илдә инде күптән көттеләр. Мөгаен, «бердәмроссия»леләр моны сизеп алганнар һәм мондый очракта сәяси партиягә үз эчендә генә кайнау үлем белән бер булуын аңлаганнар.

Шуңа күрә 22 майда булып узган йомгаклау тавыш бирүенә халык тарафыннан кызыксыну шактый югары булды. Тавыш бирү өчен сайлау

Фото: Ната Смирнова

участокларына 440 мең татарстанлы килде, килү дәрәҗәсе 14,99 процент (Россия буенча уртача алганда – 9,5 процент) тәшкил итте. Татарстанда

Тыелган темалар булмады, ә менә сәнәгать һәм авыл хуҗалыгын, импортны алыштыру, социаль тармак, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча тәнкыйди һәм эшлекле тәкъдимнәр шактый яңгырады.

федераль оештыру комитеты тарафыннан бүлеп бирелгән барлык бюллетеньнәр дә кулланылды.

Праймериз нәтиҗәләрен ясау сюрпризлар алып килмәде. Алты бер мандатлы округның бишесендә тавыш бирү лидерлары булып РФ Дәүләт Думасының хәзерге депутатлары торды. Федераль исемлек буенча җиңүче булып вице-премьер, ТР авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов калды, ә исемлекнең беренче унлыгында без РФ Дәүләт Думасының хәзерге дүрт депутатын һәм республикада билгеле булган башка кешеләрне күрә алабыз. Праймеризга барлыгы 81 катнашучы (шул исәптән партиясезләр дә) гариза биргән булган, һәм, әлбәттә, аларның күбесе Дума сайлауларында «Бердәм Россия»дән кандидат булып тәкъдим итүгә өметләнә алмый. Шулай да, әлеге тәҗрибә партия өчен дә, кешеләрнең үзләре өчен дә файдага гына, дип саный «Бердәм Россия»нең Татарстан бүлеге сәркатибе, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. «Без барлык катнашучыларга да рәхмәтле һәм күптөрле эшлекле һәм файдалы тәкъдимнәр җыя алу мөмкинлегенә шатбыз, – диде ул, алдан тавыш бирүгә нәтиҗә ясап. – Аларның Татарстан халкы ихтыяҗларына кагылган иң төпле, чынбарлыкка якыннарын партия программасына кертергә һәм тормышка ашырырга тырышачакбыз. Без биредә бик күп яңа кызыклы кешеләрне күрдек. Һәм аларның да күбесе безгә, барыннан да бигрәк, фикер әйтергә мөмкинлек биргәнебез өчен рәхмәтле».

Алдан тавыш бирүнең соңгы нәтиҗәләрен июнь азагында узачак «Бердәм Россия» съезды раслаячак. Шунда ук РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидатларның исемнәре дә мәгълүм булачак.

«La Primavera» праймеризга музыкаль флешмоб белән ярдәм итте.

Андрей Большаков, КФУ Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институтының конфликтология кафедрасы мөдире, сәяси фәннәр докторы:

– Россия өчен праймериз процедурасы яңалык түгел инде; мәгълүм булганча, «Бердәм Россия» әлеге инструментка узган Дума сайлаулары алдыннан да, 2015 елда Татарстан Президентын сайлау алдыннан да мөрәҗәгать иткән иде. Әмма ул чакта әле чара яртылаш кына булып тоелды. Ә быел без әлеге процедураны бербөтен рәвештә тормышка ашыруны күрдек.

Минем үземне, барыннан да бигрәк, праймеризның барышы турындагы мәгълүматның халык өчен ачык һәм куллана алырлык булуы шаккатырды. Әлеге процесста чын мәгънәсендә бар кеше дә катнаша ала иде. Тагын бер нәрсәне сиздем, дебатларда көн тәртибенең барлык төп пунктлары – аерым алганда, социаль-икътисадый тармактагы кризис күренешләре, мәгариф, медицина белән бәйле булган мәсьәләләр игълан ителде. Гомумән, социаль мәсьәләләр шактый булды. Шуның белән бергә БР дебатларда төрле иҗтимагый оешмаларның катнашуына мөмкинлек бирде, болай эшләгәч, төрле фикерләр, кайчак хәтта радикаль карашлар да ишетергә мөмкин булды. Хәер, соңгылары барыбер экзотика кебек кенә тоелды, күпчелек исә чынлыкта кулланырга мөмкин булган прагматик фикерләрне җиткерде. Ә шул ук БР йөзендәге хакимияткә исә аларны тупларга кирәк. Чөнки бу шактый мөһим контент булды.

Партия боссларына праймериз институты комачаулыймы? Әлбәттә, комачаулый. Һәм бу әйбәт тә, чөнки һәр партия җитәкчелеге кешеләрне аппарат ысулы белән генә чыгарырга кирәк түгеллеген аңларга тиеш. Ул «яңа кан»ны күрергә тиеш. Әлеге яңа кешеләрнең беренче праймериз нәтиҗәләре буенча ук съездда партия исемлегенә керүе яки бер мандатлы округка чыгарылуы икеле, әлбәттә, әмма, минемчә, аларны күрерләр, һәм вакыт белән алар төрле дәрәҗәдәге депутат була алырлар.

Ә тавыш бирү нәтиҗәләренә килгәндә, алар безнең өчен көтелмәгән хәл булмады. КФУның экспертлар советы даими рәвештә социологик тикшеренүләр уздыра, һәм, аларны динамикада караган чакта, без электораль өстенлек бирү лидерлары булып республика күләмендә үзләрен күрсәтергә өлгергән билгеле кешеләр торганлыгын күрдек.

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Мәктәп һәм балалар бакчаларын капиталь ремонтлау Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү Спорт мәйданчыклары төзү Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Модуль-блоклы ветеринария пунктлары төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Сыер абзарларын капиталь ремонтлау Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ.
НӘТИҖӘЛӘР

«БЕЗДӘ КЫЗЛАР ДА ФУТБОЛ УЙНЫЙ»

Республика программасы буенча төзелгән спорт мәйданчыкларының ничек эшләгәнен күрү өчен, Чаллы шәһәре белән Питрәч районына юл тоттык. Өч сүз белән әйткәндә, алардан халык өзелми. Кощаково авылында ул мәйданчыкка кызыксыну шулкадәр көчле, билгесез затлар хәтта капкадагы йозакны кискәннәр. Хәзер ул тәүлек буе хезмәт күрсәтә.

Автор:
Линар Закиров

«КОЩАКОВОДА – ИКӘҮ, ШӘЛЕДӘ БЕРӘҮ ДӘ ЮК»

Без Питрәч районындагы Кощаково авылына (Кощаково, Званка һәм Царево авылларын берләштергән җирлектә 2868 кеше яши – авт.) килгәндә егетләр-кызлар баскетбол уйный иде.

12 яшьлек Александр Евстафьев спортның әлеге төре белән өч ел элек кызыксынып киткән. Кызыксынмаслык та түгел, бертуган абыйсы – Владислав Евстафьев Казанның «Уникс» баскетбол командасының төп составында уйный.

– Баскетбол – бик мавыктыргыч уен, көн саен икешәр сәгатемне аңа багышлыйм. Кайвакыт дуслар белән төнге унга кадәр әвәрә киләбез. Минем дә абыем сыман «Уникс»ның төп составына эләгәсем, аннары тагын да югары үрләргә ирешәсем килә. Ул баскетбол буенча башта мәктәп данын яклады, аннары район командасында уйнады, «Уникс»ның икенче төркемендә үзен оста уенчы итеп таныткач, төп составка кабул ителде. Абыем елларда авылга кайтып, шушы мәйданчыкта да туп белән рәхәтләнә. Ул миңа төрле алымнар өйрәтә, – дип сөйләде баскетбол дөньясының булачак йолдызы.

Кощаковода ике мәйданчык төзелгән: берсе – мини-футбол (узган көздә), икенчесе – баскетбол өчен (ике ел элек). Безне Питрәч районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Виктор Курмышев озата йөрде. Аның сөйләвенчә, заманында Кощаково яшьләре спорт ягыннан бөтен районны гөрләткән. Ә хәзер сүлпәнлек сизелә. Шуңа да карамастан, элеккеге уңышлары өчен авылга менә шундый зур бүләк ясаганнар.

Спорт мәйданчыклары биредә яшеллек кочагында – паркта урнашкан. Ул күпмедер вакыт ташландык хәлдә булган, авыл җирлегенә бирелгән бер миллион сумлык грантка паркны тәртипкә китергәннәр.

– Узган елдан башлап авыл җирлекләре арасында ярышлар үткәрә башладык. Кайсы команда яхшы нәтиҗә күрсәтә, мәйданчыкларны шунда төзибез. Әйтик, Шәле – Татарстанның иң зур авылы, әмма анда мондый спорт корылмасы юк. Ел саен Питрәч районында кышкы турнирга һәр авыл җирлеге хоккей командасы туплый. Быел Шәле беренче урынны алды, җитмәсә, алар ике команда чыгарды. Шушы уңышлары өчен, чираттагы спорт мәйданчыгы аларда урнаштырылачак, – дип сөйләде Виктор Федорович.

Физкультура укытучысы Татьяна Шмелёва сөйләвенчә, мәктәп спорт мәйданчыгыннан 500 метр ераклыкта урнашкан. Мәктәпнең үз стадионы һәм хоккей тартмасы булса да, матур көннәрдә физкультура дәресләрен монда да уздыралар.

– Мәктәп стадионында баскетбол мәйданчыгы юк, ә монда волейбол челтәре дә сузарга мөмкин. Анда – гади чирәм, ә монда ясалма газон җәелгән, чапканда шумый. Туп та еракка очмый, – дип сөйләде укытучы.

Мәктәпнең волейбол буенча малайлар һәм кызлар командалары бар. Без килгән көнне алар махсус форма – яшел майка киеп уйный иде.

– Укучыларны командага бишенче класстан ук туплый башлыйм, хәзер күбесе тугызынчы класстан соң китә бит. Быел волейболчы кызларыбыз район командасы составында республикада икенче урынга чыкты. Малайларыбыз әлегә калыша. Кызларның җаваплылык хисе көчлерәктер, күрәсең, – дип, үзенчә аңлатты Татьяна Шмелёва.

Районның спорт бүлеге башлыгы сүзләренчә, спорт мәйданчыкларының кайберләре авыл җирлеге, кайберләре мәктәп карамагында. Кощаководагысына авыл җирлеге күз-колак булып тора. Футбол мәйданчыгы капкасында расписание дә эленгән. Анда авыл яшьләренең, мәктәп укучыларының, күрше авыллардан килеп уйнаучыларның нинди вакытта мәшгуль булганы төгәл язылган.

Спорт мәйданчыклары янында зур трибуналар тора. Алдан әйтим, Чаллыда алар юк.

– Трибуналар өстәмә рәвештә район акчасына куела. Балалар, формасын алыштыра алсын, эсседә кояштан сакланасын өчен, район җитәкчелеге шундый карарга килде, – дип аңлатты Виктор Курмышев.

– Баскетбол мәйданчыгы янындагысына бер сүзем дә юк, ә нишләп футбол мәйданчыгы каршындагысы эшләнеп бетмәгән? – дим.

– Былтыр акча җитеп бетмәде. Каркасы эшләнгән инде, эскәмияләр урнаштырып, поликарбонат белән тышлыйсы гына калды.

«СЫРА ЭЧҮЧЕЛӘРНЕҢ КИРӘГЕН БИРӘЧӘКЛӘР»

Иске Шигали авылында футболчылар гына түгел, җанатарлар арасында да ярыш бара. Сигезенче класс кызлары Эльвина Хәкимуллина, Сюзанна Салиева һәм Ира Михайлова, сөрәннәр әйтә-әйтә, зәңгәр футболкалы егетләр – үзләренең классташ егетләре өчен җан атып утырды. Ә сары футболкалы баһадирлар – җиденче класста белем алучылар. Аларның җанатарлары да калышмый.

Фото: Луиза Янсуар

PRESSA.RU

– Егетләр генә түгел, без, кызлар да бик яратып футбол уйныйбыз. Андый чакта безнең өчен егетләр җан ата. Кызлар футболы егетләрнекеннән бернәрсәсе белән дә аерылмый, без дә тупны каты тибәбез. Мәйданчыкның буш торганы юк, кичке якта халык аеруча күп җыела, – дип сөйләде гүзәл затлар.

Иске Шигалидагы мәйданчык 2013 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында ачылган. Мондагы спорт корылмасы капкасына йозак эленмәгән. Бик белән ябыла торган мәйданчыкларны бер елны гына чыгарганнар, калганнарын йозаксыз итеп кенә эшләгәннәр.

– Кощаковода халык, мәйданчык тирәсендә җыелып, сыра эчкәләсә, мондагы яшьләр спорт корылмасы янында берәрсен хәмер белән күрсә, кирәген бирәчәк. Бу авылда берничә ел мәктәп директоры булып эшләдем, шуңа да җирле яшьләрнең холкын яхшы беләм, – дип елмайды Виктор Федорович.

Районда республика программасы буенча тугыз мәйданчык төзелгән, шуларның тагын берсе – Питрәчтәге балалар шәһәрчегендә. Быел тагын икәү сафка бастырыла: район үзәгендәге Боз сарае янында һәм Богородское авылында.

Балалар шәһәрчеге янына килеп туктагач, футбол мәйданчыгында чүмәшеп утырган сабыйларга күзебез төште. Әни кеше Мария Невская ике баласын һәм аларның дус кызларын ияртеп килгән.

– Үз балаларым белән монда көн дә киләбез. Якынрак булса иде. Өебездән монда кадәр бер километр ара үтәргә кирәк. Без яши торган Спорт сарае янында бер мәйданчык та юк бит, – дип көрсенде әни кеше.

– Ул тирәдә спорт мәйданчыгы төзелеп килә, – диде Виктор Курмышев.

– Кайчан була әле?.. – дип, җитәкче сүзен ышанмыйчарак кабул итте ул.

– Быел. Ике атнадан инде әзер булачак, – дип ышандырды җитәкче.

«ҖӘЙНЕҢ БЕР КӨНЕН ДӘ БУШКА УЗДЫРМЫЙМ»

Ә хәзер Чаллы якларына күчик. 21 яшьлек Руслан Биккинин 11 ел паркур һәм акробатика белән шөгыльләнә. Паркур белән шөгыльләнүчеләрне трейсерлар дип атыйлар, алар төрледән-төрле каршылыкларны сикереп үтәләр. Руслан балачакта паркур турында фильмнар карап илһамланган да, балалар бакчасы тирәсендә шөгыльләнүче бер төркем трейсерлар белән танышып, шушы агымга кушылган.

Без Руслан белән Пушкин исемендәге 78нче пролицей биләмәсендәге спорт мәйданчыгында күрештек. Биредә тренажерлар һәм баскетбол мәйданчыгы урнашкан. Паркур белән акробатика алымнарын да шомартырга менә диген урын.

– Заманында трейсер егетләр белән ныклы төркем булып оештык та көн дә бергәләп шөгыльләндек. Хәтта Түбән Кама шәһәренә җәяү бардык, кире автобус белән кайттык. Төрле шәһәрләрдә үткәрелә торган паркур фестивальләрендә катнашканыбыз булды. Һәркем үз мәшәкатьләренә чумып, хәзер инде сирәк күрешәбез. Әйтик, мин 2,5 ел кою заводында эшлим. Паркур белән урамда шөгыльләнәләр, шуңа да кыш көннәрендә алымнарны спорт залында шомартырга туры килә. Җәйнең бер көнен дә бушка уздырмаска тырышам, – дип сөйләде миңа Руслан.

Әңгәмәдәшем әйтүенчә, Чаллыда спортның экстремаль төре белән егетләр генә шөгыльләнә, һәрхәлдә, аның гүзәл затлардан берәүне дә очратканы булмаган.

Русланның өстендәге киеме – күлмәк белән чалбары – капчык сыман асылынып тора. Кем ничек тели, шулай киенә, иң мөһиме – уңайлы булсын, ди ул.

Трейсерларны адым саен куркыныч сагалый. Русланның да шундый «ятьмә»гә эләккәне бар.

– 13 яшьлек чагымда егетләр белән төзелеп бетмәгән бер бинада йөрдек. Дүртенче кат биеклегендә бер урыннан икенчесенә сикергәндә, аңымны җуем, егылып төштем. Борынымны сындырдым. Әти-әнием, паркур белән бүтән шөгыльләнмәячәксең, дип тыйса да, нишләтәсең, күңел барыбер тартты. Киләчәктә сак булачакмын, дип ышандырдым якыннарымны, – диде ул.

– Шушы спорт мәйданчыкларына нинди бәя бирә аласың?

– Аларның сыйфатлы булуы ошый, тренажерлары да нык беркетелгән. Мускулларны ныгыту, воркаут белән шөгыльләнү өчен әйбәт. Мәйданчыкның өслеге бераз пычрак, шунысы гына кызганыч, юып торсалар, бер дә комачау итмәс иде, – диде трейсер.

Русланның йөргән кызы (бәлки, дус кызы) Алёна Зәйниева да спортка мөкиббән – баскетбол уйный. Гомумән, аның бөтен гаиләсе шушы спорт төренә бирелгән: абыйсы профессиональ рәвештә шөгыльләнә, тагын бер туганы Чаллы мәктәпләрендә укучыларны баскетбол уйнарга өйрәтә.

«ӘБИЕМ, СИННӘН БАШКА ЙӨРМӘЯЧӘКМЕН»

Чаллының «Төзүчеләр» стадионы тирәсендәге заманча зур мәйданчык – ике мини-футбол кыры белән тренажер зонасы әллә каян балкып тора. Бокс белән шөгыльләнүче егетләр монда килеп, күнегүләр дә ясый.

Анна ханым Кизбаева дүртенче класста укучы оныгын беренче генә тапкыр алып килгән. Үзен якларга өйрәнсен, ди ул оланы турында.

– Оныгымны класста кыерсыткаладылар. Беркатлырак ул безнең. Бераз юанрак та инде. Дөрес ашатмыйсың, дип, әнисен орышкалыйм да. Ахыр чиктә, түзмәдем, монда китерергә булдым, – диде әби кеше.

– Оныкны озак үгетләдегезме? – дим.

– Мин үгетләп тормыйм, бер генә әйтәм. Оныгым: «Әбием, мин монда синнән башка йөрмәячәкмен», – ди. Мин – аның тарту көче, – дип көлә әңгәмәдәшем. – Бокс белән шөгыльләнәсе булгач, ник безне чаптыралар, дип тә аптырады ул. Тын юлларын ачу өчен кирәк, дип аңлаттым. Мин заманында йөзү белән мавыктым, велоузышларда катнаштым. Хәзер дә һәр иртә зарядка ясыйм. Безнең Чаллыда олы яшьтәгеләр арасында, чаңгы таякларына таянып, скандинавча йөрү бик популяр, – диде Анна ханым.

Икенче класста укучы Артём Трондин бокс түгәрәгенә инде өченче ел йөри.

– Бер тапкыр миңа мәктәптә егетләр бәйләнде. Бокс алымнарын кулланып сабакларын укыткач, андый теләкләре бүтән уянмады. Классыбызда миннән башка

Спорт мәйданчыкларын төзү программасын финанслау

2013 елда	2014 елда	2015 елда
Республика бюджетыннан бүленгән:		
300 млн сум	292,8 млн сум	385,4 млн сум
Федераль бюджеттан:		
–	39,8 млн сум	4,3 млн сум

2013-2015 елларда Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегендә

483 спорт мәйданчыгы төзелде

Ясалма өслекле спорт мәйданчыкларын төзү буенча республика программасы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе нигезендә 2013 елдан эшли. 2013–2015 елларда 483 спорт мәйданчыгы төзелде. 2016 елда 188не сафка бастырачаклар. Караңгы төшкәч, барлык мәйданчыклар яктыртыла.

Наталья Безрукова, Чаллы шәһәренең физкультура һәм спорт идарәсе башлыгы:

– Өч ел эчендә Чаллыда барлыгы 24 спорт мәйданчыгы, шуларның 22се гомуми белем бирү һәм спорт мәктәпләре территориясендә төзелде. 2016 елда 14 мәйданчыкның 11е – белем бирү учреждениеләре, ә өчесе югары һәм урта махсус белем бирү йортлары биләмәсендә урнаштырыла. Муниципаль учреждениеләрнең бурычы – спорт корылмаларының төзеклеген саклау, халыкка, шул исәптән, сәламәтлек ягыннан физик мөмкинлекләре чикле булган кешеләргә анда шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр булдыру. Шушы мәйданчыкларда ГТО комплексына да әзерлек алып барыла. Чаллы шәһәре сайтында физик тәрбия һәм спорт идарәсе бүлегендә «Все об универсальных спортивных площадках» бүлекчәсендә спорт мәйданчыкларының адресы, эш вакыты, аларга хезмәт күрсәтүче оешма вәкилләренең исемнәре һәм телефон номерлары күрсәтелгән.

бокс белән кызыксынучы юк. Атнасына өч тапкыр 1,5 сәгать шөгыльләнәм. Абыем да боксчы, миннән 10 яшькә олы... Дөресен әйткәндә, минем чемпион буласым килә, – дип, хыялы белән уртаклашты яшь спортчы.

«БӘЛКЕМ, АЛАРНЫ ТЕЛЕВИЗОРДАН КҮРҮ НАСЫЙП БУЛЫР»

Икенче мини-футбол кырында «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнүче малайлар мәш килә иде. Тренерлары Михаил Павловка 28 яшь, шушы спорт мәктәбендә алты яшьтән шөгыльләнеп, «Төзүче»гә инде егерме елдан артык тугрылык саклый. Физкультура белгечлеге буенча читтән торып белем алган. Бүгенге көндә ул 2003 һәм 2006 елда туган егетләр төркемен җитәкли, һәркайсында – 15 кеше. Спорт мәктәбендә шөгыльләнү бушлай. Форманы да бирәләр, тик ул төс-кыяфәте белән мактанырлык түгел. Берсендә 2006 елгылар төркеменә йөрүче малайның әтисе Яңа елга бөтен командага өр-яңа форма алып биргән. Менә сиңа Кыш бабай...

– Балалар атнага биш тапкыр шөгыльләнә, кайвакыт үз ялымны корбан итеп тә эшкә чыгам. Ярышларда катнашабыз, тик нәтиҗәсе мактанырлык түгел шул. Чаллыда спорт мәктәпләре арасында көндәшлек зур, егетләрнең күбесе «КАМАЗ» футбол командасына тартыла. Безгә аның белән ярышу әлегә авыррак, ләкин калышмаска тырышабыз. Мисал өчен, «КАМАЗ» аша 200–300 кеше үтсә, минем аша – 50 кеше. Аларда сайлап алу мөмкинлеге зуррак. Бездән «КАМАЗ»га китүчеләр дә бар. Тренер буларак, миңа бу бераз үкенечле. Баланы биш ел әзерлисең, ә ул көннәрдән бер көнне икенче командага күчә... Бер тапкыр «КАМАЗ»га каршы уйнаганда, безгә йөрүче малайның әнисе, көндәш команда тренеры янына барып, баласын шунда күчерүләре турында сөйләште, – дип, күңелдәгесен чыгарып салды әңгәмәдәшем.

– Бүген тренерлар нинди рәк хезмәт хакы ала? Тамак туйдырып буламы? – дим.

– Миңа ике төркем өчен 11 мең сум түлиләр. Бу акчага яшәп булмый, билгеле, шуңа да төнлә өстәмә эш белән шөгыльләнергә туры килә. Мәскәүдә яхшы түлиләр, диләр. Бездәге тренерлар арасында да 25шәр мең алучылар бар. Хезмәт хакын исәпләгәндә тренерның нәтиҗәләренә карыйлар. Мин бит әле яшь белгеч. Ни дисәң дә, балаларның профессиональ яктан үсеш кичергәнен күзәтү рәхәт. Бәлкем, киләчәктә аларның ничек уйнаганын телевизордан да күрү насыйп булыр, – дип хисләнеп алды Михаил Павлов.

PRESSA.RU

KAZANSUMMIT*: ТАТАРСТАН ҮЗЕНЕКЕН ҺИЧШИКСЕЗ АЛАЧАК!

19–21 майда Казанда Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы (ИХО) илләренең VIII Халыкара икътисадый саммиты үткәрелде. Моннан сигез ел элек KazanSummit дөнья икътисадый бергәлеге тарафыннан бизнес үстерү проблемалары һәм перспективалары турында сөйләшүләр алып барыла торган күп мәйданчыкларның берсе буларак кына кабул ителгән иде. Бүген исә, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, «бу инде ислам динен тотучы халык яшәгән төбәкләр генә түгел, Россия кебек зур илнең үзенчәлекләрен аңларга омтылган ислам дөньясы дәүләтләре дә игътибарын юнәлткән бөтенләй үзгә бер мәйдан».

Автор:
Татьяна Колчина

ИЛНЕ ТАТАРСТАНГА КАРАП БӘЯЛИЛӘР

Форумның күп кенә кунаклары – ә алар арасында РФ Дәүләт Думасы һәм Федерация Советы депутатлары, берничә федераль министрлык һәм ведомство вәкилләре, 51 илнең илчесе һәм вәкиле бар иде – KazanSummit 2016ны Давос икътисадый форумы белән чагыштырды, аерма бары Казанда Россиянең ислам дөньясы дәүләтләре белән хезмәттәшлеге мәсьәләләре тикшерелүдә генә иде.

– Саммитның дәрәҗәсе бик югары, – дип, чараның оештырылуына үз бәясен бирде Ингушетия Республикасы башлыгы Юныс-бәк Евкуров. – Һәм бу бик әһәмиятле, чөнки Татарстанга карап тулаем илгә бәя бирәләр. Мин халыкара делегацияләр вәкилләренең реакциясен күрдем: аларны мөселманнарга Россиядә булган мөнәсәбәт гаҗәпләндергән иде. Дөньяда бу күзәтелми.

KazanSummit 2016ның төп темасы – Россиядә ислам банкингы (икенче төрле әйткәндә, партнёрлык яки этика шартларына туры китереп финанслау) инструментларын кертү перспективасы: Көнбатыш финанс базарлары ябылу белән әлеге тема илдәге иң зур банклар өчен гаять актуальләште.

ЯРАМЫЙ, ТИК БИК КИРӘК

Ислам финанслау моделенең англо-сакс моделеннән төп аермасы – рибачылыкны тыю: нинди дә булса проектны финанслаучы банк партнёр буларак катнаша, ул гамәлгә кертелгәндә, табыштан үзенең килешүдә күрсәтелгән өлешен ала бара.

Ислам финанслау секторы икътисадның теләсә кайсы тармагы хыялланырлык үсеш темплары күрсәтә: соңгы 15 ел дәвамында ислам финанслары елына уртача 15–20 процентка арта; узган ел азагына әлеге базар күләме 3 триллион АКШ долларына якынлашкан. Ислам финанс оешмалары Якын Көнчыгышның барлык илләрендә, шулай ук Малайзия, Бөекбритания, АКШ һәм Германиядә эшли.

Баштарак Россия Үзәк банкы банкирларның РФндә дә партнёрлык финанславы инструментларын кертү мөмкинлеген карау турындагы тәкъдимнәренә игътибар итмәде. Әмма Россия кредит оешмалары өчен көнбатыш финанс базарлары ябылганнан соң, регулятор, ниһаять, карашын Көнчыгышка юнәлтергә мәҗбүр булды: Үзәк банк каршында РФндә ислам банкингы хезмәтләрен күрсәтү механизмнары һәм мөмкинлекләрен өйрәнү буенча эш төркеме төзелде. «Россия банкы хәзерге вакытта партнёрлык банкингының формалашкан практикаларын һәм аларны Россия законнары кысаларында гамәлгә кертү үзенчәлекләрен өйрәнә. Мондый практикалар финанс хезмәтләре күрсәтү һәм безнең илгә инвестицияләр җәлеп итү буенча өстәмә мөмкинлекләр ача ала», – диелгән әлеге очрак уңае белән регулятор тараткан пресс-релизда.

* KazanSummit – КазанСаммит

Фотолар: Ната Смирнова

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТӨБӘКТӘ ИНСТИТУТ КИРӘК!

Партнёрлык финанслары инструментларын кулләп кертү юлында төп каршылык – Россия банк, финанс һәм салым законнарының бер-берсенә җайлаштырылмаган булуы (Россия кредит оешмаларына сәүдә итү тыелган, ә ислам банк системасы банкның товар сатып алып, үзенә табыш калдырып, аны клиентка өлешләп түләү шарты белән сатуына нигезләнә). Закон чыгару базасында кардиналь үзгәртүләрне көтүдән файда юк – бу очракта критик масса туплану законы эшли башларга тиеш. «Деловая Россия» иҗтимагый оешмасы рәистәше Антон Данилов-Данильянц да моның белән килешә:

– Россиядә үсеш институтлары, шул исәптән икътисадны үстерүгә юнәлтелгәннәре дә, шактый, алар өчен кагыйдәләрне дәүләт билгели: мәсәлән, Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү корпорациясе яки Сәнәгатьне үстерү фонды. Татарстанның исә үз төбәк үстерү институтын булдырырга хәленнән килә, ул киләчәктә федераль һәм хәтта дөньякүләм дәрәҗәгә дә җитәр иде.

Ислам финанслау секторы икътисадның теләсә кайсы тармагы хыялланырлык үсеш темплары күрсәтә.

РОССИЯ ФИНАНС СИСТЕМАСЫНА ИСЛАМ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КЕРТҮНЕҢ ТЕРЕ МИСАЛЛАРЫ

Данилов-Данильянц фаразларының реаль нигезе бар. Чөнки нәкъ менә Татарстан, төбәкләрдән беренче буларак, Россиядә партнёрлык финансларын үстерү перспективалары белән кызыксына башлады: бу тема 2009 елда узган тәүге форумда ук яңгыраган иде. Нәкъ менә Татарстанда Россия финанс системасына ислам кагыйдәләрен кертүгә тере мисаллар бар: Ак Барс Банкы Якын Көнчыгыштан һәм Фарсы култыгы илләреннән шәригать нормаларын саклап ике тапкыр инвестицияләр җәлеп итте: 2011 елда 60 миллион доллар һәм 2013 елда 100 миллион доллар. Төбәкнең тагын бер кредит оешмасы – «Татагропромбанк» – инвестицияләр, лизинг, валюта операцияләре һәм сәүдә финанславы белән шөгыльләнә торган «ислам тәрәзәсен» ачты. Ниһаять, Татарстан ислам финанславы өлкәсендә хезмәттәшлек турында Саклык банкы белән килешү төзеде.

– Килешү нинди дә булса лимит һәм сделкаларны күз алдында тотмый, – дип шәрехли документны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов. – Әмма без моңа карата үзебезнең җитди мөнәсәбәтебезне белдердек. Без беркайчан да юкка гына эшләмибез, димәк, Татарстан үзенекен һичшиксез алачак!

PRESSA.RU

БӘҺРӘЙН ТАТАРСТАН БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ ШАТ

Фәрид Якуб әл-Муфтах,
юстиция министрының ислам мөнәсәбәтләре буенча урынбасары (Бәһрәйн):

– Бәһрәйн Татарстан белән хезмәттәшлеккә бик шат, бу зур мөмкинлекләр бирә. Бәһрәйн короле күптән түгел генә Россиядә булып китте һәм кайтуга ук икътисадның барлык тармакларында, аеруча хәләл сферасында, ике ил арасында элемтәләрне үстерү кирәклеген раслады.

ГАМБИЯ САММИТ ТӘҖРИБӘСЕН КУЛЛАНАЧАК

Анна Вадда,
Гамбия
сәүдә министры:

– Миңа саммитның идеясе бик ошады, нәкъ менә шуңа да без Казанга Гамбиядән делегация белән килеп төштек. Монда спикерларны тыңларга, дискуссияләрдә катнашырга, ислам бизнесын үстерүдәге яңалыкларны белергә дип килдек. Казанда алган тәҗрибәне һичшиксез эшебездә кулланачакбыз.

КАЗАН БӨТЕН ДӨНЬЯНЫ КЫЗЫКСЫНДЫРА АЛДЫ

Шәех Тафир Нажар,
Көньяк Африка Ислам советы башкаручы директоры:

– Бу минем Казанга беренче килүем, һәм мин саммитның шундый шәп оештырылуына таң калдым. Бу бит чын уңыш – Казанга саммитка килергә теләгән бөтен кешене кызыксындыру һәм дөньяның төрле илләре вәкилләрен бергә туплау. Безнең тормыш торган саен глобальләшә бара, һәм саммитта катнашучыларны кабул иткән кунакчыл Казан әлеге глобаль аренада көчле уенчы булып тора.

САММИТ ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ БУЛЫШАЧАК

Әхмәд Галәлетдин,
Халыкара бизнес һәм инвестицияләр ассоциациясе идарәсе рәисе (Мисыр):

– Мин саммит Россия белән Африка һәм Якын Көнчыгыш илләре арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә булышыр, дип уйлыйм. Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать тармаклары хезмәттәшлекнең төп юнәлешләренә әйләнә алачак.

PRESSA.RU

КАЗАНДА ЗУР ПРОБЛЕМАЛАРНЫ ХӘЛ ИТӘЛӘР



Григорий Быстров,
Россия аграр хокук, табигый ресурслар хокукы, экологик хокук ассоциациясе директоры:

– Минемчә, Россия бизнесы мөмкинлекләрен һәм ислам дөньясы инвестицияләрен берләштерү күп проектларны, шул исәптән аграр проектларны да, гамәлгә кертергә булышыр. Россиянең мөселман республикалары хәләл индустрияне үстерү белән кызыксына, ә Татарстан исә очрашулар, аралашу һәм эш мәнфәгатьләрен кайгырту өчен безне искиткеч саммит мәйданчыгы белән тәэмин итте.

РОССИЯНЕ ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН ТОТАШТЫРА ТОРГАН КҮПЕР



Абдул Разак әл-Сәгъди,
Иордания Бөтендөнья ислам фәннәре һәм мәгарифе университеты профессоры:

– Без Татарстанның мәдәнияте һәм тарихы турында күп беләбез, бу республиканың гөрләп үсүен күрәбез. Татарстан җитәкчелегенең Болгар шәһәрендә ислам академиясе ачуга ризалык бирүенә мин шат. Казан Россияне икътисадый, финанс һәм рухи планда ислам дөньясы белән тоташтыра торган күпергә әйләнә ала. Мин үз дусларымны һәрвакыт Татарстанга килергә өндим.

РОССИЯДӘ ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАРЫ ПОТЕНЦИАЛЫ – БЕРНИЧӘ МИЛЛИАРД ДОЛЛАР

Сергей Горьков,
«Тышкы икътисадый банк» рәисе:

– Россия инфраструктура ягыннан тиешенчә финансланмый, һәм мурабәхә (банкның товар сатып алуы һәм аннары клиентка арттырып сатуы – ред.) яки сокук (предприятиеләрне максатчан финанслау өчен чыгарыла торган облигацияләрнең ислам вариантлары, әмма билгеләп куелган керемсез – моны шәригать тыя – ред.) кебек финанс продуктлары инфрастуктура тармагындагы инвестицион һәм квазиинвестицион проектлар өчен бик кулай булыр иде. Бу өлештә Россиядә партнёрлык финанслары потенциалын якынча берничә миллиард АКШ долларына бәяләп була.

ХӘЛӘЛ ИНДУСТРИЯСЕ ӨЧЕН ХАБ

Надир Йосыф Эльтайеб Бабикер,
Судан Республикасының Россиядәге илчесе:

– Суданда без барлык башлангычлар өчен дә ачык. Саммит – компания вәкилләре белән танышу, алар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерү өчен менә дигән мөмкинлек ул. Мәсәлән, хәләл продукция базары актив үсә һәм мөселман илләрендә генә түгел, башка дәүләтләрдә дә таныла бара. Казан саммиты – хәләл индустриясе өчен үзенә бер төрле хаб, ягъни үзәк ул.

ТАТАРСТАНДА КУНАК БУЛАСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

PRESSA.RU

ДИН САКЧЫЛАРЫ:
МИЛЛИ ТЕЛ, КИЕМ ҺӘМ ГАДӘТ

Автор:
Линар Закиров

Казанда май аенда узган VII Бөтенроссия дин әһелләре форумында күп кенә четерекле мәсьәләләр калкып чыкты. Хәер, шулай булырга тиеш тә – әлеге җыен дини вазгыятьтәге проблемаларны уртага салып сөйләшү һәм аларны чишү юлларын эзләүне күздә тота. «Татарстан» журналы игътибар иткәнчә, урта һәм олы яшьтәге хәзрәтләр, нигездә, үз өлкәләрендә алып барган эшчәнлек турында хисап тотса, яшьләр кыю рәвештә тәнкыйди фикерләрен дә җиткерде.

Фото: Ната Смирнова

ТӨРКИЯ АГАЧЫ ТАТАРСТАНДА ЙӘ ӨШИ, ЙӘ КОРЫЙ

Форумның беренче көнендә кунаклар, секцияләргә бүленеп, дүрт төрле темага фикер алышты. Барысы да бер үк вакытка туры килгәнгә, «Татарстан» журналисты «Татар яшьләре һәм Ислам дине» секциясе утырышында катнашты. Аны Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев җитәкләде. Дин әһеле сүзен сабыйлардан башлады. Ислам дине туган көн, Яңа ел кебек бәйрәмнәрне танымый, әмма без дөньяви дәүләттә яшибез, һәр баланың да бәйрәмгә бүләк аласы килә бит.

– Үзегезне бала урынына куеп карагыз әле, – дип мөрәҗәгать итте Җәлил хәзрәт. – Беренче баш казыебыз Габделхак хәзрәт Саматов: «Әй, бу бабайлар, яшьләрне тиргәгәндә, нишләп үзләренең яшь чакларын искә төшерми икән», – дип әйтә иде. Әйтик, балалар бакчасындагы төркемдә 15 бала, ди. Яңа ел бәйрәме алдыннан, Кыш бабай сиңа нәрсә алып килде, дип бер-берсеннән сорашалар. Араларыннан берәү: «Безнең әти-әни мөселман, намаз укый, безгә Кыш бабай килми», – ди. Теге 14 бала нәрсә дип уйлый? «Әле ярый әти-әниебез намаз укымый, безгә дә Кыш бабай килмәс иде», – ди. Димәк, калган 14 балада ислам диненә тискәре караш уяна. Шуңа күрә сак эш итәргә кирәк.

Сабантуй да безнең бәйрәм түгел. Анда барыргамы-бармаскамы, дип тавыш чыгаручылар, гаиләләре таркалучылар да булды. Шуннан соң мөселман сабан туе үткәрә башладык. Хәзер күп җирләрдә ул бәйрәмдә хәмер сатылмый. Андый чараларны үзебезнең мәнфәгатьтә файдаланырлык дәрәҗәгә китерергә кирәк. Без, дин әһелләре, катнашмасак, гомумхалык бәйрәмнәр әхлак ягыннан начарлана гына барачак, – диде Җәлил хәзрәт Фазлыев.

Татарстанның баш казые фикеренчә, нинди җәмгыятьтә яшәгәнебезне бөтен нечкәлекләренә кадәр уйларга тиешбез. Төркия яки Гарәбстандагы стандартларны турыдан-туры Татарстан җирлегенә күчерү – мөмкин хәл түгел. Җәлил хәзрәт бу уңайдан чагыштыру да китерде: бик яхшы алмагачны Төркиядән безнең республикага алып кайтып утыртсаң, ул монда йә өши, йә корый. Сәбәбен тиреннән эзлисе түгел – шартлары туры килми.

– Күп нәрсә шәхси үрнәктән тора. Бер хирургның намаз укы дип әйтүе, имамның йөз вәгазеннән яхшырак тәэсир итә. Дөньяви белем алудан курыкмаска кирәк. Кеше дини белем генә алсын, дисәк, бернәрсәне дә кабул итмәүче фанатиклар килеп чыга. Шул ук вакытта кешенең кызыл дипломы, карьерасы булып та, күңелендә иман булмаса, ул корыган агачны хәтерләтәчәк. Андый кеше яхшы машинада җилдерергә, галстук тагып йөрергә мөмкин, әмма аның киләчәге юк, дигән сүз, – диде Җәлил хәзрәт Фазлыев.

ҖЫЛЫТМЫЙБЫЗ, ӨШЕТӘБЕЗ ГЕНӘ

Дин белән кызыксыну татар теленә бәйле, дигән фикер форумда кызыл җеп булып сузылды. Шушы җәһәттән Уфадагы «Ихлас» мәчетеннән яшь хәзрәт Альфред Дәүләтшинның чыгышы кунакларның игътибарын аеруча җәлеп итте. Аның сөйләвенчә, Башкортостан башкаласында җомга вәгазьләрен татарча алып барган имамнар рус телендә чыгыш ясауны үз итә башлаган. Имеш, шәһәр яшьләре, үзбәк, таҗик кебек милләт вәкилләре татарча белми, ә динне барысына да аңларлык рәвештә җиткерергә кирәк.

– Бу яңалык үз «нәтиҗә»сен дә китерде – руслашу башланды. «Вирус» Уфаның Тукай урамындагы Җәмигъ белән Ләлә-Тюльпан мәчетләренә дә барып җитте. Бүген Башкортостан башкаласында бер миллион да йөз мең кеше яши, шуның яртысы – татар һәм башкорт, ләкин татар телендә вәгазь «Ихлас» мәчетендә генә алып барыла. Уфада башкортча вәгазьләр бар, дип уйлый күрмәгез. Башланмыйча бетте, – диде чыгыш ясаучы.

Альфред Дәүләтшин татар телен гасырлар буе исламны тарата торган тел, дип атады. Аның әйтүенчә, җомга вәгазьләрен русча алып бара башлаган имамнарның күпчелеге мәктәпләрдә татар телендә укып, татарча яхшы белә.

– Алар кайсы милләт балаларын дингә өйрәтә? Рус белән мари халкынмы? Әлбәттә юк. Ник соң татар кешесенә рус телендә җанын җылытырга тырышабыз? Җылытмыйбыз, өшетәбез генә. Өстәвенә, шул имамнарның русчасын да аңлап булмый. Ризаэтдин Фәхретдингә әтисе 20 яшенә кадәр рус телен өйрәнүне тыйган. Әхлагы бозылмасын өчен. Аның рус телендә бер дини хезмәте дә юк. Ә быел Уфада «Фәхретдин укулары» чарасы рус телендә генә узды.

Россиянең нинди генә төбәгендә яшәсәк тә, без анда килмешәк тә, диаспора да түгел. Татар ул Россияне дәүләт итеп оештырган халык, аның Камчаткасы да – камчы тау, Магаданы да – мәгъдән, Читасы да -чат, Саратовы да – сары тау, ул шәһәрләрдә соңгы 20 елларда мәчетләрне кем төзеде? Әлбәттә татарлар, – диде яшь хәзрәт.

Уфа кунагы татар яшьләренең тәңречелек, аюрведа белән кызыксына башлауларына да игътибар итте. Бу күренеш хәзрәтнең баласы укый торган мәктәпкә дә килеп җиткән. Укучыларның әти-әниләре «Ватсап» кушымтасында фикер алышу өчен төркем оештырган. Пасха бәйрәмендә шунда, хәзрәт әйткәнчә, Айгөлләр, Зөлфияләр бер-берсенә бәйрәм котлаулары һәм буялган йомырка фотоларын җибәргән.

-Ни өчен балаларыбыз милләт диненнән ерак? Сәбәбе, бәлки, үзе-

PRESSA.RU

бездә – мөселманнардадыр. Без мәчетләребездә бикләнеп утырабыз, мөселман яшьләре һәм хәзрәтләр еш кына тирә-якка маңгай астыннан карый. Динебездә тыюны гына күрәбез, дини оешмаларыбызда да – ирексезлек һәм авторитаризм. Татар дин әһелләре исламны, яралганнан башлап, һәр чорда да буйсыну һәм буйсындыру дине булган дип кенә өйрәтә. Ә бит динебезнең нигезендә мәхәббәт һәм мөстәкыйльлек ята.

Исламда террор юк дип күпме генә әйтсәк тә, кардәшләребез «Аллаһ әкбәр», дип, кешеләрнең башларын кисә. Күзәтүләрем буенча әйтәм: дини максимализм һәм радикализм рус телендәге вәгазьләр өстенлек иткән мәчетләргә йөрүче мөселманнар арасында аеруча көчле. Вербовканы татар телендә алып бару кыенрактыр, күрәсең. Ләкин яшьләрнең йөрәкләренә юлны сәясәткә кермичә генә табасы иде. Шиһабетдин Мәрҗани әйткәнчә, диндә өч нәрсә юк, ләкин шулар динне саклый – милли тел, милли кием һәм милли гадәт, – дип, фикерен җөплап куйды Уфа хәзрәте.

ТУКАЙ ИШАННАРНЫ НИК ТӘНКЫЙТЬЛӘГӘН?

«Татарларда суфыйчылык һәм дини традицияләр» секциясен Мәскәү, Россия үзәк төбәге һәм Чувашия Республикасы мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов җитәкләде. Аның сүзләренчә, утырышта, ни өчен олы әдипләребез, әйтик, Габдулла Тукай ишаннарны мыскыллап язган, диючеләр дә булган. Әлбир хәзрәт фикеренчә, бүгенге вазгыяттә Тукай кебек бөек әдипләребез экстремизм тарафдарларын тәнкыйтьләп язган булырлар иде.

– 2015 ел саннарына карасак, илебездә экстремистик юнәлештәге җинаятьләрнең саны арткан. Бересезгә дә сер түгел, бу эшне оештыручы кешеләр яшьләребезне ялган дини фикерләр артына ияштерәеп, үзләренә тарта. Безнең секциядә суфыйчылыкка багышланган аерым сайт булдыру тәкъдиме яңгырады, – диде Әлбир Крганов.

ПРЕЗИДЕНТ АЙФОНЫНА ЧЕХОЛ ТЕКТЕМ

Форумның икенче көнендә Г. Камал театрында пленар утырыш узды. Аның алдыннан кунаклар күргәзмәдә халык осталары һәм һөнәрчеләре ясаган эшләнмәләр белән таныштты. Безнең игътибарны гарәп язулары, милли һәм дини сурәтләр төшерелгән паспорт, айфон чехоллары, Коръән өчен чигүле савытлар җәлеп итте. Боларны ясаучы Ирина Галант (Галант – иҗади тәхәллүс. – Авт.) Петербургта күн эшләнмәләре буенча конструкторлыкка укыган.

Ул Татарстанда гамәлгә куелган кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү буенча грантка 2011 елда гаризасын һәм бизнес-планын тапшырып, 300 мең сумга ия булган, 240 мең сумны -чигү машинасын, 60 меңне чимал алуга тоткан. Шарт буенча, грант откан кеше хезмәт урыннары да булдырырга тиеш – Ирина да ике кешене эшле иткән. 2013 елда ул кабат грант откан, бүген ике чигү машинасында биш кеше хезмәт куя. Өченче грантка да гариза бирер идем, ди оста, әмма эшче куллар мәсьәләсе кабыргасы белән килеп баскан.

– Кайбер кешеләрнең эшләргә теләге бар, әмма алар кайчы да тота белми. Училищеларга да мөрәҗәгать иттем, белдерүләр дә бирдем – нәтиҗәсе булмады. Без икътисадчылар, юристлар үстердек, ә кул белән эшли белгән кешеләр шулкадәр аз, – дип борчуын җиткерде әңгәмәдәшем.

2014 елның августында Ирина Рөстәм Миңнехановка айфон өчен чехол теккән. Акча һәм вакыт ягыннан бернинди чикләү куелмаган. Чехолны күннән ясап, тышына Татарстан гербын төшергән.

– Дин бик четерекле тема. Нәрсәнедер белмәсәм, ясамаска тырышам. Татарча аз сөйләшәм, православие динен тотам, шуның аркасында кайвакыт үземә карата тискәре караш та сизәм. Шул ук вакытта, чит илләрдәге күргәзмәләрдә катнашып, татар мәдәниятен танытуга зур өлеш кертәм. Шуның өчен миңа ташлама ясарга була торгандыр. Кызым татар телен камил белер, дип ышанам. Бүген дә менә милли чигешле күлмәк кидем. Моны исламга да, православиегә дә хыянәт итү дип кабул итмим. Форумга килүчеләргә

өстемдә шундый күлмәкне күрү рәхәтрәктер. Һәрхәлдә, Казанның толерант булуы һәм барыбызның да дус-тату яшәве – безнең өстенлек, – дип әйтте кул остасы.

ДИН – БЕЗГӘ ТҮГЕЛ, БЕЗ ДИНГӘ ЯРАКЛАШЫРГА ТИЕШ

Быел форумга 900гә якын делагат җыелды. Амур, Тамбов өлкәләре, Дагыстан республикасы дин әһелләре бу чарада беренче тапкыр катнаша. Иң ишле делегация Башкортостаннан – 120 кеше.

Саратов өлкәсенең Җәмигъ мәчете баш имам-хатыйбы Фәнил хәзрәт Бибарсов, табибларга хас булганча, бүгенге ислам торышына диагноз куеп, үзе әйтмешли, берничә «чир»ен аерып чыгарды.

– Ислам – хак дин, диелсә дә, кайбер имамнар үз-үзләренә каршы килә. Мисал өчен, исламны территориаль һәм милли яктан аерабыз: гарәп исламы, Азия исламы, Кавказ исламы, дибез. Юкса, Аллаһ Тәгалә динебезне татарлар өчен генә түгел, барлык милләтләр өчен дә әманәт итеп җибәргән. Әгәр башкаларны онытсак, алар үз иманын булдырып, арабызда ызгыш башланачак. Без әле үз арабызда да тынычлык саклый алмыйбыз, – диде Фәнил хәзрәт Бибарсов.

Саратов хәзрәтенең ислам тәгълиматын белмәгән кешеләрнең дә киң җәмәгатьчелеккә дингә карата үз фикерләрен белдерүләренә эче поша. Андый белдеклелек тә низагларга китерә.

– Ислам турында үзебезчә уйларга кирәкми, Аллаһ моның өчен Коръәнне иңдергән. Бүген исламны үзебезгә яраклаштыру күзәтелә. Киресенчә булырга – без дингә яраклашырга тиеш. Тагын бер чиребез – күпме шәкерт чит илдән укып кайтып, мәчетләрдә эшли башлады, ә хәзер аларны куалыйлар. Уртак тел табарга кирәк. Кадрлар юк, дибез. Болай барса, булмаячак та, без яшьләрне башта укытабыз, ә аннары куып җибәрәбез, – дип, күпләрне уйландырырлык фикер җиткерде Фәнил хәзрәт Бибарсов.

КҮПМИЛЛӘТЛЕ ХАЛКЫБЫЗ ТЕЛӘКТӘШЛЕК БЕЛДЕРӘ

Форумның өченче көнендә, Изге Болгар җыенында, кунаклар катнашында ислам академиясенә нигез ташы салынды. Рәсми затлар киләчәк буыннарга атап дүрт телдә язылган капсуланы да нигезгә иңдерде.

Тантанада катнашкан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, илнең рухи иминлеген саклап калу өчен, югары дәрәҗәдәге дини уку йортлары кирәк. Заманында безнең җирлектә бөтен дөньяга билгеле булган дин әһелләре яшәгән. Кызганыч, бу вакыт инде артта калган, ә алда – яңа этап. Болгар академиясен төзүне Россия Президенты Владимир Путин хуплаган, федераль үзәк тә ярдәм күрсәтә.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, ислам академиясенең бурычы – Россия дәрәҗәсендәге үзәккә әйләнеп, югары белемле һәм әхлаклы дин белгечләрен әзерләү. Үз мисалыбызда тынычлыкта һәм бердәмлектә ничек яшәргә кирәклеген күрсәтергә тиешбез.

ТР Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев Президент фикерен куәтләде. Динебезне заман таләпләренә җиткерү өчен, белем бирү системасын булдырырга кирәк.

– Күптән түгел Казан Кремлен, Благовещение соборын реставрацияләдек, Кол Шәриф мәчетен торгыздык. Күпмедер дәрәҗәдә тәҗрибәгә ия булгач, Болгар белән Зөяне яңартуга керештек. Күпмилләтле Татарстан белән Россия өчен бу – яхшы фал. Хәзер тагын ике эшкә тотындык – Болгар ислам академиясе белән Казанда Изге Мәрьям ана соборын төзибез. Әлеге проектларны башкарып чыгуга бер шигебез дә юк. Иң мөһиме – бу эштә күпмилләтле халкыбыз теләктәшлек белдерә, – диде Минтимер Шәймиев.

Төньяк Кавказ мөселманнарының координацион үзәк рәисе Исмаил Бердыев, Рөстәм Миңнеханов белән Минтимер Шәймиевнең янәшә торуларына сокланып, бу барыбыз өчен дә зур үрнәк, диде.

-Гадәттә, яңа президент килгәч, элеккегесен, бөтен нәрсәне җимерде, талады, дип хурлый. Ә монда андый нәрсә күзәтелми. Ике җитәкчегез дә янәшә тора, алар бу эшне бергә башлаган. Болгарның Ак мәчетендә тәүлек буе Коръән укыла. Мондый күренеш кайда бар? Бары тик изге урыннарда гына. Сезнең урыныгыз да изге, биредә ислам динен кабул иткәнгә генә түгел, аны изге итүгә президентларыгыз һәм сез биргәләп ирештегез, – дип, югары бәясен бирде Төньяк Кавказдан килгән дин әһеле.

P.S.

ТАТАРСТАН – ИСЛАМ КОМПАНИЯЛӘРЕ ӨЧЕН КЕРҮ НОКТАСЫ

Май ае республикада дини вакыйгаларга бай булып чыкты. Казанда «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең утырышы узды. Бу чарага Казанга Якын һәм Урта Көнчыгышның 30 иленнән сәясәт һәм җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре, эшкуарлар җыелды.

Стратегик күзаллау төркеменең максаты – халыкара мөнәсәбәтләрдәге аеруча кискен мәсьәләләр буенча фикер алышып, аларны хәл итү юлларын табу. Быел Татарстан мисалында мәдәни һәм динара бәйләнешләрне саклауга һәм ныгытуга басым ясалачак.

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты:

– Россия – күпмилләтле ил, биредә 20 миллионнан артык мөселман яши, күпчелеген җирле халык тәшкил итә. Россия дәүләтчелеге оешканда, аңа яңа биләмәләр һәм үз мәдәниятен, динен, телен саклап калган халыклар кушылган. Безнең бердәмлек җиңел генә бирелмәде, әмма, нәтиҗәдә, бүгенге дин һәм милләтара дуслыгыбыз – Россия дәүләтчелегенең нигезе. Илебездәге иң уңышлы төбәкләрнең берсе булган Татарстан моңа ачык мисал.

Бүген дөнья җәмәгатьчелегенә яңа куркыныч яный башлады – дин артына яшеренеп, экстремизм һәм террорчылык яклы кешеләрнең көче арта бара. Аларга мөселман өммәте берләшкән очракта гына каршылык күрсәтеп булачак. Россия бу мәсьәләдә күп көч куя, шул исәптән, стратегик күзаллау төркеме кысаларында.

Без икътисадый хезмәттәшлеккә дә зур әһәмият бирәбез. Республикабыз ислам дәүләтләрендәге компанияләр өчен Россия базарына үтеп керү ноктасына әйләнергә омтыла.

Әхмәд Мөхәммәд Али әл-Мәдәни, Ислам банкы үсеше төркеме президенты:

– Казан инде күптән Көнчыгыш белән Көнбатыш хезмәттәшлегендә мөһим пунктка әйләнде. Ә хәзер, алдан күрүчәнлегегез һәм зирәклегегез нәтиҗәсендә, Татарстан Россия Федерациясе белән ислам хезмәттәшлеге берләшмәсе илләрен тоташтыручы бәйләнешкә әверелде. Ислам банкы Татарстан белән хезмәттәшлек итәргә әзер.

Фото: Ната Смирнова, tatarstan.ru

PRESSA.RU

Фото: Ната Смирнова

WORLDSKILLS. ТАТАРСТАННЫҢ АЛТЫН «БРОНЗАСЫ»

Май азагында Мәскәү янындагы Красногорскида WorldSkills Russia эшче һөнәрләр милли чемпионаты үткәрелде. Татарстан командасы өйгә «бронза» белән кайтты. Бары Мәскәүдән һәм Мәскәү өлкәсеннән генә калышты, шунлыктан бу «бронза» алтындай кадерле.

21 медаль, шулардан 11е – «алтын» – Татарстан җыелмасының WorldSkills Russia-2016 финалында катнашуының нәтиҗәсе шундый. Алтын медальләр саны буенча республика, мәскәүләрне генә алга уздырып, икенче урынга чыкты. Алар исә катнашучылар саны буенча бездән шактый күбрәк иде һәм барлык 61 компетенциядә көч сынашты. Чагыштыру өчен: без 39 номинациядә катнаштык. Татарстанлылар «Мәгълүмати, кабель челтәрләре», «Инженерлык дизайны», «Веб-дизайн», «Медицина һәм социаль тәрбияләү», «Лаборатория-медицина анализы», «Суытучы», «Таш юну эше», «Башлангыч сыйныфлар укытучысы», «Мәктәпкәчә тәрбия», «Мобиль робототехника», «Фотография» номинацияләрендә җинде.

Катерина Котова
әзерләде

PRESSA.RU

АЛМАЗ ТАШ ШОМАРТА

Казан төзелеш колледжы студенты Алмаз Һадиев илнең иң яхшы яшь таш юнучысы булып танылды. Бу җиңү юлындагы кыенлыклар һәм киләчәккә планнары турында без WorldSkills Russia милли чемпионатында җиңүче белән ул Красногорскидан кайткан көнне сөйләштек.

– Алмаз, ни өчен таш юну эшен сайладың? Синең исем белән зәркәнче булырга гына – анда да ташлар бит.

– Ә миңа балачактан төзүче һөнәрләре ошый. Тугызынчы сыйныфтан бирле абзыема төзелештә булышам – ул фирма җитәкчесе. Каникул вакытында җәйге сезон башлана бит, һәм без егетләр белән гел шунда кайнашабыз – фундамент салабыз, опалубка ясыйбыз... Безгә бу эш ошый, хезмәт хакы да начар түгел. Ә таш шомартучы һөнәрен сайлавым очраклы килеп чыкты дисәң дә була – чемпионатка өстәмә әзерлек кысаларында. Теләүчеләрне эзлиләр иде, мин үземне сынап карарга булдым. Барып чыкты тагын үзе.

– WorldSkills барыннан да элек безнең укуга мөнәсәбәтебезне үзгәртте. Яхшылап әзерләнү, күнекмәләр ясау өчен өстәмә стимул барлыкка килде. Ә укыту бездә һәрвакыт югары дәрәҗәдә.

– Чемпионатка әзерлек ничек барды?

– Таш юну эшенең нечкәлекләренә мине колледжыбыз укытучысы Наил Шәфыйкович Галимуллин өйрәтте. Һәр эшнең үз җае бар бит. Махсус технологияне белергә, нәрсәдән башларга, ничек тәмамларга икәнен аңларга кирәк – алайса таш ярылырга мөмкин. Иң кыены – почмакларны тигезләү, монда аеруча пөхтәлек таләп ителә... Беренче елда бик авыр булды, әмма әкренләп күп нәрсәгә өйрәндем. Безнең эштә дә зәркәнчеләрнеке кебек үк сабырлык кирәк бит.

– WorldSkills Russia биреме катлаулы идеме соң?

– Көтелмәгәнрәк булды. Биредә без нигездә табигый известьташны эшкәртәбез. Ярышта да известьташ иде, әмма ул йомшаграк булып чыкты. Аерма шундук сизелә. Әз генә катырак бассаң – ярылырга мөмкин. Тик йомшакны эшкәртүе дә җиңелрәк, юнырга вакыт та азрак китә. Һәр таш белән билгеле бер моментны «тотып» алу зарур, һәркайсының үз характеры.

– Конкурс биреме нидән гыйбарәт иде?

– Финалда таштан архитектура скульптура орнаменты ясарга кирәк булды. Бәйгедә биремнәр ел саен катлаулана бара, һәм чемпионатка әзерлек чорында без моны исәпкә алдык.

– Көндәшләрегез ничегрәк эшләде?

– Көндәшләр бик көчле. Анда бер инглиз бар иде – ул конкурстан тыш катнашты – аның эше миңа бигрәк тә ошады. Башкалар да югары дәрәҗә күрсәтте. Мөгаен, шуңа да җиңүем минем өчен көтелмәгәнрәк булды. Мин үзем дә шаккаттым, диярга була.

– Бер елдан син колледжны тәмамлыйсың. Аннары нишләргә исәбең?

– Дипломымда «Бина һәм корылмаларны файдалану буенча өлкән техник» дип язылачак. Аннары югары уку йортына читтән торып укырга керәчәкмен. Әлбәттә инде, архитектура-төзелеш университетын сайладым.

– Бүгенге мәктәп балаларына нинди киңәш бирер идең? Аларга эшче һөнәрләрне сайлау кирәкме?

– Хәзер эшче һөнәрләренә ихтыяҗ зур. Тормышта да бу күнекмәләрнең кирәге чыкмый калмас. Әмма минем танышларымның күпчелеге ни өчендер шундук югары уку йортына керергә тырыша. Мин колледжга 11 сыйныфтан соң кердем. Әлбәттә, укытучыларым минем колледжны сайлавыма гаҗәпләнде. Әмма минем ул чакта ук фикерем нык иде. Техникум һәм колледжлар күбрәк практикага юнәлтелгән. Моңа эш бирүчеләрнең дә бәясе югары, минем үземнең дә күңелемә ятышлы. Мәктәпне тәмамлаучы яшьләргә махсус урта белем алырга киңәш итәм. Карар кабул итүне 11 сыйныфка калдырырга кирәкми, 9 сыйныфтан соң ук сайлау зарур. Яшьтәшләре мәктәптә вакыт уздырганда, алар инде һөнәр үзләштерәчәк. Аннары инде шул профильдәге югары уку йортына керергә була, анда беренче курсларда укып тормыйсың.

– Сезнең колледж WorldSkills хәрәкәтенә кушылганнан бирле мәгариф системасы күпкә үзгәрдеме?

– WorldSkills барыннан да элек безнең укуга мөнәсәбәтебезне үзгәртте. Яхшылап әзерләнү, күнекмәләр ясау өчен өстәмә стимул барлыкка килде. Ә укыту бездә һәрвакыт югары дәрәҗәдә. Безнең колледж студентлары югары бәяләнә – эшкә урнашу проблемасы бөтенләй юк. Беркайчан да төзүдән туктамаячаклар, шунлыктан бу һөнәрнең киләчәге дә бик өметле.

– Таш юну эшендә камилләшүеңне дәвам итәчәксеңме?

– Әлегә фаразларга иртәрәк. Эшчәнлекнең бу төре шактый сирәк очрый, тик мин аның киләчәктә киңрәк таралуына өметләнәм.

– Эш тәкъдим итүчеләр юкмы соң әле?

– Юк әлегә.

– Ә күршеләреңнең таштан берәр матур әйбер ясауны үтенгәне юкмы?

– Булды андый моментлар да. Тик вакыт юк бит! Мин үзем Теләче районыннан, ә авылда эш гел күп инде ул. Билгеле, киләчәктә берәр нәрсә ясап карарга була. Минемчә, әгәр таланты һәм осталыгы бар икән, андый кеше беркайчан да тик ятмый.

Анфиса Җәләлова, Казан педагогика колледжы директоры:

– Безнең колледж WorldSkills Russia чемпионатында 2014 елдан бирле катнаша. «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбиячесе» компетенциясе беренче тапкыр 2014 елда Казанда икенче милли чемпионатта кертелгән иде, әмма әле WorldSkills International исемлегендә юк. Әмма бу безгә кирәкле стандартларга яраклы рәвештә конкурс биремнәре өчен һөнәри модульләр эшләргә комачауламады – әлеге компетенция буенча үзләрендә WorldSkills ярышлары үткәрелгән кайбер Европа илләре тәҗрибәсе ярдәм итте. 2015 елдан чемпионатта «Башлангыч сыйныфларда укыту» компетенциясе буенча катнашабыз, алдынгы урыннарда торабыз. Әлеге белгечлекләр абитуриентларны да, эш бирүчеләрне дә кызыктыра. Менә инде өч ел буе алар буенча конкурс бер бюджет урынына 9 кеше тәшкил итә.



Наталья Китаева, Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы директоры:

– Телеком һәм IT-тармаклар җирле хезмәт базарында аеруча таләп ителгән һөнәрләр өчлегенә керә, һәм бу белгечләргә ихтыяҗ һаман арта барачак. 2015 елның декабрендә безнең техникум базасында Мәгълүмати һәм аралашу технологияләре өлкәсендә халыкара компетенцияләр үзәге төзелгән иде. Бүген инде безнең мәгариф программалары эчтәлегенә студентларыбызга WorldSkills International таләпләренә җавап бирергә мөмкинлек бирә торган модульләр кертелгән. IT-компетенцияләр буенча чемпионатның барлык этапларында да безнең шәкертләр югары нәтиҗә күрсәтте. Ә Павел Фадеев һәм Андрей Дюбанов хәзер Кореядәге SamsungSkills укыту үзәгендә әзерлек үтә, алар Абу-Дабида узачак WorldSkills International-2017 чемпионатында «Мобиль робототехника» компетенциясендә Россия данын яклаячак.

Алексей Старостин, «Казан» Халыкара аэропорты» ААҖ генераль директоры:

– Көчлерәк буласың килсә, иң шәпләр белән ярыш, диләр. Чемпионатта «Һава транспортында сервис хезмәте күрсәтү» компетенциясендә безнең көндәшләребез – башка төбәкләрдән килгән яхшы әзерлекле командалар. «Казан» Халыкара аэропортында яңа хезмәткәрләрне «Теркәү агенты» һәм «Авиация иминлеге хезмәте инспекторы» юнәлешләре буенча әзерләү программалары WorldSkills таләпләренә һәм стандартларына тулысынча җавап бирә. Без бу ярышларда инде икенче ел катнашабыз һәм яхшы нәтиҗәләр күрсәтәбез.

Илдар Гыйниятуллин, Буа ветеринария техникумы директоры:

– WorldSkills Russia – һәрвакыт бик киеренке көрәш ул, әмма без моңа әзер. «Ветеринария» компетенциясендә чемпионатның төбәк этабындагы барлык биремнәр безнең студентлар өйрәнгән модульләргә тулысынча туры килә иде. Безнең техникум республиканың агросәнәгать секторы өчен ветеринария фельдшерларын әзерли. Без эш бирүчеләр – эре агрохолдинглар һәм аерым фермер хуҗалыклары белән элемтәдә торабыз. Алардан безгә бик күп гариза керә.

Илгиз Җәләлов, Дементьев исемендәге Казан авиация-техника колледжы директоры:

– Ерак авиациянең перспектив авиация комплексы (ПАК ДА) Горбунов исемендәге Казан авиация заводына титаник оборона заказы перспективаларын ача. Безнең алда авиатөзелеш өчен эшчеләргә һәм белгечләргә һөнәри юнәлеш бирү, сыйфатлы белгечләр әзерләү бурычлары тора. Без укыту программаларына төзәтмәләр керттек, һәм хәзер алар заманча инновацион технологияләргә һәм һөнәри әзерлекнең бөтендөнья стандартларына туры килә. Яңа компетенцияләр үзләштерелде, практика сәгатьләре күләме арттырылды, лаборатория-җитештерү базасы яңартылды. Колледж участоклары «Яшь һөнәрмәндләр» чемпионаты таләп иткән DMG MORI, HAAS, Fanuc фирмалары станоклары белән җиһазландырылган.

Илдар Ганиев, Чаллы политехника колледжы директоры:

– Былтыр безнең колледжны тәмамлаучы милли җыелма составында Сан-Паулуда (Бразилия) Worldskills Competition-2015 чемпионатында катнашкан иде. Киләчәктә дә экспертлар комиссиясен югары нәтиҗәләр белән таң калдырырга җыенабыз. Кирәкле җиһазларыбыз булмаса да, без сынатмыйбыз. Мәсәлән, WorldSkills чемпионаты кысаларында «СПИ булган станокларда токарлык эшләре» компетенциясендә эшләр башкарыла торган бер генә станогыбыз да юк. Шулай булса да, өч ел дәвамында призлы урыннар алабыз. Һәм инде моны очраклы җиңүгә санап булмый. Кирәкле җиһазларыбыз кайчан да булса барыбер кайтартылыр, дип өметләнәбез.

Александр Проснев, Казан төзелеш колледжы директоры:

– Безне тәмамлаучыларның 90 проценттан артыгы үз белгечлеге буенча эш таба. Дисциплиналар программасы, шулай ук уку һәм җитештерү практикалары WorldSkills дәрәҗәсенә тәңгәл килсен өчен, без аларга өстәмә темалар керттек. Безнең студентларыбыз Вениамин Петров һәм Айрат Вафин «Плитка белән тышлау» компетенциясендә Россия милли җыелмасының киңәйтелгән составына керә. Көндәшләрнең дә көче һаман арта. Аларның осталыгы һәм җиңүгә омтылышы сизелеп тора. Ел саен без конкурсантларны әзерләү программаларын катлауландырабыз, һәм бу безгә колледжга беркетелгән компетенцияләр буенча позицияләребезне сакларга мөмкинлек бирә.

Раушания Сәүбәнова, Казан халык сәнгати һөнәрчелеге техникумы директоры:

– WorldSkills хәрәкәтендә без инде өченче ел катнашабыз. Республика җитәкчелеге матди-техник базаны ныгытуда, кирәкле кораллар һәм чыгым материаллары алуда ярдәм итте. Безнең барлык җитештерү өйрәтү мастерларыбыз – югары квалификацияле белгечләр, шунлыктан студентларны чемпионатка әзерләү өчен шартлар тудырылган. Аңа гына да түгел. Без халык сәнгать һөнәрчелеген үстерү, саклау һәм торгызу буенча дәүләт программасында да актив катнашабыз. Безнең техникумда уку музей фондлары каталогларындагы татар һәм рус милли бизәнү әйберләрен өйрәнүне һәм аларны әзерләүнең югалган технологияләрен торгызу белән шөгыльләнүне таләп итә.

PRESSA.RU

АКЫЛНЫ ЭШКӘ **ҖИГИК!**

Автор:
Катерина Котова

Ике ир-ат аудитория каршында тормышта очрый торган ситуацияне уйнап күрсәтә. Михаил – «официант». Илдар – кыйммәтле ресторан «клиенты», һич булмаган хәл – аңа салкын аш биргәннәр.
– Бу аш салкын килеш биреләме? – дип сорый «клиент». Һәм менә монда иң кызыгы башлана да инде...

ЭШЛИСЕҢ ИКӘН, ИЛҺАМ БЕЛӘН

Мәскәүдән килгән профессиональ бизнес-тренер Наталья Самоукина Татарстан дәүләт хезмәткәрләре белән инде беренче мәртәбә генә дәресләр үткәрми. Һәм менә бүген дә ул тыңлаучылардан тренингта катнашучыларның гамәлләренә бәя бирүләрен сорады. Катнашучының үз-үзен тотышы нинди типка карый: ул пассивмы, үз-үзенә ышанган кешеме яисә агрессия күренәме? Сез ничек уйлыйсыз?

«Хакимияткә таянмый идарә итү» тренингы муниципаль район җитәкчеләренә үз хезмәткәрләрен мотивацияләү өчен шактый конкрет ысуллар бирергә тиеш. Гади генә итеп әйткәндә, күзләр янып торырлык яңа хезмәт батырлыкларына рухландырырга. Бурыч җиңелләрдән түгел, әмма КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбендә моңа өйрәтәләр.

ИСКЕЛЕККӘ КАРШЫ УКУ

Бүген дәресләрнең беренче көне. Аудиториядә буш урыннар күзгә чалынмый. Парта артында утырган «студентлар» гади түгел, дип әйтик – муниципаль берәмлек подразделениеләре җитәкчеләре һәм урынбасарлары. Укытучы мөнбәре артында – ТР Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенең оештыру бүлеге мөдире Алексей Панкратов. Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча әйдәп баручы экспертның лек-

Фотолар КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе архивыннан алынды

циясе дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү буенча яңа курсны ачып җибәрде. Тәнәфестә үземнең төп соравымны бирү өчен, аларның берсен тотып алам: бу укулар – көнүзәк ихтыяҗмы яисә югары җитәкчелекнең теләге генәме?

– Әлбәттә, ихтыяҗ! – дип җавап бирә Руслан Никонов. – Үзем өчен күп нәрсә алырмын, дип ышанам. Халыкта, шул исәптән үсеп килүче буында да, ришвәтчелекне кабул итмәүне тәрбияләү механизмнары турында күбрәк беләсем килә.

Руслан Кама Тамагы муниципаль районыннан. Администрациядә кадрлар эше буенча оештыру бүлеге башлыгы урынбасары вазыйфасын били. Коррупциягә каршы тору сораулары да аның карамагында. Аның өчен бу икенче квалификация күтәрү курслары – узган елны КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбенә ике көнлек курсларга килгән булган. Укуларның эшендә көчле этәргеч булуын һәм яңа офыклар ачуын таный.

– Гадәттә дүшәмбедән шимбәгә кадәр гаять зур эш күләме, башны күтәрергә дә вакыт юк. Еш кына яңалыкларны күзәтеп барып булмый – көч тә, вакыт та җитми. Мондый курслар кешене яңа белем дәрәҗәсенә күтәрә, югары планка куя һәм үзеңне күрсәтергә мөмкинлек тудыра. Һәм тагын башыңны тәртипкә китерергә, башка районнардан килгән коллегаларың белән аралашырга, тәҗрибә уртаклашырга мөмкинлек бирүче менә дигән форсат, эмоциональ бушану.

РОССИЯДӘ ИҢ АЛДА

Бүген КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе башкара торган эш күләме гаҗәпләндерә. Узган ел нәтиҗәләре буенча, биредә 5,5 меңнән артык кеше курслар үткән (мәгълүмат өчен: республикада дәүләт муниципаль хезмәткәрләренең гомуми саны – 12 меңгә якын кеше). Бары тик Мәскәү Хөкүмәтенең Дәүләт хезмәте һәм кадрлар идарәсендә генә әлеге күрсәткеч моңардан югарырак. Аңлашыла ки, анда бюджетлар да башка. Шулай да тәҗрибә алу өчен Мәскәү өлкәсе Хөкүмәте Казанга килә. Мәскәү яныннан килгән коллегаларыбызга, чыннан да, биредә өйрәнерлек нәрсәләр бар.

Бүген КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбендә илебезнең башка күп кенә вузларында дәүләт хезмәткәрләрен укыту өчен кулланыла торган типлаштырылган 72 сәгатьлек программадан баш тарттылар.

– Без лекторлар килеп, күңелсез генә материалларын укып китә торган сәгатьләр санынннан баш тарттык, – дип аңлата КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең

PRESSA.RU

югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – Без республика ихтыяҗлары өчен җайлаштырылган программалар төзедек.

Яңа 50 сәгатьлек курс нәкъ бер атнага исәпләнгән. Эш өч блок буенча алып барыла: гомуми, махсуслаштырылган, тренинглар блогы. Беренче көн – база белемнәре. Бу республикадагы теләсә кайсы хезмәткәрнең эше өчен кирәкле белемнәр: дәүләт сәясәте нигезләре; тынычлык һәм татулыкны булдыруга юнәлдерелгән конфессияара әчке сәясәт; коррупциягә каршы эшчәнлек; Стратегия – 2030. Аннан соң иң кызыклысы башлана: махсуслаштырылган белемнәр. Укытучылар сыйфатында – республиканың әйдәп баручы практиклары: республика муниципаль берәмлекләре башлыклары, ТР Президенты Аппараты, ТР Министрлар Кабинеты Аппараты, ТР Прокуратурасы, республика министрлыклары вәкилләре һәм башкалар. Алар конкрет сорауларны һәм вазгыятьләрне тикшерәләр, аерым мисалларны карыйлар: дәүләт хезмәткәрләре үз эшләрендә нәрсәләргә «абынырга» мөмкиннәр. Әлбәттә, тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Курсны тренинглар блогы йомгаклый.

«АЛАР – БЕЗНЕКЕ, ҺӘМ БЕЗ АЛАР ӨЧЕН ЭШЛИБЕЗ!»

– Кайвакыт без гражданнарның халыкка дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгать калмаулары, хезмәткәрләр белеменең тиешле дәрәҗәдә булмавы турында ишетәбез, – дип сөйли Игорь Привалов. – Эш күләменең бик зур булуы кадрларның гел алмашынып торуына китерә һәм безгә дәүләт һәм муниципаль идарә өлкәсе өчен яңа белгечләрне һаман-һаман әзерләп торырга туры килә. Без дәүләт хезмәтенә күптәннән килгәннәр белән дә, үз эшчәнлеген яңа гына башлап җибәргәннәр белән дә эшләргә шатбыз. Соңгы вакытларда муниципаль хезмәттә эшләргә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итәргә теләүчеләрнең арта баруы сөендерә. Шуны ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре турында да әйтеп була.

Белгечләрнең һөнәри әзерлеге һәм үз эшенә туры килү дәрәҗәсен, шул исәптән аларның ришвәтчелеккә юл кую-куймау ихтималлыгын аңларга, беренчел тестлаштыру булышa. Аны, мәсәлән, дәүләт һәм муниципаль өлкәдә эшли генә башлаган – вазыйфаларында бер елдан кимрәк хезмәт куйган хезмәткәрләр – «Дәүләт хезмәте нигезләре» һәм «Муниципаль хезмәт нигезләре» курсына килгән барлык тыңлаучылар да мәҗбүри тәртиптә уза. Тест җитеп бетмәгән белемнәрне ачыкларга һәм уку процессында әлеге «тапларны» бетерергә мөмкинлек бирә.

– Беренчел тестлаштыру шуны күрсәтә: артында җитәкчелек итү буенча олы тәҗрибәсе булган кеше дә төп, нигез белемнәргә мохтаҗ, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе директоры урынбасары Наталья Аксенова. – Белемнәрне шулай итеп тикшереп алу безгә җитешсезлекләрне күрергә һәм файдалы программа төзергә ярдәм итә. Йомгаклау тестлары уңай динамиканы күрсәтә, бу безнең дөрес юнәлештә хәрәкәт итүебезне аңлата дигән сүз.

АШ БЕЛӘН НӘРСӘ БУЛДЫ СОҢ?

– Менә инде ун ел без дәүләт хезмәткәрләре белән тренинглар үткәрәбез, – ди КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе директорының беренче урынбасары Галина Маштакова. – Эшебезне башлап кына җибәргән мәлләрдә без нигездә бизнестан алынган кейсларны кулланcак, бүгенге көндә дәүләт хезмәтенең үзенчәлегенә бәйләнеше булган күнегүләр күбәйде. Шоуны хәтерләткән тренинглар икенче планда калды – безне күбрәк конкрет ысуллар, шул исәптән үз-үзеңне ышанычлы тоту инструментлары кызыксындыра. Мәсәлән, әгәр синең эшең бик күп икән, стрессларга ничек түзәргә? Тискәре йогынты булганда үзеңне ничек тотарга? Баш тартсалар, үзеңнекенә ничек ирешергә?

Быел квалификация күтәрү программалары челтәренә тагын бер яңалык кертелде – анда тренинглар аерым блок булып кертелгән. Катнашучылар үзләренә нинди компетенцияләр җитеп бетмәвен үзләре билгелиләр һәм, шуннан чыгып, барасы килгән тренингларны сайлыйлар.

Дәүләт хезмәткәрләре арасында мондый дәресләрнең ни дәрәҗәдә популяр булуларын аңлау өчен, аларга күпме кеше йөрүен карарга кирәк. Әйтик, министрлык җитәкчеләре тренингы расписаниесенә «Нәтиҗәле киңәшмә», «Гавами чыгыш ясау», «Эмоциональ талчыгу» кебек темалар өстәлде. Планлаштырылган бер төркем урынына өч төркем җыелды. Тренинг барышында тренер катнашучылар белән бергә төрле вазгыятьләрдән чыгу юлларын эзли, эштә еш кабатлана торган үз-үзеңне тоту модельләрен тикшерә.

Бу урында нәкъ менә югарыда аталган «ашны» искә төшерү урынлыдыр.

– Еш кына үзебезне ышанычлы тотабыз кебек тоела, ә чынлыкта исә без агрессия күрсәтәбез, моның белән тирә-юнебездәгеләрдә дә җавап агрессиясен уятабыз, – ди Галина Маштакова. – Клиентның: «Бу аш салкын килеш биреләме?» – дигән соравы моңа ачык мисал. Официант ашның салкын килеш бирелергә тиеш түгеллеген белә. Иң кызыгы – клиент та белә. Нигә дип ул бу сорауны бирә соң? Чөнки ул инде «сугышка» әзер һәм вазгыятьне дөрләтеп җибәрмәкче.

Мондый очракларда ничек бар, шулай, ачык итеп әйтергә кирәк – җитәкчеләр нәкъ менә шулай эшләргә тиеш тә: «Син миңа хисап китердең, анда өченче биттә ялгыш бар – төзәт, зинһар». Менә монысы үзеңне ышанычлы тоту була да инде. Хезмәткәргә: «Син миңа монда нәрсә китердең!?», – дияргә кирәкми. Аш белән булган хәлдә дә шулай.

Акылны эшкә җиксәң, чүп-чарны да акчага әйләндерергә мөмкин!

ҮСЕШ НОКТАЛАРЫ

– Дәүләт органнары эшендә муниципалитетлар арасында үзара эш итү кебек мөһим момент бар, – ди Игорь Привалов. – Аерым бер районның дәрәҗәсен «күршеләрдән» аерып үстереп булмый. Коммуникацияләр бер-берсенә шулкадәр үрелгән ки, әгәр башлык эшендә боларны исәпкә алмый икән, аның теләсә кайсы стратегиясе уңышсызлыкка дучар булачак.

Узган елны КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе, «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе белән берлектә, республика башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре һәм муниципаль берәмлек башлыклары өчен «Нәтиҗәле идарә: Стратегия. Гамәлләр. Нәтиҗәләр» дип аталган белем бирү программасын гамәлгә ашырды. Программаны тыңлаучыларны агломерацияләр буенча тупларга карар кылдылар. Курс дәвамында алар үз проектларын эшләделәр – барысы да «Стратегия – 2030» кысаларында. Бары тик актуаль булган юнәлешләрне генә модельләштерделәр. Мәсәлән, ике күрше районда чүп-чарны җыяр урын юк, ә өченчесендә чүп-чар эшкәртү станциясе төзелеше өчен кулай территория бар. Әгәр акылны эшкә җиксәң, чүп-чарны да акчага әйләндерергә мөмкин!

– Мондый проектлар биргән төп нәрсә – команда карарлары эшләү, ихтимал куркынычларны исәпкә алу, үз коллегаларының ишетә белү күнекмәләрен формалаштыру, – дип саный Игорь Привалов. – Без программа тәмамланганнан соң, кире элемтәне күреп тә шатланабыз. Күп кенә район башлыклары үзләренә тапшырылган территорияләрне үстерүнең яңа, өстәмә мөмкинлекләрен күрүләре турында шалтыратып әйттеләр. Мин моны иң мөһиме дип саныйм! Алар үсеш ноктаtotal табалар. Без файдалы була алуыбызга куанабыз.

PRESSA.RU

ИСӘНМЕ, RASA!

Сезне әйбәт яңалык белән таныштырырга ашыгабыз: Татарстанда, КФУ базасында, исәбе буенча илдәге өченче RASA үзәге ачылачак. RASA (Russian-speaking Academic Science Association) – Рус телендә сөйләшүче галимнәрнең халыкара ассоциациясе. Алар заманында Россиядән киткәннәр, ә менә хәзер бездәге фәннең үсешенә үзләреннән өлеш кертергә телиләр.

Әлеге оешманың фәнни-тикшеренү буенча потенциалы бик югары дәрәҗәдә, шуңа да Казанда RASA-ның әйдәп баручы вәкилләрен җыйган «Трансляцион медицина, аның бүгенгесе һәм киләгесе» Халыкара фәнни конференциясендә Үзәкнең ачылуы турындагы хәбәрнең игълан ителүе аеруча дулкынландыргыч мизгел булды.

Безнең корреспондент, галимнәр белән очрашып, аралашып, алардан фәндәге иң гаҗәеп ачышлар турында сорашты. Татарстанның фәнни-тикшеренү буенча потенциалы хакында да фикерләрен белеште.

Әзерләде:
Ольга Туманская

Фото: Ната Смирнова

Яман шешкә – авызлык

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Люба Вартиковски – Медицина фәннәре докторы, онкология һәм гематология өлкәсендәге белгеч. Ун елдан артык Яман шеш дәүләт институтында (Мериленд, АКШ) эшли. Шулай ук Рецепторлар һәм ген экспрессиясе лабораториясе тикшеренүләрендә катнаша. Фәнни кызыксынулары күпкырлы – нормадагы һәм яман шеш табылган нигез күзәнәкләрнең киң масштаблы геном характеристикасы.

Бүген без яман шеш китереп чыгаручы күзәнәкнең иң үзәгенә үтеп кердек. Без аның ни өчен резистент, ягъни һәртөрле даруларга тотрыклы булуын белә башладык. Традицион препаратларга гына түгел, ә иң яңа молекуляр терапиягә дә хәтта. Сүз уңаеннан: бу төр терапия АКШта онкологиядән вафат булучы халык санын 23 процентка киметергә мөмкинлек бирде. Бу «дулкын» әле башка илләрдә күтәрелеп өлгермәде – дарулар, тәртип буенча, иң башта һәрберсендә тиешле дәрәҗәдә тикшерү узарга тиеш. Тиздән алар Россиядә дә пәйда булыр, дип уйлыйм. Әмма эш моның белән генә чикләнми әле. Онкологик авыруларны дәвалауда тагын бер бик мөһим фактор бар: ике яклы юнәлешнең булдырылуы – авырудан – лабораториягә кадәр һәм киресенчә. Әгәр яман шеш дару тәэсиренә җавап бирми икән, димәк кабат лабораториягә юл тотасы була! Безгә шуңа да аерым бер рак күзәнәкләренең препаратка каршы тора алуын аңларга һәм, тиз арада реакция белдереп, авыруга өр-яңа терапия билгеләргә кирәк. Һәрбер кешенең күз уңында тоткан, персоналашкан медицинаның асылы шуннан гыйбарәт, бу хакта Казан университетында инде сүз башланды. Бу безгә, әйткәнемчә, яман шеш күзәнәкләренең табигатен, аларның резистентлыгының сәбәбен аңларга ярдәм итә, шулай ук үлем очракларын киметергә дә мөмкинлек бирә.

Сәяси яктан дистанцияләр булса да, безгә – галимнәргә – бердәм булып эшләү – зарури. Казанда моның өчен барлык мөмкинлекләр дә бар, коллегаларым инде эшне башладылар да. Мин монда беренче тапкыр, әйтергә кирәк, Татарстан фәненең югары дәрәҗәсенә шаккаттым. Татарстанда хөкем сөргән дустанә мөнәсәбәт, милли кысалардан, чикләүләрдән азат рәвештә хезмәттәшлеккә әзер булу – болары да искиткеч. Минем фәнни-тишеренү нәтиҗәләрем кызыксыну уятачак, һәм мин монда кирәк булачакмын икән, хезмәттәшлек итәргә дигән тәкъдимне рәхәтләнеп кабул итәргә әзермен.

Марска очарга җыенабыз

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Олег Гусев – Казан федераль университетының 2001 елгы чыгарылышыннан. Молекуляр биология өлкәсендә доктор дәрәҗәсен Японийдә – MEXT стипендияле программа кысаларында белемен күтәрергә килгәч ала. Япония Космик агентлыгы тарафыннан Космосның фән һәм тормыштагы урынын тикшерүгә багышланган Россия – Япония бердәм проектына чакырыла. Фәнни кызыксынулары өлкәсе – чагыштырма геномика һәм РНК транскрипциясен яраклашу биологиясе һәм биомедицинасында кулланып карап анализлау. Япониянең RIKEN тикшеру үзәгенең һәм KFU-RIKEN «Функциональ һәм гамәли геномика» уртак лабораториясенең фәнни җитәкчесе.

Япон технологияләре ярдәмендә без бүген космик очыш вакытында организмда бара торган генетик һәм аксым катнашында узучы процессларны бик җентекләп тикшерә алабыз. Аерым алганда, мускуллар атрофиясен өйрәнү буенча проектыбыз яңа сулыш алды. Космоста бу бик зур проблема – бер очыш дәвамында космонавтлар 10% кальций һәм 17% мускул массасын югалта. Бу процессларның ничек баруын аңлау һәм көйгә салу космос өчен генә түгел, ә гамәли медицина өчен дә гаять әһәмиятле.

Астробиология, ягъни космоста тормышның таралышын чикләүнең әһәмиятен аңларга омтылу белән бәйле махсус проектлар бар. Тере организмнарны ерак космик араларга ничек илтеп җиткерергә? Әйтик, Марска яки Венерага? Хәзерге вакытта аларны сусыз саклау буенча технологияләр эшләнә. Ә космонавтларга, чит планетага килгәч, нәрсәдән курыкырга кирәк – нинди дәрәҗәдәге тере организмнар радиация, йә булмаса башка эффектларга каршы торырга сәләтле? Космосны үзләштерү – бу искиткеч күп технологияләрнең комбинациясе дигән сүз. Шул исәптән, космонавтларның биоиминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча да.

Иң кырыс космик тәҗрибәләр җирдәге тере организмнарның космоста исән калуы белән бәйле, мөгаен. Аларны махсус капсулаларга урнаштыралар да ачык космоска чыгаралар, шуннан нинди үзгәрешләргә дучар булуларын күзәтәләр. Һәм, беләсезме, шундый организмнар бар: космик пространстводагы шартларга тотрыклы булу ягыннан алар потенциаль чит планета вәкилләреннән бер дә ким түгелләр. Әйтик, әкренйөрүчеләр (тихоходки) – бу әкәмәт микроскопик умырткасызлар бәләкәй аю балаларына охшаган. Йә булмаса, балык тотканда элмәккә киертә торган суалчаннар. Хәзер безнең игътибар үзәгендә – Африка озынборыны, аның личинкалары ачык космоста сусыз килеш дистә еллар яши ала!

Россиядә «акыллы башлар» һәрчак бар иде. Әмма алар элегрәк чит илләргә чыгып китү ягын карады – читтәге шартлар бездәгегә караганда яхшырак чөнки. Бәхеткә, бүген Татарстанда да алар өчен уңайлы шартлар тудырылды, һәм без, монда кайтып, нәтиҗәле эшчәнлек алып барырга әзер булган шактый көчле яшь галимнәрнең барлыгын беләбез. Казан федераль университеты күрсәткечләрнең шактые буенча әйдәп баручы дөнья уку йортларыннан калышмый. Аерым алганда, техник җиһазлау, махсус тикшеренүләр һәм партнерлар җәлеп итеп эшли торган проектларны да финанс ягыннан тәэмин итү буенча – болар бездә эшләнә.

Без хәзер республикада кызыклы тенденцияне күзәтәбез: фәнни проектлар, ниһаять, республиканың реаль ихтыяҗлары тирәсендә формалаша башлады. Мисал өчен, геномның этник үзенчәлекләре, билгеле бер авыруларның үзенчәлекләре һәм монда яшәгән уникаль организмнар, болар барысы да республиканың гамәли кызыксынуларын чагылдыра шикелле. Дөресен әйткәндә, болар – дөнья фәненең үсешендә дә мөһим урын алып торучы нигез мәсьәләләр. Элегрәк мондый багланышлар берән-сәрән очракны гына тәшкил итсә, хәзер без университетның максатчан рәвештә халыкара институтлар белән эшләүгә йөз тотуын ачыктан-ачык ассызыклап әйтә алабыз. Чит илләрдәге галимнәр белән хезмәттәшлек итү үзенең беренче җимешләрен дә бирә – студентларның һәм университет хезмәткәрләренең фикерләү дәрәҗәсе киңәя, алар тикшеренү өчен катлаулырак темалар сайлыйлар.

Трансляцион медицина – фәннәр чигендә торучы кызу үсештәге өлкә, максаты – диагностиканың, дәвалауның һәм тернәкләндерүнең яңа методларына фәнни ачышларны «лаборатория өстәленнән – туры авыруның ятагына» принцибы буенча кертүне тизләтү.

PRESSA.RU

Синтезланмаган кушылмаларның биологик, физик һәм башка хасиятләрен алдан күрәзә итеп кую мөмкинме? Хемоинформатика ярдәмендә – мөмкин. Бу химия, информатика, физика, математика һәм башка фәннәр чигендә торучы тиз үсә торган өлкә. Ул, мәгълүм күрсәткечләрне файдаланып, алдан фаразлап кую модельләрен булдырырга мөмкинлек тудыра. Алган нәтиҗәләргә таянып, без молекулаларның, реакцияләрнең һәм билгеләнгән үзлекле материалларның махсус юнәлтелгән синтезын башкарып чыга алабыз. Хемоинформатика барлык даруларны эшләгәндә дә кулланыла, чөнки тәҗрибә нәтиҗәсендә алынган күрсәткечләрнең күләме шулкадәр зур, кеше аларны үзлегеннән генә эшкәртеп өлгерә алмый.

– Мин КФУның, безнең белән хезмәттәшлектә булып, фәнне үстерүгә һәм хемоинформатика өлкәсендә укытуны оештыруга зур өлеш кертүенә шатланам. Монда илдәге беренче магистрлык программасы эшләнде.

Хемоинформатика ысулларын куллану даруларга һәм материаллар җитештерүгә киткән чыгымнарны сизелерлек дәрәҗәдә киметү мөмкинлеге бирә. Әлегә бер даруны җитештерү өчен киткән чыгымның күләме – лабораториядән алып даруханәгә кадәрге этапта – 1,5 млрд долларны тәшкил итә. Хәлләр уңай борылыш алган очракта, хемоинформатика ысуллары инде башлангыч этапта ук бюджетның өчтән бер өлешенә кадәр экономия ясауга китерәчәк. Шул ук вакытта хемоинформатиканы файдалану фармацевтика сәнәгате белән генә дә чикләнми.

Мин КФУның, безнең белән хезмәттәшлектә булып, фәнне үстерүгә һәм хемоинформатика өлкәсендә укытуны оештыруга зур өлеш кертүенә шатланам. Монда илдәге беренче магистрлык программасы эшләнде. Аңа тиңдәш программа хәзер Мәскәү физика-техника институтында барлыкка килде, бу төр программаны Петербург университеты кулланылышка кертеп җибәрергә җыена, әмма Казан, һичшиксез, Россиядә лидер булып кала бирә. Биредә кызыксыну да көчле, җитәкчелекнең булышлыгы да үз ролен уйный.

Күрәзәгә сәләтле фән

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Александр Варнек – Россиядә физик химия өлкәсендә белем ала һәм биредә үк доктор дәрәҗәсенә ия була. Егерме елдан артык Страсбург университетында эшли, теоретик химия профессоры. Университетта хемоинформатика лабораториясе ачу тарафдары була, хәзер шул лабораторияне һәм хемоинформатика буенча дөньядагы беренче магистратураны җитәкли. 2011 елдан КФУ белән хезмәттәшлек итә – аның җиңел кулы белән бу фәнни юнәлеш Казанда да пәйда булды.

Фото: Ната Смирнова

Терминатор? Биоробот!

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Виктор Ерохин – Физика-математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә СССР ФАнең Кристаллография институтында 1990 елда ия була. Хәзерге көндә Италиянең Парма университеты профессоры, Италиянең фән буенча Милли советының өлкән фәнни хезмәткәре. Фәнни кызыксынулары өлкәсе – кеше нерв системасының кайбер функцияләрен кабатлаучы модельле тәҗрибә җайланмалары эшләү һәм өйрәтергә мөмкин булган яңа заман компьютерларын җитештерү. Казанда КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты каршында ачылган «Электрон синапс» ачык лабораториясе белән җитәкчелек итә.

Миннән еш кына биороботларның пәйда булуын тагын күпме көтәргә кирәк, дип сорыйлар. Әгәр сүз Терминатор турында икән, якын киләчәктә түгел әле. Ә менә без бүген күз алдына да китереп карамаган башка нидер турында булса, аның якын арада булуы бик мөмкин. Сезгә, бәлки, көлке тоелыр, әмма ике ай элек кенә миңа «Компьютерларны күгәректән үстерү» дип аталган зур Европа проектында катнашу мөмкинлеге тиде. Беләсегез килсә, күгәрек – әллә никадәр бурычны хәл итә белә торган бик акыллы җан иясе ул. Аны хәтта биоробот дип атарга да мөмкин булыр иде, дөрес, эшчәнлеге акрын бара-баруын. Бу проекттан ни килеп чыгачагын хәзерге этапта әйтеп бирү шактый авыр. Галимнәр үз алдына ниндидер максат куйганда, гадәттә, «караңгыда капшанып бармыйлар», ә билгеле бер юнәлештә хәрәкәт итәләр. Һәм шул хәрәкәт барышында, эзләнү вакытында башка кызыклы нәрсәләргә дә тап булалар, яңа өлкәләрдә тикшеренү алып бара башлыйлар. Биороботлар мәсьәләсендә дә шулай булырга бик мөмкин.

«Ясалма интеллект» өлкәсендәге соңгы казаныш – күптән түгел эшләнгән мемристор дип аталучы җайланма. Бу иң соңгы фәнни казаныш! Ул үзенең компьютер туганнарыннан «акыллырак», һәм кешенең нерв системасының, төгәлрәк итеп әйтсәк, синапсның кайбер функцияләрен кабатлый алуы белән аерылып тора. Эш шунда ки, компьютер өчен әзерләнгән мәгълүмат пассив рольдә була: машина аны «хәтерендә калдыра», әмма әлеге күрсәткечләр компьютерның үзлекләрен берничек тә үзгәртми. Ә кешенең баш мие башкача көйләнгән – ул өйрәтүне кабул итәргә әзер. Аның күзәнәкләре мәгълүматны кабул итү, саклау өчен генә түгел, ә эшкәртү өчен дә яраклаштырылган. Баш миенең «акыллы» структур берәмлеге – синапс. Бу бер нейронның, сигнал тарату максатыннан, икенче нейрон белән кисешү ноктасы. Аның үткәрү мөмкинлеге үзен куллану ешлыгы һәм дәвамчанлыгы нәтиҗәсендә көчәя ала. Өйрәнү сәләтенең нигезендә шул ята да инде. Узган елны Hewlett-Packard* лабораториясе, беренчеләрдән булып, бер катламлы перцептронны – объектларны танып классификацияләү системасын кулланылышка кертү турында мәкалә бастырды. Алар белән беррәттән, без дә үзебезнең эшчәнлекне алып бардык, хәзерге вакытта чираттагы фәнни ачышны игълан итәргә әзерләнәбез – бер катламлысына караганда катлаулырак бурычларны хәл итү мөмкинлегенә ия булган ике катламлы перцептронны әзерләп җиткерү.

Мин Казанда мәгълүматны табигый рәвештәгесенә охшаш итеп эшкәртү юнәлешендә тикшеренүләр алып бара торган фәнни төркемне җитәклим. Без монда кирәк, шулай икән – димәк, эшлибез! Шәһәрнең фәнни потенциалы бик югары. Узган елны Парма һәм Казан университетлары арасында уртак аспирантлык программасы оештырылды. Беренче «карлыгачыбыз» – хәзерге вакытта Пармада тикшеренү эше алып баручы КФУ студенткасы. Алга таба хәлләр тагын да яхшырачак, дип ышанам.

PRESSA.RU

«ЩЁЛКОВО АГРОХИМ» – ҖИТЕШТЕРҮНЕ ТИЗЛӘТҮГӘ ТАБА ТАЙПЫЛЫШСЫЗ КУРС

Һәрбер эре компаниянең үз тарихы, үз юлы бар. Әмма күп еллар элек «Щёлково Агрохим» АҖнә нигез салган һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе булган Салис Добай улы Каракотов сайлаган юл аеруча тәэсирләндерә. Ул даими рәвештә, әлеге юлдан тайпылмыйча, диверсификациягә йөз тота – бу исә компаниягә аграр бизнеста яңадан-яңа тармакларны колачларга мөмкинлек бирә. Колачларга гына да түгел, ә анда күзгә күренеп торган лидер булырга.

Каракотов С.Д.

ТӨП КАЗАНЫШЛАР

«Щёлково Агрохим» – яшьлекнең тәҗрибә белән исәпләшүенә мисал ул. 1998 елда нигез салынган компания берьюлы ике предприятиенең традицияләренә һәм фәнни базасына таяна – ВНИИХЗСРның Щёлководагы филиалына һәм «Щёлково Агрохим предприятиесе» ААҖнә. Һәм ике дистә елдан азрак эшчәнлек алып бару вакытында ук инде компания югары нәтиҗәләргә ирешә. Бүген РФ һәм БДБ төбәкләрендә аның 40тан артык вәкиллеге эшли.

Үсемлекләрне саклау чаралары һәм агрохимикатлар, бөртеклеләр, кузаклылар һәм шикәр чөгендере орлыгы җитештерүче иң эре компанияләрнең берсе, тиз арада илебезнең географик чикләрен узып, якын һәм ерак чит илләрнең аграрийлары белән актив хезмәттәшлек итә башлый. Гаҗәп тә түгел, компания тәкъдим иткән нәтиҗәле препаратлар агрономиядә иң катлаулы бурычларны да хәл итү һәм җитештерүдә югары рентабельлелеккә ирешү мөмкинлеге бирә.

Озак еллар инде компания Орёл өлкәсенең иң эре авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе – «Дубовицкое» ҖЧҖнә кураторлык итә. Җитди инвестицияләр, алдынгы технологияләр, фәнни яктан нигезләнгән җир эшкәртү системасы… Нибары берничә ел эчендә «Дубовицкое» туган төбәгендә генә түгел, илнең башка почмакларында урнашкан хуҗалыклар өчен дә үрнәк булырга өлгерде.

2011 елда компания чөгендер игү буенча алга таба зур адым ясады. Воронеж өлкәсендә «Бетагран Рамонь» шикәр чөгендеренең вакланган орлыкларын җитештерү буенча завод эшли башлады. Предприятиенең җитештерү куәте елына 400 мең чәчү берәмлеге тәшкил итә.

Компания вак авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр турында да онытмый. Бакчачылар өчен махсус рәвештә «Октябрина Апрелевна» дигән сәүдә маркасы белән препаратларны югары сыйфатлы итеп ваклап төреп сату оештырыла.

2014 елдан башлап «Щёлково Агрохим» терлекчелек юнәлешен үстерүгә зур көч куя башлады. Нәтиҗәсе – «Бетагран Липецк» ҖЧҖндә терлекчелекне югары нәтиҗәле итеп үстерү өчен мөгезле эре терлекнең элиталы токымнары яралгыларын җитештерү буенча Россиядәге беренче селекция-генетик үзәге ачылу.

ЯҢАЛЫКЛАР

2016 елдан башлап «Щёлково Агрохим» Италиянең авыл хуҗалыгы техникасы җитештерү буенча ике заводының – Projet һәм Mascar*ның рәсми дилеры. Эшчәнлекне уңышлы алып бару өчен Воронеж өлкәсендә запас частьларның һәм сервис хезмәтенең махсус склады оештырылган.

Моннан тыш, 2016 елдан башлап, компания Мәскәү өлкәсенең Щёлково районында Үсемлекчелек буенча фәнни-технологик үзәге төзелешен инвестицияли. Үзәк территориясендә басу-кыр культураларын демонстрацияләү өчен авыл хуҗалыгы базасы булдыру, 2 гектар мәйданда бишенче буын теплица комплексы, шулай ук күпьеллык җиләк-җимеш культуралары булган бакча комплексы төзү планлаштырыла. Ул тикшеренүләр эшчәнлеген, конференция, семинарлар, очрашулар, симпозиум һәм күргәзмәләр үткәрү урынына әйләнәчәк.

* Projet и Mascar – Италиянең авыл хуҗалыгы техникасы җитештерүче заводлары.

«Щёлково Агрохим»ның Татарстан Республикасындагы вәкиллеге:
Казан шәһәре, Красносельская урамы, 51 а
Тел.: (843) 562-34-85; 562-22-83
kazan@betaren.ru www.betaren.ru

ЩЕЛКОВО АГРОХИМ
российский аргумент защиты

Реклама

Реклама

КАДРЛАРГА ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРГӘ

2000нче еллар башында, Россиянең авыл хуҗалыгын торгызу һәм үстерү программасы кысаларында, биш авыл хуҗалыгы предприятиесе – «Маяк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, «Үзәк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, «Яңа юл» коттедж бистәсе, «Таң» крестьяннар хуҗалыгы, Тельман исемендәге крестьян хуҗалыклары ассоциациясе – берләште. Сүз аларны исән калдыру турында бара иде. Нәтиҗәле инвестицион сәясәт алып баруы һәм акыллы стратегиясе аркасында, «Авангард» ҖЧҖ бүген республиканың иң эре агросәнәгать комплексларының алгы сызыгында бара.

2006 елның ноябрендә компаниягә «Чишмә» ҖЧҖ килеп кушылды. Ул үзе Чуваш Республикасы Цивиль районының биш хуҗалыгын берләштергән иде: «Коммунар», «Дуслык», «Таң», «Юлдаш» АХҖК һәм «Цивильское» ЯАҖ. «Авангард» ҖЧҖнең филиалы барлыкка килде – «Цивиль Беконы», һәм дуңгызларны симертү өчен яңа комплекс төзелде. 2011 елның апреленнән «Авангард» ҖЧҖ – «Ак Барс» холдинг компаниясе структурасында.

Бүген «Авангард» ҖЧҖ дуңгызчылык, үсемлекчелек, азык әзерләү, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртеп сату белән шөгыльләнә. Мегакомплексларда 64 мең баш дуңгыз асрала, аларның тәүлеклек артымы 636 грамм (симертүгә куелганнарыныкы – 821 грамм). Өстәмә бәя салымыннан алынган керем 2015 елда 2,1 млрд сумны тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы – 20 мең гектарга якын, шуның 17 мең га дан артыгы – сөрүлек җирләре. 2015 елда бөртеклеләрнең тулай җыемы, кукурузны да кертеп, 11 мең гектарга 32,6 тонна тәшкил итә. Сояның уңышы гектарыннан – 17, шикәр чөгендеренеке 478 центнер булган. Хуҗалыкта 1484 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 300дән артыгы – савым сыеры, 300дән артык үгез – ит токымнарыннан. Бер сыердан уртача 7850 литр сөт савып алынган, 2014 ел белән чагыштырганда, 123 литрга күбрәк. МЭТнең тәүлеклек артымы – 856 грамм, симерткәндә – 957. 2016 елга 1500 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән симертү мәйданы, 800 башлык үстерү мәйданы төзү планлаштырылган.

2011 елның июненнән башлап предприятиенең генераль директоры булып Чуваш Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Т. Мальцев исемендәге медаль иясе, «Ел җитәкчесе – 2015» республика бәйгесенең «Югары көндәшлеккә сәләтлелек» номинациясе лауреаты Николай Курчаткин эшли.

Тәҗрибәле җитәкченең роле предприятиенең уңышлы үсешендә бәһаләп бетергесез. Нәкъ менә Николай Григорьевич кадрларны сайлап алуга, квалификацияле белгечләрне әзерләүгә һәм аларның үсешенә зур игътибар бирә.

«Авангард» ҖЧҖ – Гомумдәүләт дуңгыз үстерүчеләр берлеге әгъзасы. Анализ, җитештерү эшчәнлегенең стратегиясен һәм сәясәтен кору өчен компания җитәкчелеге һәм белгечләре дуңгыз итен дөнья һәм Россия базарларындагы сатып алучыларның ихтыяҗларын, партнерлар һәм инвесторларның таләпләрен дә кертеп, комплекслы анализлау үткәрә торган бәйсез экспертлар төркеменең маркетинг тикшеренүләреннән файдалана.

2015 елның июнь аеннан башлап, «Авангард» ҖЧҖ эшкәртү белән актив шөгыльләнә. Буада компаниянең филиалы ачылган – «Карлинский» ит йорты». Бу ит продукциясен суытып эшкәртә һәм аны сата торган сую цехы. Бер сменада 480 баш дуңгыз, 80 баш мөгезле эре терлек суела, 25 тонна түшкә эшкәртелә, 14 тонна ярымфабрикат әзерләнә, 3 тонна казылык һәм ит ризыгы, 1 тонна пилмән җитештерелә. Терлек чалу буенча еллык проект куәте 118200 баш дуңгыз, 29550 баш мөгезле эре терлекне тәшкил итә. Бу 4221 тонна полуфабрикат, 844 тонна казылык һәм ит ризыгы, 281 тонна пилмән җитештерү мөмкинлеге бирә. Җитештерү даими рәвештә яңартыла, әзерләнә торган ризыкларның сыйфаты һәм ассортименты яхшыртыла.

«Авангард» ҖЧҖ – актив үсештәге күп юнәлешле яңа тип авыл хуҗалыгы предприятиесе. Акыллы кадрларга һәм югары технологияле җитештерүгә таянып, ул үзенең югары җитештерүчәнлеккә ия булуын дәлилләп һәм партнёрларын сыйфатлы продукция белән тотрыклы рәвештә тәэмин итеп тора. Компаниядә 407 кеше эшли, шуларның 310ы – ТРның Буа районында, 97се – «Цивиль Беконы» филиалы хезмәткәрләре. Уңай корпоратив мәдәният һөнәри осталыкка, эчке бердәмлеккә һәм хезмәткәрләрнең үзара ихтирамына нигезләнә. Коллективның амбициоз планнары компаниянең алга таба чәчәк атуына гына түгел, беренче чиратта, халыкны экологик яктан чиста, сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итүне яхшыртуга да юнәлтелгән.

PRESSA.RU

Языл һәм телевизор от!

1 Языл
30.06.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!

Акцияне үткәрү вакыты:18.04.2016 - 20.09.2016

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» орденын **КЕМ** беренче булып алды

Чистай сулыклары ярларын **НИЧЕК** саклыйлар

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Илһам Шакиров – күренекле татар җырчысы. Аның иҗаты – татар җыр сәнгатенең тулы бер дәверен тәшкил итә. Егерме ел дәвамында Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкара, әйдәп баручы солист-вокалисты була. РФ һәм ТРның халык артисты. ТР Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты һәм сәнгать өлкәсендәге югары бүләк – «Алтын Аполлон» иясе. 2005 елда «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденына лаек була.

ИЛҺАМ ДӘВЕРЕ

«Андый кешеләр дөньяга киләләр дә моңы белән киләчәк буыннарны сугарыр өчен биредә мәңгегә калалар». Бу сүзләр татар халык җырларын гаҗәеп сәнгати югарылыкка күтәрә алган җырчы Илһам Шакиров турында. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены шикелле югары бүләккә дә иң беренче булып Илһам Шакировның лаек булуы очраклы хәл түгел.

Ольга Туманская
әзерләде

«СИН МИНЕ БУ ҖЫРЫҢ БЕЛӘН ҮТЕРДЕҢ!»

1974 ел. Илһам Шакиров Мәскәүдә концерт бирә. Ул әле залда Мстислав Ростропович утырганын белми. Ә менә концерт тәмамлангач, легендар музыкант сәхнә артына керә дә сәламләү сүзе урынына: «Син мине бу җырың белән үтердең!» – дип соклануын белдерә. Илһам башкаруындагы «Кара урман» шулай тәэсирләндергән була Ростроповичны.

Мстислав Леопольдович яшь җырчыны үзенә кунакка чакыра. Соңрак Илһам Шакиров, бу очрашуны искә алып, дусларына еш сөйли. Ростропович өендә аның килүе хөрмәтенә өстәлгә татар ризыклары куелган була, бу хәл Илһамны чиксез гаҗәпләндерә һәм дулкынландыра. Җырчы ул очрашуны тормышындагы иң әһәмиятле мизгелләрнең берсе дип исәпли.

«Халыкта аны яратып «татар сандугачы» дип йөртәләр. Халыкча гади, әмма тирән эчтәлекле бу билгеләмә җырчының музыка сәнгатендәге урынын бик төгәл билгели... Илһам борынгы татар җырларын дөньяга күрсәтү белән генә чикләнмәде, ә аларга өр-яңа сулыш өрде, үзенә генә хас булган мелизмнар, музыкаль үзенчәлекләр өстәде», – дип яза Илһам Шакиров турында икенче бер даһи – азәрбәйҗан җырчысы Бүл-Бүл оглы.

Илһам Шакировның утыз ел элек булган гастрольләрен язучы Аяз Гыйләҗев исә менә ничек искә ала:

«Күз алдына китерегез, моннан утыз еллар элек нефтьчеләр мәркәзе булырга әзерләнгән Әлмәт шәһәрен. Апрель азаклары... Ул чактагы Әлмәт язы урамнарын белсәгез сез!.. Кая борылма, тездән лай, урамнарда машиналар артыннан сызылып саек пычрак кала... Мәдәният сараенда Илһам Шакиров концерты. Җырчының даны шулай бөек, ерак-еракларга таралган, шушы сазлы урамнарны үтеп, кесә фонарьлары белән юл яктыртып, бер-берсенә дәрт-көч биреп, концертка йөзәрләгән әлмәтлеләр җыелган... Кемнәр бу авыр торбаларны кулдан-кулга күчереп йөрткән, бетон блоклар, баганалар күчергән, канау казыган – әлмәтлеләр Илһам Шакировның моң диңгезенә кереп чумганнар. Сәхнәдә «Кара урман» агыла... «Әниемә хат» яңгырый... «Көзге ачы җилләрдә» уйнап ала. «Уел» башлануга, күпләрнең күзләренә кайнар яшь килеп бөялә, һәрбер җыр йөрәкләрне милләт белән, учакта җемелдәшеп яткан күмер чаткылары белән тоташтыра. Залда басып торучылар да күп, ишек-тәрәзәләргә адәмнәр килеп бөялгән, җырчыны сәхнәгә кат-кат чакыралар. Берәүнең дә бу кичтән аерыласы, бәхет диңгезеннән чыгасы килми...»

2000 елда Илһам Шакиров татар артистларыннан беренче булып «Алтын Аполлон» дигән дәрәҗәле бүләккә лаек була. Бу премияне ике елга бер тапкыр РФ Мәдәният министрлыгы һәм Чайковский исемендәге илебез музыкаль сәнгатен үстерү фонды «Музыка һәм хореография өлкәсендәге махсус казанышлар өчен» тапшыра торган була. Лауреатлар арасында Россия сәхнәсенең тере легендалары бар.

«БӨГЕЛМӘС РУХЛЫ ШӘХЕС»

Совет хакимияте елларында шулай бервакыт Илһам Шакировны партия өлкә комитетына беренче секретарь белән очрашуга чакыралар. Кабинетка килеп кергәч, секретарь, Шакировның җилкәсенә кулын сала да, бик акыллыланып, «Кара урман»ны ничек җырларга кирәклеген өйрәтә башлый. Унбиш минут буе аңлата. Илһам Шакиров әлеге бусагадан башка гомерендә дә атлап керми...

Вакыйганы язучы Мөхәммәт Мәһдиев язып калдырган. Мәһдиевне, башка бик күп башка замандашлары белән беррәттән, бөек җырчының үз-үзенә тугрылыгы, сынмас

Фотолар Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивыннан алынды.

рухы соккандыра торган була. Менә аның язмасыннан бер өзек:

«Илһам – сынмас, бөгелмәс рухлы шәхес. Ул җырлый башлаганнан бирле сәяси атмосферабыз ничәмә-ничә тапкыр үзгәрде: Хрущев заманында җырлый башлаган Сарман яшүсмере Брежнев, Андропов, Черненколар, Горбачёвлар дәверен халкына тугрылыклы рәвештә узып, иманын үзгәртмәгән көе бүген дә сәхнә тота».

Илһам Шакиров гомере буена халык җырларын эзли һәм өйрәнә. Аларны планетаның барлык почмакларыннан бөртекләп җыя – Татарстанның иң бәләкәй авылларына чыкканда, татар диаспорасы вәкилләре чакырган илләргә барганда... Кыскасы, бөтен дөнья буйлап.

– Илһам – зур галим, акыл иясе ул, – дип сөйли җырчы хакында якын дусты, Татарстанның халык язучысы, шагыйрь Гәрәй Рәхим. – Ул татар халык авыз иҗатының һәм сәнгатенең үсеш этапларын бик борынгы чорлардан башлап белә. Шулай ук традицияләребезне дә – милли аш-су булсынмы ул, борынгы гореф-гадәтләр, йолалар булсынмы. Ул бу белемне озак еллар дәвамында туплады – халыкның үзеннән, тормыштан. Шуңа да Илһам, хәтта зур-зур галимнәр белән очрашканда да, тарихи фактлар, вакыйгалар турында сүз көрәштерүдән курыкмый. Бүгенге башкаручылар ул кадәр тирәнгә төшеп тормый, халык җырларын беренче тапкыр ничек ишетәләр, шулай башкаралар да. Хәтта сүзләрен дә кат-кат тикшереп, чагыштырып карамыйлар. Ялгыш җырлыйлар. Ә менә Илһамда һәр сүз, һәр иҗек, һәр музыкаль борылыш, кыскасы, һәрбер деталь җентекләп тикшерелгән, өйрәнелгән. Ул шуннан соң гына – башкара. Болардан кала, Илһамда гаҗәеп моң бар – аның моңын бирәү дә кабатлый алмый. Гомумән, мондый моң бары татар җырларына гына хас. Шуңа да, күрәсең, бу сүзнең башка телләргә төгәл тәрҗемәсе дә юк.

БЕРЕНЧЕ ГОНОРАРЛАР

Исемен дә белеп кушканнар диярсең. Әллә язмыш үзе куштыргынмы? Һәрхәлдә, очраклык кына түгел шикелле. Ерак Сарманда гап-гади генә Гыйльметдин атлы тимерче гаиләсендә туып-үскән бу малайга дөньяның мәртәбәле заллары аягүрә басып кул чабасын каян белгәннәр диген.

Тормышы җиңел булмый Илһамның. Дәһшәтле 1937 елда, малайга әле ике генә яшь булганда, ялган шикаять буенча әтисен кулга алалар. Илһамга аны кабат күрергә насыйп булмый – Гыйльметдин колониядә авырудан һәм ачлыктан дөнья куя. Ул 1972 елда «җинаять составы юк» булуы «ачыкланып» реабилитацияләнә.

Илһамны сугыш чоры михнәтләре дә урап узмый. Башкалар кебек үк, ул да ачлыктан интегә, хәер сорашырга мәҗбүр була. Дөрес, бушка ашамый, хәер бирүчеләргә рәхмәт йөзеннән җырлый торган була. Каткан ипи кисәге белән пешкән бәрәңге – беренче гонорарлары әнә шул була бәләкәй артистның.

Илһамның тавышын бөтен авыл ярата. Мәктәптә аны укуын алга таба дәвам итәргә кирәклегенә инандыралар. Озак уйлый егет, икеләнә, нәтиҗәдә кабул итү имтиханнарына соңга кала. Казан музыка училищесына көзен генә килә һәм ул чактагы директор – Ильяс Әүхәдиевка барып керә. Әүхәдиев аны, бик озак үтенгәч, тыңлап карарга риза була. Тыңлый да... тулы бер комиссия җыя. Илһам шунда ук училищега кабул ителә!

Композитор Фасил Әхмәтов Илһам Шакиров белән танышуын болай искә ала:

«Илле дүртенче ел микән, кара күзнең шомлы, яңгырлы бер көнендә музыка училищесына бер егет килеп керде. Телогрейкадан, кирза итектән, чәче машинка белән алынган. «Армиягә китәргә әзерләнеп килгән идем... Монда җырларга өйрәнергә исәп. Дөресен әйткәндә... өйрәнәсе дә юк инде... бәләкәйдән үк җырлыйм...» Тиз генә гармун китереп, бер аудиториягә кердек. Мирсәет Яруллин да шунда иде. Яңа танышыбыз бөтен училищены яңгыратып җырлап җибәрде. Җыелды бар студент... Шәп, көчле, табигый тавышы булуга карамастан, Илһам үз өстендә көне-төне эшләде, һәрчак кулында китап, һәрчак пианино янында иде...»

Илһам училищеда озак укымый – алдагы елда ук, педагоглар гаризасы белән, консерваториягә алына. Ул әле студент кына, әмма тавышын инде бөтен республика белә. Илһам радиода даими чыгыш ясый, халык аның чыгышларын көтеп ала! 60нчы елларда ул инде чын мәгънәсендә танылган җырчыга әверелә. Эшчеме ул, колхозчымы, галимме, сәнгатькәрме – барысы да Илһамны белә. Советлар Союзы территориясендә һәм хәтта аннан читтә яшәүче халыкның яше дә, карты да, татары да, башка милләт вәкилләре дә –татар җырын Илһам башкаруында ишетсә, аны инде мәңгегә оныта алмый, йөрәгенә кереп урнашып кала ул моң аның.

ТАТАР ҖЫРЫНЫҢ БИЕКЛЕГЕ

– Ә беләсеңме, егет чагында Илһам бик шаян иде, – дип искә ала Гәрәй Рәхим. – Һәм туры сүзле! Үз заманында Минкультны (Мәдәният министрлыгын – авт.) культура белән ял министрлыгы дип атаудан да курыкмады ул. Без 60нчы еллар башында таныштык. Илһамның популярлыгы, даны күкрәп торган еллар, ә мин әле – башлап язучы шагыйрь генә. Журналда беренче тапкыр шигырьләрем басылып чыккан чак. Кинәт Илһам Шакиров минем яныма килде дә: «О, Гәрәй! Мин бит сине беләм – шигырьләреңне укыдым. Рәхмәт!» – диде. Менә шундый иде ул, «йолдызлык чире»нең тамчысы да юк, ә кешеләргә игътибарлылык – беренче урында.

Илһамның шаянлыгы турында мәзәкләр күп йөри. Кайчак юмор аның коралына да әверелә торган була – четерекле ситуацияләрдә ярдәмгә килә. Шундый бер кызыклы тарихны «ТНВ» каналының алып баручысы Илдар Кыямов сөйләде:

«Житмешенче еллар башы. Илһам Шакиров Үзбәкстанда чыгыш ясый. Кемдер Үзбәкстан Коммунистлар партиясе республика комитетына шикаять яза. Имеш, Илһам Шакировның музыкантлары озын чәч йөртә, сакал-мыекларын кырмый, фәлән дә төгән. Янәсе, шулай ярыймы? Җырчыны республика комитетына чакырталар. Шикаять белән таныштырып, шул ук сорауны бирәләр: ни өчен музыкантларыгыз озын чәч йөртә? Нишләп кырынмый? Халык артисты инструктор артында диварда эленгән Карл Маркс портретына ымлый: «Аңа ярый, ә без... кырынырга тиешме?»

Шулай да Илһам Шакировның шәхес буларак та, кеше буларак та чын асылын күрсәткән вакыйга Башкортостандагы гастрольләрнең берсе вакытында була. Җырчы сәхнәдә чыгыш ясаганда кинәт куе төтен күтәрелә башлый – көчәйткеч янып чыга. Антракт вакытында музыкантлар нишләргә дә белми – микрофон да, электрга көйләнгән инструментлар да эшләми. Менә концертның икенче өлеше башлана. Илһам аптырап тормый, сәхнәгә чыга да җырлап җибәрә. Бар да «элеккечә» – ул да, баян гына. Азакта тамашачы җырчыны алкышларга һәм хатларга күмә. Һич тынычлана алмыйлар, әйтерсең, Илһам аларның йөрәгендә учак кабызган, һәм ул учак дөрли дә дөрли. Бернинди чит авазларсыз, бары Илһам тавышы гына яңгырап торган кичә була ул. Илһам Шакиров газиз халкын татар җырының нинди биеклеккә күтәрелә алырга сәләтле булуын исбат иткән кичә.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән

ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Материалны әзерләүдә ярдәм күрсәткәне өчен редакция «Җыен» фондына рәхмәт белдерә.

PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ШАШИН

100 ел элек, 1916 елның 16 июнендә, ерак Бакуда гади нефтьче гаиләсендә исеме Татарстанның күренекле кешеләре исемлегенә мәңгелеккә кереп калачак кеше туган. Сүз Валентин Дмитриевич Шашин турында бара. Республикада нефть сәнәгате формалашу һәм аның үсеше тарихының данлыклы сәхифәләре нәкъ менә әлеге легендар шәхес белән бәйле.

Шашин В.Д. «ТатНИПИнефть» хезмәткәрләре белән. Бөгелмә шәһәре, 1966 ел.

«ИКЕНЧЕ БАКУ»

Язмыштыр инде, нәкъ менә Россиянең төп нефть чыгаручы төбәгендә туып-үскән Валентин Шашинга 50–60нчы елларда академик И.М. Губкинның идеяләрен тормышка ашырырга туры килә: «икенче Баку» – Идел-Урал төбәгенең потенциалын ачарга һәм, туган шәһәренең нефть белән бәйле данын күләгәдә калдырып, Татар АССРны Советлар Союзының иң эре нефть төбәге итәргә.

Валентин Шашин 30нчы елларда ук биеклекләр ялый башлый – Башкортостанда нефть техникумын тәмамлап, ул ике ел «Ишембайнефть» трестының каротаж партиясендә эшли. Бөек Ватан сугышы елларында ул Мәскәү нефть институты дипломы ала. Әмма «нефть һәм газ ятмаларын эшкәртү буенча инженер» белгечлеге алганчы, СССРның булачак нефть сәнәгате министрына шәһәрне фашистлардан сакларга туры килә әле. «Мәскәүне саклаган өчен» медале – шуның дәлиле.

Инженер Шашинның хезмәт эшчәнлеге «Туймазынефть» трестының бораулау конторасында башлана, бер елдан соң ул «Башнефтеразведка» трестына күчерелә. Анда ул 1947 елда трестның баш инженеры, соңрак идарәчесе итеп билгеләнә. Аннан соң инде Шашинны Татарстанга яңа нефть ятмаларын үзләштерергә җибәрәләр.

СССРДА – БЕРЕНЧЕ УРЫН

Ул елларда «Татнефть»кә Алексей Тихонович Шмарев җитәкчелек итә. Нәкъ менә легендар Алексей Шмарев башлангычы белән аның бораулау буенча урынбасары Валентин Шашинга 1953 елдан 1956 елга кадәр иң кыска вакыт эчендә, бик аз чыгымнар кулланып, Татарстанда беренче алты мең нефть скважинасын төзү, алга таба аларның санын 25 меңгә җиткерү бурычы йөкләнә.

1956 елда Алексей Шмаревны Мәскәүгә алалар, «Татнефть» башлыгы вазыйфасында Шашин кала.

1956 елдан алып 1960 елга кадәр Валентин Шашин җитәкчелегендәге «Татнефть» алдынгы технологияләрне сынап карау мәйданына, илдәге турбиналы бораулау буенча тизләтелгән режим үзәгенә әйләнә. «Татнефть» бораулаучылары революцион юнәлештә – бораулауның индустриаль скважиналары буенча зур уңышларга ирешә. Бурлар төзелешен оештыруның яңа ысулын куллану эшне 4–5 тапкырга тизләтә. Бу чорда Татарстанда нефть чыгару 13 миллионнан 43 миллион тоннага җитә. 1960 ел йомгаклары буенча, чыгару күләмен 20 млн тоннага диярлек арттырып, ил күләмендә рекорд куялар, бу дөнья күләмендә чыгарылган нефтьнең 14% тәшкил итә. СССР нефть табу буенча икенче урынга чыга.

Валентин Шашинның республика нефть сәнәгате үсешенә, «Татнефть» оешуга кертнкән өлеше бик зур. Берничә мисал гына китерик. 50нче еллар башында бораулау эшенә ел фасылы йогынты ясый торган була: җәй көннәрендә җиң сызганып эшләп алганнан соң, кышын күрсәткечләр түбәнәя. Әлеге вазгыятьне нәкъ менә Шашин үзгәртә. Бораулау эшләрен алып бару тәҗрибәсен җентекләп өйрәнеп анализлыйлар. Тәҗрибә-тикшеренүләр үткәрүгә

Реклама

контрольлек итүне Шашин үз өстенә ала. 1955 елдан башлап берләшмәдә бораулау эшләренең ел фасылына бәйлелеге бетерелә.

Татарстанның нефть чыгару өлкәсендәге зур уңышлары Валентин Дмитриевич Шашинны РСФСР Халык хуҗалыгы советы Нефть һәм газ сәнәгатенең баш идарәсе башлыгы итеп билгеләү өчен саллы сәбәп була.

ТАБЕЕВ ШАЯРУЫ

Министрлыкка Шашин җитәкчелек иткән унике ел СССРның нефть тармагы үсешендә иң алгарышлы чор була. Валентин Дмитриевич илдә нефть буенча фәнни учреждениеләр булдыру һәм аларны киңәйтү эшенең башында тора, тышкы икътисадый бәйләнешләргә зур игътибар бирә, даими рәвештә тармак буенча фән үсеше, казанышлары, һәм, хәзерге тел белән әйткәндә, инновацияләр белән кызыксынып бара.

1965 елда Шашин бораулауда түбән әйләнешле винтлы двигатель куллану технологиясен хуплый, бу исә нәтиҗәлелекне генә арттырып калмый, ә нефтьчеләрнең имгәнү очракларын да сирәгәйтә. Алай гына да түгел, Валентин Дмитриевич министр булгач та әле, шәхсән үзе Әлмәткә үзебезнең илдә эшләнеп, ТАССРда сынау үтә торган винтлы яңа двигательне карарга килә. Шул елларда «Әлмәтбурнефть» трестының 1нче бораулау конторасы директоры, соңрак «Татнефть» ААҖнең бораулау буенча генераль директор урынбасары булып эшләгән, хәзерге вакытта «Татнефть» ГАҖнең В.Д.Шашин исемендәге «ТатНИПИнефть»нең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Рашат Фәтхуллин хатирәләреннән: «Без бурларны әзерләп куйдык. Өч кара «Волга» килеп туктады, алардан югары кунаклар төште: министр Валентин Шашин, ТАССР өлкә комитеты секретаре Фикрәт Табеев һәм башкалар. Без эшкә керештек. Бораулаучы, дулкынлануыннан, торбаларны ялгаганда кагыйдәләрдән тайпылды. Ә Шашин үзе бораулаучы бит, бездән дә ким белми. Ул шунда ук миңа: «Син ничек өйрәтәсең? Нишләп кулдан ычкындырдың боларны?!» – диде. Ярый әле Фикрәт Әхмәтҗанович эшне шаяруга борып җибәрде. Без двигательнең ни дәрәҗәдә нәтиҗәле эшләвен күрсәттек. Шашин барысы да яхшы булуына инанды, хуплады – винтлы двигательләр чоры шулай башланды. Бер шундый забойлы двигатель бер борау белән ярты скважина бораулау мөмкинлеге бирә иде. Двигательләр Татарстаннан «чыкты» һәм бөтен Союзга, бөтен дөньяга таралды».

Шашин В.Д. СССРның Министрлар советы Рәисе Косыгин А.Н. алдында доклад ясый. 1972 ел.

1960 ел йомгаклары буенча, чыгару күләмен 20 млн тоннага диярлек арттырып, ил күләмендә рекорд куялар, бу дөнья күләмендә чыгарылган нефтьнең 14% тәшкил итә. СССР нефть табу буенча икенче урынга чыга.

Валентин Дмитриевич нефть җитештеругә һәм тармак белән идарә итүгә зур өлеш кертте. Нефть чыгару сәнәгате министрлыгы барлыкка килү белән илнең барлык нефть төбәкләрендә контроль урнаштырды һәм йөкләнгән үсеш темплары белән тәэмин итте.

ТАТАРЛАРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯВЫ

Валентин Дмитриевичны эш вакытында күреп белгәннәр бертавыштан аны олпат идеолог, дип саный. Ул игътибарын төп юнәлешләргә бирә, вак-төяккә таркалмый, үз өлкәсе буенча проблемаларны хәл итәрдәй һөнәр осталарын таба белә. Шашин беркайчан да кешеләргә карата каты куллы булмый, артык иркәләми дә, басым да ясамый. Аның өчен ахыргы нәтиҗә мөһим. Министр итеп билгеләнгәч, ул «Татнефть» берләшмәсеннән күп кенә геологларны, бораулаучыларны һәм башка белгечләрне үз янына алдыра. Нефтьчеләр ул вакытта «татарларның Мәскәүне икенче яулавы» дип шаярта торган була.

1960нчы еллар уртасында илдә Косыгин реформалары дип аталган үзгәрешләр башлана. Аларны тормышка ашыру өчен гадәти булмаган фикерләү рәвешенә ия кешеләр таләп ителә. Валентин Шашин «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры Валерий Грайферны сайлап ала. Валентин Дмитриевич Грайферны шалтыратып кына урынбасары булырга кодаламый, ә махсус рәвештә Татарстанга җирле җитәкчелектән сорарга оча. Ә «Татнефть»нең башлыгы урынбасары Виктор Мищевич, Шашин тәкъдиме белән, СССР Нефть сәнәгате министрлыгының баш техник идарәсе башлыгы итеп билгеләнә.

ЮБИЛЕЙ

1976 елның 16 июнендә СССРның нефть сәнәгате министры Валентин Дмитриевич Шашинга 60 яшь тула. Бу вакытта ул инде җитди авырый. Валентин Дмитриевич 1977 елның 22 мартында дөньядан китә. Аны Мәскәүдә Новодевичье зиратында хөрмәтләп җирлиләр. Бик күп халык җыела.

Валентин Шашинның ТАССРның нефть-газ чыгару сәнәгатенә керткән өлеше «Татнефть» берләшмәсенә һәм Лениногорск шәһәренең бер урамына аның исемен бирү аша мәңгеләштерелде. Лениногорскида Валентин Шашинга һәйкәл куелды.

Һәйкәлне ачу тантанасында аның кызы Шашина Татьяна Валентиновна катнашты. Ул бөтен гаиләсе исеменнән әтисенең истәлеген саклаган өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде һәм әтисе Валентин Шашин исән чагында республикада үткәргән елларын иң бәхетле, иң уңышлы чор, дип атый иде, диде. Ачылу тантанасында катнашкан Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Шашинның республика нефть сәнәгате үсешенә керткән зур өлешен ассызыклап, болай диде: «Бу кеше безнең нефтьчеләр белән нефть тармагын булдырган, аның язмышын билгеләгән шәхес!»

PRESSA.RU



ЫШАНЫЧ ЯРЛАРЫ

2016 ел ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан Татарстанда Су саклау зоналары елы дип игълан ителде. Су объектларын республика халкының һәрберсе өчен уңайлы һәм үтәрлек, йөрерлек итү – бу ел эчендә каралган чаралар кысаларында архитекторлар, түрәләр, оешма җитәкчеләре һәм республика сулыкларының язмышына битараф булмаган кешеләр бергәләп чишәргә тиешле бурычларның берсе әнә шуннан гыйбарәт. Ә без сезгә Татарстан сулыкларының ярларын тагын да чистарак һәм матуррак итәргә тиешле, инде өлешчә эшләнгән һәм әле эшләнәчәк берничә проект турында сөйләп үтәргә булдык.

Автор:
Олеся
Бондаревская

СУ ВАКЫТЫ ТӨГӘЛ БУЛА

Чистай. Энгельс урамы буйлап Кама ярына төшәбез һәм киң яр буена килеп чыгабыз. Аның бормалы бизәкләре ак һәм зәңгәр төсләргә буялган. Эссе булуга карамастан, тымызык кына көн уртасы һәм киң елганың караңгы сулары фонында яр буендагы култыкса (рәшәткә) һәм коймалар, ротонда, чатырлар аеруча җете күренә – ак һәм зәңгәрсу төсләрнең кушылмасы күзне иркәли. Биредә бар нәрсә дә салмак һәм тын. Мондый рәхәтлек зур булмаган җыйнак шәһәрләрдә генә буладыр, мөгаен.

«Тәнкыйтьчеләрнең иң бөеге, иң даһие, иң ялгышмый торганы – вакыт». Яр буеның иң үзәгендә урнашкан сәгать манарасы тактачыгына чокып язылган әлеге сүзләрне укыйбыз. Белинский сүзләре бу. Уклар төгәл вакытны күрсәтә. Вакыт, төгәлрәге, сәгать белән Чистайның үз мөнәсәбәте. Сугыш елларында бирегә эвакуацияләнгән һәм хәзерге көнгә кадәр эшләп килә торган Чистай сәгать заводы Россиядә бүгенгә кадәр үз сәгать механизмнарын һәм корпусларын эшләп чыгара торган бердәнбер оешма дип әйтсәк тә була.

– Әлеге мәйдандагы һәрбер предмет диярлек шәһәр тарихында булган ниндидер мөһим вакыйганың символы, – ди безне яр буенда озатып йөрүче журналист һәм фотограф Илдар Биктимеров.

Чыннан да шулай икән. Менә, мәсәлән бакыр печән көлтәсе. Әлеге һәйкәлдәге мәгълүмат тактасы революциягә кадәр Чистайның Кама буенда икмәк сату үзәге булып торганлыгы турында сөйли. Кама буенда, портка якынрак урында, складлар урнашкан булган, шәһәрдә ашлык сатып баеган берничә сәүдәгәр нәселе яшәгән.

Ә менә «Чистополец» дип аталган якорь һәм теплоход, алар шәһәрнең суднолар йөрешле данлыклы үткәне һәм хәзергесе турында искә төшерә.

Балалар мәйданчыгында чуар түбәләр һәм баскычлар, башлыклар һәм курткалар күзгә ташлана: яр буена күрше балалар бакчасыннан сабыйларны алып килгәннәр.

– Ял көннәрендә бөтен шәһәр халкы биредә! – дип сөйли безгә тәрбияче, узып барышлый.

Балалар китә. Тәрбиячеләр аларны үзәк баскыч буенча шәһәргә таба әйди. Ә сабыйлар, фонтаннан агып чыккан төрле төстәге су тамчыларына соклана-соклана, тукталып торалар.

Әле берничә ел элек кенә әлеге яңа яр буе территориясендә ташландык хәлгә килгән «Юность» паркы урнашкан булган. Совет чорының зиннәтле мәдәният учагыннан истәлек булып ротонда, чәчәк түтәле һәм җимерелеп төшкән бию мәйданчыгы гына калган.

Паркны яңадан торгызу «Ямашнефть» НГТИ башлыгы Виктор Смыков инициативасы белән башкарылган. Сүз уңаеннан, Виктор Васильевич, республика проектлары әле игълан ителгәнче үк, Чистайның аска – Камага алып төшә торган Ленин урамы буйлап урнашкан барлык паркларның язмышын үзгәрткән. Яр буен реконструкцияләү масштаблы проектның логик дәвамы гына булып тора.

– Биредә велосипедчылар һәм җәяүлеләр өчен юллар белән яшел мәйдан булачак, – ди Илдар Биктимеров, яр буе һәм көймә станциясе арасындагы территорияне күрсәтеп. – Ә биредә – төзекләндерелгән пляж, ятаклар, эчәргә яраклы сулы фонтанчыклар.

Без әле көймә станциясе буенда торган яхталар белән хозурланабыз, ә ул арада, эшчеләр килеп, топографик сурәтләр ясый башлый.

Чистай вакыты безне ашыктыра. Киткән чакта яр буе архитекторы Рамил Хәлиуллинның күккә ашкан Никольск соборы белән бергә иҗат иткән күркәм проектын янә бер кат сокланып күздән кичерәбез.

СУ КҮСЕЛӘРЕ ҺӘМ ЯЛ ПАРКЫ

Зәйнең яшел йөрәге – аның үзәк паркы. «Елганың җайлы, акрын агышы, яшел алан, елга аша салынган матур күпер – бире дә бар нәрсә шатландыра!» – Зәй укучылары әлеге урынны үз иншаларында нәкъ менә шулай тасвирлый торганнардыр мөгаен.

Беренче мәртәбә әлеге территорияне масштаблы төзекләндерү 2005 елда булып узды. Ул вакытта Зәй районы башлыгы Ринат Фәрдиев инициативасы буенча шәһәрне бүлеп уза торган Карамалы елгасы ярларында Европаның иң яхшы традицияләрендә эшләнгән парк пәйда булды. Район һәм аның халкы өчен күп яхшылык эшләргә өлгергән Фәрдиевның гомере 2008 елда фаҗигале рәвештә өзелде. Зәйлеләр үзәк паркка аның исемен бирергә дип карар кылдылар.

2016 елда Татарстан буенча «Язгы марш» иҗат лабораториясе узды. Аның кысаларында яшь архитекторлар республиканың җиде торак пунктында урнашкан зур һәм бик зур булмаган яр буйларын төзекләндерү проектлары эшләп чыгарган иде. Зәйнең үзәк паркы да әлеге исемлеккә кергән.

– Без бирегә берничә тапкыр – көз азагында, кыш көне һәм иртә язын килеп киттек – елның төрле фасылында, иртән, көндез һәм кич белән паркның ничек яшәвен һәм сулавын өйрәнәсебез килде. Һәм без, аны күрү белән, бу җиргә гашыйк булдык, – дип сөйли паркны торгызу проектын тормышка ашыру эшендә катнашкан архитектор Анна Федорович. – Матур елга куе яшеллек белән капланган территория аша ага, елганың үзәгендә – утраулар, анда агачлар үсә. Парк шәһәр территориясе өчен сирәк очрый торган фаунасы белән шаккаттыра: монда кондызлар, су күселәре, кулга ияләшкән ак казлар һәм үрдәкләр, балык, Татарстанда бердәнбер булган диңгез кысласының да төре яши.

Паркта тормыш кайный: иртә таңнан яшьләр йога белән шөгыльләнә, бормалы сукмаклар буйлап коляска этеп әниләр йөри, пирсларда балыкчылар утыра, яңа өйләнешүчеләр фотога төшәргә һәм басмага йозакларын эләргә килә, ял көннәрендә парк сәхнәсендә концертлар һәм башка чыгышлар була.

– Кагыйдә буларак, шәһәр кешеләр, елга аркылы төзелгән җәяүлеләр күпере буйлап чыккач, парк аша узалар. Әлеге күпер паркны бер-берсе белән үзара бәйләнмәгән ике өлешкә бүлә. Проектның иң төп пунктларыннан берсе булып әлеге күперне 2,5 метрга өскә күтәру тора. Шулай эшләгәч, аның астында җәяүлеләр һәм велосипедчылар үтә алырлык урын барлыкка киләчәк, – дип сөйли Анна Федорович. – Карамалы елгасы буйлап төзекләндерелгән сукмаклар салыначак һәм алар күпергә барып тоташачак дип планлаштырыла. Шулай итеп, ике ярны, ягъни паркның аерым-аерым торучы ике территориясен «тегеп» куеп, аның буенча йөрү маршрутын берләштереп, бирегә йөрү вакытын арттырачакбыз, шулай ук су янына төшү юлын да ачачакбыз.

Зәйдә апрель азагында проект буенча булып узган җәмәгать фикер алышуларында шәһәр кешеләре күперне күтәрү идеясына бик ышанып та бетмәгәннәр иде. Әмма моның паркның үзәк зонасын үзгәртергә мөмкинлек бирә торган концепциядәге бер өлеш икәнен белгәч һәм «үзгәртеп коруның барлык акчалары да күпергә генә тотылып бетмәслегенә» ышангач, әлеге яңалык белән килештеләр.

2016 елга, реконструкциянең беренче чираты кысаларында, паркның үзәк өлешендә мәдәни чаралар өчен мәйданчыкны яңарту һәм бию мәйданчыгы, балалар мәйданчыгы, су буенда ял итү өчен яр буенда агач баскычлар, күргәзмә зонасы, чәчәк түтәлләре булдыру, җәмәгать бәдрәфе, ял итү һәм табигать белән аралашу өчен башка бик күп тыныч зоналар төзү карала. Икенче чират (2017 ел)



ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

паркның яңа территорияләрен – спорт зонасын кору, воркаут һәм скейт-парк өчен мәйданчык, елга үзәнендә ландшафт йөрү паркын монтажлауны күз алдында тота. Өченче чират (2018 ел) Фәрдиев паркына җәяү йөрүләр һәм пикниклар өчен урман-парк зонасын тоташтыруны планлаштыра.

– Проект яңа төзелешне түгел, ә паркны реконструкцияләүне күз алдында тотканга күрә, паркның инде яшәп килгән сценарийларын һәм булган артефактларын – ландшафтны, фауна, Ринат Фәрдиевка һәйкәл, агачлар үсеп торган утраучыклар, туй традицияләрен истә тоту һәм саклау бик мөһим иде, – дип сөйли Анна Федорович. – Һәм без гаять кызыклы фишка уйлап таптык шикелле. Ул әлеге тирәлеккә бик туры килеп торачак – хәзерге балалар зонасы урынында урнаштырырга җыенган «Крепость» шәһәрчеге. Зәй Кама аръягы оборона ныгытмасы буларак барлыкка килгән бит. Шәһәрдә аның килеп чыгу тарихының әлеге өлешен хәтерләткән берниндиобъект та юк. Шуңа күрә тарихи сюжетлы тактачыклары белән әлеге мәйдан кызыклы һәм истәлекле урынга әйләнер, дибез.



PRESSA.RU

АДМИРАЛТЕЙСТВО РЕНЕССАНСЫ

Казан территориясендә дә күчле символик һәм тарихи контекстлы су объектлары бар. Мәсәлән, Александр Дембич тарафыннан эшләнгән Адмиралтейство бистәсе территориясен ревитализацияләү проекты нигезендә Адмиралтейство буасы яр буе территориясен чистарту һәм төзекләндерү ята.

Казансу елгасының борылмасы XX гасыр уртасында ук суднолар йөри торган була. Ләкин 1956 елда, Куйбышев сусаклагычын төзегәннән соң, елганың якынча 2,5 км озынлыктагы әлеге өлеше ике дамба белән киселә. Вакытлар узу белән, әлеге территория сазлыкка әйләнә, ярлары үтеп чыкмаслык куаклыклар белән каплана. Елга ярларында предприятиеләр төзелә. Күп еллар буена әлеге сулык яңгыр һәм сәнәгать юынтык сулары өчен дренаж һәм су агыза торган канау булып хезмәт итә.

Озак еллар дәвамында Елга техникумы һәм Гладилов тукталышы арасындагы юлдан узучыларны Бөкре күпер астындагы сазлыктан чыккан сероводород исе озатып кала иде. Бәхеткә, бүгенге көндә калдыкларны сулыкка агызу эше туктатылды, әмма «авыр» мирас калды: Казансуның иске елга юлы акваториясен тулысынча чистартуны белгечләр 400 млн сум дип бәялиләр.

– Адмиралтейство бистәсен ревитализацияләүнең комплекслы проекты өчен «Адмиралтейство буасы» статусы алган һәм шул атама белән РФнең су объектлары реестрына кертелгән әлеге борылма төп, нигез объектларның берсе булып тора, – дип сөйли Александр Дембич. – Экологик реабилитацияләү проекты эшләнелгән инде. Буаны чистарту эшләрен үткәрү 2016 һәм 2017 елларга планлаштырылган.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: быел Адмиралтейство буасын чистартуны тормышка ашыру өчен федераль һәм республика бюджетларыннан тулаем 40 млн сумга якын акча бүлеп бирелгән.

– Чиста буа Казанда без планлаштырган иң эре шәһәр паркының күчәре булып тора. Һичшиксез, без проектны парк урнашырга тиешле территориягә тарихи яктан бәйләүне дә истә тоттык, – ди Александр Дембич. – Шулай итеп, проект XVIII гасыр өчен характерлы булган суднолор төзүнең тарихи технологиясен күрсәткән «Адмиралтейство верфе» музей-күргәзмә комплексын торгызуны күз алдында тота. Шунда ук императрица Екатерина II Казанга килгән «Тверь» галерасын торгызу да каралган. Галера мәңгелек саклауга Адмиралтействода калдырылган булган, әмма XX гасырның 50нче елларында янып беткән.

Буаның яр буенда, элеккеге Алафузов театры бинасы артында, Театр скверын урнаштыру планлаштырыла. Зилант монастыре урнашкан калкулыкның көньяк-көнбатыш өлешен төзекләндерү өчен монастырь бакчасы булдырылачак. Әлеге яшел зоналар да гомуми мәйданы 400 гектарга сузылачак территорияне төзекләндерүне күз алдында тоткан гомуми концепцияне тулыландырып торачаклар.

Ә Иделдәге дамба буенча, кайчандыр Казансу аккан урында, Идел буе яр буен төзү планлаштырыла. Әлеге эшне хәзер үк башлап булганлыгын хәбәр итә архитектор, әмма башта хөкүмәт дәрәҗәсендә аны җентекләп өйрәнергә, эшкәртергә кирәк.

– Адмиралтейство бистәсе территориясен ревитализацияләү проектын тормышка ашыру ихтималлыгы беренче чиратта хакимияттә әлеге мәсьәлә белән шөгыльләнергә вәкаләтле булган кешеләрнең профессиональлегенә һәм кызыксынуына бәйле, – ди Дембич. – Чынлыкта тормышка ашыру бара инде. Әмма әлегә проектларны хәзерләү дәрәҗәсендә генә. Ләкин, Татарстан һәм Казанда проектлар күп булганга күрә, өстенлекле якларны карау мөһим. Нәкъ менә биредә кызыксынган кешеләрнең мөнәсәбәте һәм инициативасы кирәк тә инде.

«Тверь» галерасы хәзерге Адмиралтейство урамының 17нче номерлы йорты торган урында урнаштырылган булган. Ул агач «тартма» әченә бастырып куелган һәм бик зур тент белән капланган иде. Без, балалар, әлеге саклавыч корылмалар аша бик җиңел һәм тиз уза идек. Галера бик биек түгел, аның өстенә менәбез дә, аннары, эчкә узып, каюталарда качышлы уйныйбыз. Эчке ягы агачтан эшләнгән, яхшы сакланган иде. Хәтта ниндидер интерьер күренешләре дә хәтердә: кызыл бәрхет белән капланган кечкенә диваннар хәзергә кадәр күз алдымда тора, алар хәтта палубада да торалар. Кайчак, тыгыз итеп урнаштырылмаган такталар арасыннан без гел бикле булган биналардагы утларны да күрә идек. Бәлкем, аларда кем дә булса яшәгәндер дә әле...» (Адмиралтейство бистәсендә яшәгән Нина Ларионова истәлекләреннән) .


11 ГОРОДСКОЙ ПАРК «КРАСНЫЕ ВОРОТА»(ПЕТРОВА)
12 ПАМЯТНИК ЕКАТЕРИНЕ II
13 ТЕРРАСНЫЙ САД
14 ТВОРЧЕСКИЙ КЛАСТЕР
15 ТЕАТРАЛЬНЫЙ САД
16 РАЗВЛЕКАТЕЛЬНО-ВЫСТАВОЧНЫЙ КОМПЛЕКС
17 РЕКРЕАЦИОННО-ТУРИСТИЧЕСКАЯ ЗОНА
18 ДЕТСКАЯ ИГРОВАЯ ЗОНА
19 САД ЦВЕТОВ
20 САД ФОНТАНОВ

Схема основных функционально-тематических зон парка

PRESSA.RU

«...БӨТЕН МӘЙДАН БИЮДӘ БӨТЕРЕЛДЕ»

Илебездәге авиация җиһазлары төзүче беренче предприятие – Казан «Электроприбор» заводы 2017 елда үзенең йөзьеллыгын билгеләргә әзерләнә. Быел сентябрьдә аның Татарстан җирендә эшли башлавына 75 ел тула. Ул вакытта 230 нчы дип йөртелгән завод Мәскәүдән Казанга Бөек Ватан сугышының беренче айларында эвакуацияләнә.



Романов Н.А., 1940–1943 елларда завод директоры.

1941 елның сентябрь ахырында ике эшелон Казанга җиһазлар, материаллар һәм төгәлләнеп бетмәгән җитештерү детальләре белән төеннәрен китерә. Заводның 1369 эшчесе дә гаиләләре белән – барлыгы 5000 кеше – килеп төшә. Яңа урында оештыру эшләре белән Николай Александрович Романов шөгыльләнә: 1918 елда, 13 яшьлек вакытында, заводка слесарь-инструментальщик янына өйрәнчек булып килгәннән соң, Мәскәү сәнәгать академиясен тәмамлап, АКШта стажировка үтеп, 1940 елда заводка җитәкче итеп билгеләнә.

Предприятиене Ветеринария институты шәһәрчегенә урнаштыралар, институтның күпчелек бинасын үзгәртеп корырга, идәннәрен һәм түбәләрен ныгытырга туры килә. Электр, җылылык һәм су белән тәэмин итү, канализация челтәрләренең куәтләре җитми, территориядә юллар һәм складлар булмый.

Җитештерү цехларының йөзләрчә эшчесе һәм белгече төзелеш эшенә кушыла. Территориядәге агач корылмаларның бер өлешен торак өчен файдаланалар, яңа агач йортлар сала башлыйлар. 1944 ел ахырына торак фонды инде 3000 квадрат метрга җитә.

Нибары өч автомашина һәм берничә ат белән завод эшчеләре Арча кырындагы соңгы тукталыштан заводка кадәр чакрымлы трамвай юлы салалар. Төннәрен трамвай платформалары аша тимер юл станциясеннән, елга портыннан йөк, утын ташыйлар.

Май тахометры ТМЭ-41, 1941 елдан бирле чыгарыла.

1941 елның декабрендә инде завод Мәскәүдәге кадәр үк продукция эшләп чыгара башлый. Шулай да төп төзелешне 1942 елның көзенә төгәллиләр, бу вакытка 16 мең квадрат метр җитештерү мәйданы, 600 метр су канализациясе челтәре әзерләнә һәм Җылылык-энергия үзәгеннән биш чакрым озынлыктагы югары вольтлы чыбыклар сузыла. Трансформатор станциясе, пар казаннары бинасы, суыткыч-аммиак камерасы, телефон станциясе, диспетчерлык пункты төзелә. Барлык цехлар һәм лабораторияләр эшли башлый. Урман кисү бүлеге ел саен 20 мең куб метр утын әзерли, шул рәвешле заводны һәм аның эшчеләрен ягулык белән тәэмин итеп тора.

Кадрлар кытлыгы проблемасын үсмерләрне һәм хатын-кызларны җәлеп итү юлы белән хәл итәләр – аларны эш урынында һәм 27нче ФЗӨ мәктәбенең заводның үзендә үк ачылган филиалында өйрәтәләр. 1942–1945 елларда барлыгы 2000 яңа кадр әзерләнә. 1942 елның башында завод территориясендә балалар бакчасы һәм ясле ачыла – анда балалар тулысы белән завод каравы астында була.

1942 елның мартында эшчеләрнең тәэминат бүлеге булдырыла: ашханә, шәһәр сәүдә бүлегенең азык-төлек һәм сәнәгать товарлары кибете, шулай ук 1нче трестның Бакалдыдагы совхозы (303 гектар сөрүлек җирләре, 38 сыеры, 90 дуңгызы, 57 аты, дүрт тәгәрмәчле тракторы белән) аның карамагына тапшырыла. Ярдәмче хуҗалык стахановчыларның, бакчадагы балаларның ашау ягын яхшыртырга ярдәм итә.

Ләлә Галимҗан кызы Чистовская 34нче җыю цехына 1942 елда җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң килә. *«Шулай бервакыт безгә20шәр килограмм ташкабакка талон бирделәр – аны ярдәмче хуҗалыктан алырга кирәк иде. 3нче трамвайның соңгы тукталышыннан соң 7 чакрым җәяү барасы. Ерак иде, әмма мин ул ташкабакларны өйгә алып кайттым. Алар шундый тәмле иде. Кием-салымга да талон бирделәр. Мин оекларга һәм күлмәккә талон алдым. Оекларны завод янындагы кибеттән сатып алдым. Ак төстә иделәр. Әни аларны суган кабыгында кайнатып буяды. Көрән төскә керделәр, тигезсез булып.*

Тахометрлар участогы. 1945 ел.

Реклама

Ә менә алсу төстәге йомшак күлмәкне озак кидем әле».

1942 елда җиһазларны 1941 елга караганда 1,5 тапкырга күбрәк эшләп чыгаралар, ләкин оборона заводларына бу гына да җитми әле. 1942 елның җәеннән башлап, хәрби биремнәр нормага керә: эшләп чыгару нормасын бер ярымнан һәм аннан да күбрәккә арттыралар. Комсомол-яшьләрнең фронт бригадалары саллы өлеш кертә. 1944 ел ахырына алар 80 гә җитә.

34нче цех конвейерына 1942 елның июлендә җиде сыйныфны тәмамлау белән үк килгән **Александра Георгиевна Раннева** Николай Гастелло исемендәге комсомол-яшьләр стахановчылар бригадасында җыючы булып эшләгән. *«Еш кына, – дип хәтерли ул, – нинди дә булса берәр деталь җитмәгәндә, безне икенче бер цехка эшләргә җибәрәләр иде. Соңыннан үзебезнең цехка кайтып, төннәрен норма тутыра идек. Безне утын бушатырга, ярдәмче хуҗалыкка булышырга еш җибәрделәр. Өйгә кайткач, төннәрен ике бармаклы тире бияләйләр, махорка тәмәкесе өчен янчыклар тегә, йон оеклар, бияләйләр бәйли идек».*

Серафима Федоровна Беляева 1941 елда заводка килә, аңа 17 яшь була. *«12-15әр сәгать эшли идек. Эш сәгате 8.00 дән 20.00 гә кадәр – мәҗбүри, «ихтыяри» рәвештә 22.00 гә кадәр калырга була, – дип сөйли ул. – Авыр, әмма күңелле иде: кичәләр үткәрәбез, маскарадлар оештырабыз. Марля һәм кәгазьдән костюмнар тегә, җырлар җырлый, бии идек. Ленинградтан «Голубой джаз» килгәне хәтердә калган. Барысы да яшьләр – ап-ак йөзле, арыган-йончыган һәм тешсез иделәр. Блокададан соң».*

Вера Ивановна Ардатовская 3нче цехка ФЗӨ да дүрт айлык курслар үтеп, 15 яшьлек кыз булып килә. Разрядка имтихан биреп, токарь булып урнаша. *«12 сәгатьлек икешәр сменада эшләдек. Айның беренче көнендә бер көн ял. Бөтен сугыш буена ялсыз. Карточкаларга 800 грамм ипи бирәләр, – дип искә ала ул, – ләкин без балалар санала идек әле, шуңа да завод өстәмә рәвештә көненә бер тапкыр ашата иде».*

Җелеккә төшә торган авыр хезмәт, әмма нәтиҗәләре дә сокланырлык. 1943 елда җитештерү күләме сугышка кадәргә чорга караганда 263,2 процент тәшкил иткән. Сугыш вакытында завод җитештерү күләмен 3,5 тапкырга арттырган, 40 эшче СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән, тагын 1790ы – «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәте өчен» медале белән. Алар арасында В.И. Ардатовская, С.Ф. Беляева, А.Г. Раннева, Л.Г. Чистовская да бар.

Комсомол-яшьләр фронт бригадасы. 1945 ел. Сулдан беренче булып А. Раннева утыра, уңнан беренче басып торучы – Л. Чистовская.

Завод эшчеләре Җиңүне фидакарь хезмәт белән генә якынайтмаган. Ел саен икешәр-өчәр айлык хезмәт хакын Дәүләт хәрби заемына күчереп барганнар, хәрби самолетлар төзелешенә 400 мең сум биргәннәр, Украина һәм Белоруссия партизаннарына ярдәм фондына 200 мең сум җыеп тапшырганнар. Сталинградны торгызуга 1943 елның апрелендә завод 138 берәмлек җиһаз, 6800 берәмлек корал, ике тонна төзелеш материалы һәм хәтта 500 пар аяк киеме җибәрә.

Йөзләрчә завод эшчесе бушлай кан тапшыра. Көн саен дистәләрчә кыз бала 4642нче госпитальгә яралыларны карарга йөри. Унике сәгатьлек эш көненнән соң, хатын-кызлар заводның кер юу бүлмәсендә солдатларның киемнәрен юалар яки өйләренә алып кайта торган була.

Сугыштан соң заводта өч йөздән артык фронтовик эшли. Алар арасында Советлар Союзы Герое очучы Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова да бар. 1951–1962 елларда ул контролер була. Интсрументлар цехы башлыгы урынбасары булып озак еллар Ростислав Владиславович Чиж эшли. 1943 елда училище тәмамлап, ул артиллерист-разведчик булып сугышка керә. Дәһшәтле танк һөҗүмнәре, вафат булган разведка башлыгы, яралы иптәшен команда пунктына кадәр сөйрәп бару – Сталинград янындагы беренче яу бу. Курск дугасында: немец танклары белән йөзгә-йөз очрашу һәм безнең артиллеристларның, паникага бирелмичә, кыюлыгы һәм зирәклеге аркасында могҗизалы рәвештә котылуы. Аннан соң Икенче Балтыйк буе фронты, азат ителгән Витебск, Литва, Латвия һәм 30 апрельдә яулап алынган Рейхстаг янында истәлеккә фотога төшү.

Майя Николаевна Серебрякованың да өлешенә авыр язмыш туры

Данные
о выполнении задания Р.К. В.К.П/б/.
Молотовского р-на.
По стирке и ремонту белья для
бойцов КРАСНОЙ АРМИИ.
ВЫСТИРАТЬ: 32.290
ОТРЕМОНТИРОВАТЬ: 16.310
Всего 48.600
Выполнено:
Выстирать — 33.900
Отремонтиров. — 17.317
Всего — 51217
Было привлечено к проведению стирки 78% всего коллектива завода.
г. Казань.

килә: бомба уты астында калу һәм өч концлагерь.

Ветераннар радиолары булган күршеләреннән иртәнге дүрттә Җиңү турында ишетеп, ничек итеп заводка очып барганнарын күз яшьләре белән искә төшерә. Керү юлында йөк машиналары тора, комач белән капланганнар – алардан котлаулар ишетелә. Озакка сузылган сугыш елларында беренче тапкыр җыелган халыкны яңа пешкән ит белән сыйлыйлар – моның өчен ярдәмче хуҗалыкта өч дуңгызны суялар. Кешеләр бии һәм күз яшьләре аша «Ура!» кычкыра – бу вакытта алар йокысыз төннәр турында да, ачлыктан аңнарын җуйган чакларын да онытала... Ләлә Галимҗан кызы Чистовская митингтан соң иптәш кызлары белән Ирек мәйданына килдек, дип сөйли: «Халыкның исәбе-саны юк. Барысы да шатлана, көлә, җырлый, бер-берсен котлый. Тынлы оркестр уйный һәм бөтен мәйдан биюдә бөтерелә иде...»

Материал белән завод тарихы музее директоры Ю.А. Гарпинченко тәэмин итте.

Реклама

PRESSA.RU

ТЫЛДА ДА СУГЫШТАГЫ КЕБЕК

Казан электр техникасы заводы (КЭТЗ) тарихы республикадагы легендар предприятиеләрнең күпчелегенең тарихын кабатлый. 1941 елда Ленинградтан 1,5 меңнән артыграк предприятие эвакуацияләнә. 379 нчы заводның филиалын (элек – 21 нче Махсус конструкторлык бюросы) Казанга күчерергә дип хәл итәләр.

Августта Ленинградтан Казанга өч эшелонның беренчесе кайтып төшә. Анда хезмәткәрләрнең, җиһазларның һәм чималның бер өлеше була. Юлда барганда эшелонны берничә тапкыр бомбага тоталар. Эшчеләр һәлак була, җиһазларның күпмедер өлеше югалтулар кичерә. Казанга килеп җитүгә, исән калганнарын завод филиалы өчен бүлеп бирелгән ликер-аракы заводы территориясенә урнаштыралар (бүген бу урында – Петербург урамындагы «Идея» технопаркы бинасы).

Тылдагы кырыс эш көннәре башлана. Бөтен илгә артиллерия зенит утлары белән идарә итү җиһазлары («ПУАЗО») чыгара торган бердәнбер предприятие буларак, завод катлаулы бурычлар алдында кала. Станокларга, инфраструктурага, белгечләргә коточкыч дәрәҗәдәге кытлык шартларында фронт өчен планны үтәргә кирәк була. Санны тотыру өчен заводка эшкә казанлыларны– 14–18 яшьләрдәге үсмерләрне җыялар. Алар предприятиедә ачылган фабрика-заводларда эшләргә өйрәтә торган мәктәпнең беренче укучылары булып китәләр. 1942 елның мартында инде заводта 300гә якын кеше эшли, ул үзе исә мөстәкыйль предприятиегә әверелә.

Заводның туган көне булып 1942 елның 8 марты санала. КЭТЗның Хезмәт даны музеенда тылның авыр эш көннәрен чагылдырган фотолар саклана: завод хезмәткәрләре җитештерү эшендә генә түгел, үзләренә торак төзү эшләрендә дә хезмәт куя. Нормасы билгеләнмәгән эш көне дәвамында күпләр стахановчы планын үтәп бара. Шулай да фотолардан безгә илһамлы, тормышка гашыйк йөзләр карап тора. «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» – әлеге өндәмә берләштергән дә, илһамландырган да, мөмкин булмастай эшләргә

Реклама

Станокларга, инфраструктурага, белгечләргә коточкыч дәрәҗәдәге кытлык шартларында фронт өчен планны үтәргә кирәк була.

рухландырган да. Сугышның беренче, иң авыр айларында, заводның кайбер цехлары планны ике йөз процентка үти. 1942 елда завод бер ай эчендә фронтка «ПУАЗО –3»нең 8 комплектын җитештереп бирсә, сугыш ахырына елына 200 комплектка кадәр җыя торган була.

1943 елда завод диңгез автоматикасы җиһазлары – «Спрут»лар (су асты көймәләрен автомат рәвештә тотрыкландыру җайланмалары), «ПУТС»лар (торпедо атышы белән идарә итү җайланмалары) һәм эхолотлар (су тирәнлеген үлчәгечләр) эшләп җитештерә башлый. Хәрби-диңгез флоты өчен кирәкле булган автомат рәвештә көйләү системасын эшләп чыгару җайга салына.

Хезмәт ветераны, монтажлаучы А. Глазкова хатирәләреннән:

«Мин җыю цехына 1942 елның сентябрендә килдем. Миңа 14 яшь иде. Бу цехта Казаннан беренче эшче булдым. Эш урынында өстәл дә, верстак та юк. Зал буйлап нинди-дер үткәргечләрнең өемнәре генә аунап ята. Соңрак миңа аларның җайланмалар өчен схемалар булуын аңлаттылар… Мастерыбыз Володя Кулаков иде, искиткеч киң күңелле кеше. Ул мине эшкә тиз өйрәтте, аннан соң, цехка инде минем булачак дус кызларым килгәч, үзем аларны схемалар җыярга өйрәтә башладым… Ул вакытта без шунда ук, цехта яши идек. Биредә без кайгыны да, шатлыкны да уртаклаштык, ул безнең өчен мәктәп тә, туган йорт та булды…»

Сугыш беткәч, оборона сәнәгате яңа үсеш баскычына күтәрелә. «Свияга» «Татар җитештерү берләшмәсе» дигән исем алып, завод тулысы белән Хәрби-диңгез флоты кораблары өчен җиһазлар җитештерүгә күчә. Төп, стратегик эшләнмәләрнең берсе – баш конструктор Григорий Клебанов кул астында уйлап чыгарылган «үзебезнеке-читнеке» дигән дәүләт тану системасы була. Алга таба Хәрби-диңгез флоты өчен эшләп чыгарыла торган продукциянең төрләре киңәйтелә. Яңа техника җитештерү оештырган өчен завод 1971 елда Хезмәт Кызыл Байрагы белән бүләкләнә, заводның 62 эшчесенә дәүләт бүләкләре тапшырыла.

Хәрби-сәнәгать комплексының барлык предприятиеләре дә ул вакытта гражданнар продукциясенең билгеле бер төрен эшләп чыгара иде. Бу җәһәттән «Свияга» берләшмәсе бөтен планета күләмендә алдынгы була. 70нче елларда илдә «винил бумы» башлана – СССР үзебезнең илдә чыгарылган музыка тәлинкәләренә «күмелә». «Свияга»да «Рондо» дигән электрофон җитештерүне җайга салалар – алар музыка сөючеләрнең күңелен дистә еллар буе биләп тора. Җитештерү юнәлешен үз вакытында үзгәртеп коруга сәләтлелек, нинди товарга ихтыяҗ буласын алдан күрү, үсешнең яңа перспективалы юнәлешен билгели алу сыйфатлары предприятиенең барлык директорларына да хас була. Оборона заказының кинәт кыскаруы белән бәйле, гражданнар куллану товарлары – Корея һәм Кытайда җитештерелгән аналогларыннан сыйфат ягыннан күпкә алдынгы тостерлар, аш комбайннары, грильләр, домофоннар, ут кабызу блоклары, антенналар, көчәйткечләр һ.б. товарлар 90 нчы елларда заводка исән калырга ярдәм итә. Шул ук вакытта югалтулар да зур була: 8000 хезмәткәре булган предприятие 2000нче еллар башына 800дән артык кешене генә эш белән тәэмин итеп тора ала.

2002 елда берләшмә өчен җаваплылыкны үз кулына аның бүгенге җитәкчесе Владимир Гинсбург ала. Дәүләт заказын үтәү белән шөгыльләнә торган цехлар аерым предприятие булып бүленеп чыга, 2004 елда ул «Казан электр техникасы заводы» ААҖ булып китә.

2009 елда предприятие «Радиоэлектрон технологияләр» Концерны» (КРЭТ) Акционерлык җәмгыятенә кереп, «Ростех» Дәүләт корпорацияләренең көчле холдинг компанияләре

һәм оешмалары җәмәгатьчелеге белән берләште. «Диңгез» радиоэлектрон аппаратлар җитештерүгә нигезләнгән традицияләрен саклаган хәлдә, Концерн канаты астында, гади булмаган шартларда, завод һава һөҗүменә каршы оборонаның җир өсте кораллары һәм хәрби авионика өчен заманча, югары технологияле эшләнмәләр җитештерүне үзләштерә башлый. КЭТЗ үзенең традицияләренә тугры: предприятие элеккечә үк гражданнар тармагына да югары сыйфатлы продукция җитештерә. Болар «Дозор» дигән күп зоналы стационар металл детекторлары, энергетика һәм энергия саклау өлкәсендә комплексы җайланмалар, «Ритэкс» нефть скважиналары өчен насослар белән идарә итү станцияләре, мөһерле платлар, металл кисүче кораллар, агач эшкәртү буенча төрле эшләнмәләр һәм үзләре өчен яңа медицина буенча юнәлештә – «Да Винчи»ның Россиядәге аналогы «Робот» өчен хирургия кораллары.

2017 елда Казан электр техникасы заводы үзенә нигез салынуның 75 еллыгын билгели. Элеккечә үк, берничә буынның фидакарь хезмәте, даими рәвештә үсешкә омтылыш һәм традицияләргә сакчыл караш Казан электр техникасы заводын имин киләчәк көтәчәгенә шик калдырмый.

Реклама

PRESSA.RU

Реклама

КАЗАН ГИПРОНИИАВИАПРОМ: ҖИҢҮЧЕЛӘР ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Ел саен 9 майда илебездә Җиңү көне киң билгеләп үтелә. Россиялеләрнең берничә буынын берләштерүче әлеге бәйрәм – 1941 елның искиткеч авыр шартларында илгә киләчәк Бөек Җиңү хакына героик хезмәт башкаручыларның фидакарьлеге нәтиҗәсе ул. «Гранит мәңгелек»кә булачак «Казан Гипронииавиапром» АҖнең нигезен тәшкил иткән 6нчы Махсус проектлаштыру бригадасы (МПБ) хезмәтчәннәренең исемнәре язылган.

Казан Гипронииавиапром хезмәткәрләре – сугышта катнашучылар: Борисов М.К., Буханевич Б.К., Валеев З.З., Кутасин В.М., Магит М.Л., Немыкин Н.С., Павлычева Н.Е., Победимский Н.А., Скляров Я.Г., Склярова А.Е., Фадеичев Н.П.

Инде 30нчы еллар ахырында ук Казан авиазаводында хәрби самолётлар җитештерү эше җайга салынган була, шуңа да сугышның беренче айларында ук ТАССР башкаласына СССР Хөкүмәте карары белән иң кыска срокларда (нибары 10 көндә!) Мәскәүнең С.П.Горбунов исемендәге авиазаводы (22нче номерлы), Воронеж моторлар заводы (16нчы номерлы) һәм Ленинград авиазаводы (387нче номерлы) эвакуацияләнүе очраклы түгел. Завод эшчеләре алдына хәрби самолётларны – Пе-2 бомбардировщикларын, стратегик Пе-8 бомбардировщикларын һәм аларга двигательләр җитештерүне мөмкин кадәр арттыру бурычы куела. Бу мөһим бурычны үтәү өчен гамәлдә булган һәм эвакуацияләнеп килгән заводларның җитештерү егәрлекләрен киңәйтү һәм реконструкцияләү таләп ителә.

Проект документацияләрен эшкәртү һәм алар белән авиазаводларны тәэмин итү эше С.П.Горбунов исемендәге Мәскәү авиазаводы территориясендә 1941 елның октябрендә оештырылган 6 нчы Махсус проект бригадасына йөкләнә. Бригада авиация сәнәгатенең «Гипроавиапром» Мәскәү проект институты белгечләре, Казан проектчылары һәм эвакуацияләнгән авиаоешма хезмәткәрләреннән туплана. Бөек Ватан сугышы елларында 6 нчы МПБга алыштыргысыз рәвештә Мәскәү белгече Михаил Пазинич җитәкчелек итә. Аның кул астында 100дән артык проектчы яңа технологик линияләрнең проектларын эшли, гамәлдәге цехларны һәм җитештерү участокларын үзгәртеп коруны оештыра. Ул авыр елларда хезмәт иткән кешеләр арасында – Воронеж инженеры Николай Дёгтев (соңыннан ул бригада башлыгы була), Казан проектчылары Виктор Ларюков, Валентина Казанцева, Прасковья Толокнова (Пугачёва), А.Бекбулатова, С.Солдатова; авиация һәм мотор төзү заводлары инженерлары Зинаида Клименко, Борис Николаев, Анастасия Егорова. 1944 елда бригадага баш хисапчы Мера Кичкировская килә, һәм ул институтта 50 елдан артык эшли. 1944–1947 елларда 6 нчы МПБда төзелеш төркеме җитәкчесе Олимпий Грязев, проектчылар Николай Журавлёв, Юрий Терёхин, топограф Александр Крюков, баш хисапчы Анна Поташник, сметачы Сергей Семелькин үзләренең хезмәт биографияләрен башлый. 1949 елдан бирегә хезмәт юлларын архитектор Николай Победимский (ул чакта 6 нчы МПБ составындагы бердәнбер архитектор, Бөек Ватан сугышы ветераны) һәм инженер Юрий Мочалов дәвам итә.

Пазинич М.И.

Дёгтев Н.Н.

Көнкүреш кыенлыкларына һәм рисык ярлылыгына да карамастан (600–800 г икмәк һәм завод ашханәсендә төшке ашка талон), МПБ хезмәткәрләре тәүлегенә 11–12 шәр сәгать эшли. Самолётлар, двигательләр һәм корал конструкторлары фронт өчен кирәкле продукциянең техник һәм кулланыш характеристикаларын яхшырту өстендә даими эшләгәнлектән, нәкъ менә 6 нчы МПБ проектчыларына шулай ук даими рәвештә яңа технологик процессларны эшкә кушуда катнашырга, яңа җиһазларны урнаштыруны планлаштырырга, өстәмә җитештерү мәйданнарын проектлаштырырга яисә гамәлдәгеләрен үзгәртеп корырга туры килә. Техник документацияне эшләү белән беррәттән, бригаданың белгечләре, параллель рәвештә күпсанлы техник һәм оештыру мәсьәләләрен хәл итә барып, гамәлдәге җитештерүләрне реконструкцияләү эшләренә җитәкчелек итүгә дә турыдан-туры катнашалар.

Кырыс сугыш мәктәбен үткәч, демобилизациядән соң үзләренең яраткан эшенә – проектлаштыруга – Кызыл Йолдыз ордены кавалерлары инженер Николай Фадеичев, кадрлар бүлеге башлыгы Яков Скляров, склад мөдире Николай Немыкин, инженер Бронислав Буханевич; II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалерлары – проектчылар Зәйди Вәлиев һәм Наталья Павлычева кабат әйләнеп кайта, һәм соңыннан алар күп еллар дәвамында «Казан Гипронииавиапром»ында хезмәт куялар. Күрсәткән батырлыклары һәм кыюлыклары өчен инженер Михаил Борисов, сметачы Василий Кутасин, төзелеш бүлеге төркеме җитәкчесе Николай Победимский, контролёр Августина Склярова, бүлек башлыгы Моисей Магит «Берлинны алган өчен», «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

6 нчы Махсус проектлаштыру бригадасы хезмәткәрләренең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә Казан авиация заводлары сугыш елларында фронтны үтә кирәкле продукция белән туктаусыз тәэмин итә.

Бүгенге көндә, инде 75 елдан соң, «Казан Гипронииавиапром» АҖ элеккечә үк 6нчы МПБ геройларының исемнәрен хәтерендә саклый. Компаниядә җаваплылык, үз эшенә тугрылык традицияләрен саклыйлар һәм олылап баш иярга лаеклы 1941 ел геройларының рухларын хөрмәтләп искә алалар.

КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Иң тәмле гөбәдияне **КАЙДАН** эзләп таптык

Казан шәһәренә чынлыкта **НИЧӘ** яшь булырга мөмкин

Кирәксез балаларны **НИЧЕК** кирәкле итәргә

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе ял иткәндә **НИНДИ** китаплар укый

PRESSA.RU

Ярату ЯШӘГӘН ЙОРТТА...

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

«Олы кызыбыз Айсылу белән кече кызыбыз Гөлкәй яраткач, гөбәдияне гел пешерәм», – дип елмайды Тәти апа, безне каршылаганда. Тәти апа дигәнем, Кама Тамагының Келәнче авылында яшәүче Мөршидә Гомәрова. Бу якларда аның гөбәдиясен татып карамаган кеше юктыр. Кама Тамагының тагын бер күркәм гадәте – монда туган-тумача бер-берсенә матурдан-матур исемнәр белән эндәшә – Тәти апа, Тата апа, Алма апа, Матур апа, Тугания апа һ.б. Гадәттә, кунакка килгәч, шул йорт тәртипләренә, йолаларына үзеннән-үзе ияләшәсең, шуңамы икән, озак та үтмәде, мин дә Мөршидә апа диясе урынга «Тәти апа» дия башлавымны сизми дә калдым.

Автор:
Луиза Янсуар

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ДЕСЕРТ

Гөбәдия безнең халыкта гомер-гомергә затлы ризык, табын күрке саналган. Классификациясе буенча, ул катлы бәлешләр исемлегенә керә. Гөбәдиянең эченә кипкән корт, бөрттергән дөге, кыздырган суган белән иттарткычтан чыгарган ит, ваклап туралган йомырка, йомшарткан йөзем, күрәгә, төшен алып кара җимеш яисә өрек салалар.

Гөбәдияне әче камырдан да, төче камырдан да әзерлиләр, майны мул итеп салалар. Итле гөбәдияне табынга кайнар килеш икенче аш итеп бирәләр. Ит салып пешермәгән очракта, ул – чәй янына бирелә торган татлы ризык булып исәпләнә.

Мин үзем туып-үскән якларда, ягъни Питрәч районының Янсуар авылында, гөбәдияне әллә ни еш әзерләмиләр – затлы кунак килгәндә генә. Бездә күбрәк ит бәлеше өстенлек итә. Әбием 40тан артык туйга аргыш (туйны алып баручы, бүгенгечә итеп әйтсәк – тамада. – Л.Я.) булган кеше, ул да, хәтерлим, нигездә бәлешкә өстенлек бирә иде. Биек итеп әзерләгән, өстенә камырдан бизәкләр ясаган бәлешләре хәзер дә күз алдымда тора.

Тәти апаның әйтүенә караганда, бәлешне аларда да әзерлиләр. Әмма ул, ягымлы елмаеп, болай дип тә өсти:

– Шулай да бәлеш гөбәдияне алыштырмый, гөбәдия бит ул күбрәк чәй ризыгы.

Ягъни, заманча итеп әйтсәк, десерт була инде.

Сүзгә Тәти апаның тормыш иптәше Мәҗит абый кушыла:

– Бездә, сеңлем, – ди ул, – электәләктән дөге белән җимеш бәлеше пешерәләр иде. Ә ит бәлешен карабодай белән кушып әзерлиләр. Менә син ничек уйлыйсың, нишләп карабодайны шулай үз иткән халык?

Мин аргументлар китереп өлгергәнче, Мәҗит абый инде сүзен дәвам итә:

– Сәбәбе бик гади – әллә нинди «учёный» булмаса да, белгән халык – карабодайда тимер күп, ә тимер организм өчен иң кирәкле матдәләрнең берсе. Ул җитмәсә, кешенең көче, энергиясе булмый, гемоглобины түбәнәйгән кешегә дә юкка гына карабодай, җиләк-җимеш ашарга кушмыйлар бит. Өрек, караҗимеш – алары да тимер чыганагы...

Тәти апаның кулы кулга йокмый, без Мәҗит абый белән гәпләшкән арада ул инде барысын да әзерләп куярга өлгергән. Үзе, ирен читләре белән генә елмаеп, Мәҗит абыйга карап ала да, аннан миңа күз сирпи:

– Шундый инде ул безнең – профессорлар кебек сөйли!

Аның бу сүзләрендә үтә бер җылылык, наз бар. Гомумән, бу йортка аяк басуга, бөтен барлыгыңны шул наз биләп ала. Ярату яшәгән йортта гына була ул... Баксаң, Мәҗит абый әллә никадәр өлкәдә белгеч икән – һөнәре буенча агроном ул, озак еллар буе бухгалтер булып та эшләгән. Туганнары «безнең мичуринчы» дип йөртәләр үзен.

– Әнә, бакчада әллә ниләр майтарып ята, – дип, бакча якка караган

«Безнең якларда кыз кешенең бирнәсе һәрчак мулдан булды: тәрәзә челтәрләре, чиккән сөлге-тастымаллар, чабылдыклар, чаршаулар, дисеңме. Кыр-кыры челтәрләнгән япмалар карават читенә дә әзерләнә, өй буйлап сузар өчен дә. Бездә челтәр бәйләү гадәте киң таралган иде. Бирнәне сандыкка салып әзерләп куялар, туй көнендә кияү йортына сандык белән китерәләр».

Фото: Луиза Янсуар

PRESSA.RU

тәрәзәгә ымлый Тәти апа. Тәти апаның табынга әзерләгән сые кебек үк, Мәҗит абыйның бакчасы да муллыктан кайнап утыра.

«Безнең якларда, үлем-җитем булганда, савым илтәләр. Элегрәк күмәч салып алып бара идек. Янына он, ярма кебек нәрсәләр дә куела. Кеше шулай бер-берсенә авыр вакытларда ярдәм итә».

ТАШКЕНТТАН ГӨЛЧИРӘ БЕЛӘН ТӘСЛИМӘ КАЙТКАЧ...

Ул арада Тәти апа камыр әзерли башлады. Савытка сөт салды да өстенә 6 аш кашыгы сыек май агызды. Газ плитәсенә эретергә куйган сыер маен алып өстәде һәм чама белән тоз, шикәр комы сипте.

– Мин шулай чама белән эшләргә ияләшкән инде, – дип елмая үзе, – гел әзерләгән ризыкка күпме саласын күз дә, кул да үзеннән-үзе белә башлый бит ул. Аллага шөкер, биш кыз үстердек, гаиләләре белән алар кайтып керсә, йорт туп-тулы була, алар кайтышына берничә гөбәдия әзерлим, иренмим, яратып пешерәм. Өстәлгә куяр өчен дә, балаларга күчтәнәч итеп биреп җибәрергә дә. Хәзер бит, малайлар, бөтен нәрсә бар, тормыш җитеш, рәхәтләнеп пешер генә! Менә безнең заманда әйбере юк иде, алай да пешерәнә идек әле...

Искәрмә: «малайлар» дип Кама Тамагында ир затына гына түгел, хатын-кызларга да дәшәләр. Мәгънә спектры бик киң – гади мөрәҗәгатьтән башлап, иркәләп, үз итеп дәшүгә кадәр.

– Нәрсәләр пешерә идегез, Тәти апа? – дип төпченәм.

Бу якларның тагын бер затлы сые – төрле яшелчә-җимештән пешерелә торган пироглар икән. Безгә дә, килеп керешебезгә, чәй янына өстәлгә корт, алма пирогы китереп куйдылар.

– Кул астында нәрсә бар, шуннан әзерли идек инде ризыкны. Бакчадагы яшелчә-җимешнең өлгергән вакытына карап, кайсы җитешә, камырга төрәбез дә пешерәбез. Элегрәк, юк заманнарда, чөгендер, кишер пироглары да пешерәләр иде. Юка пешерә идек, бәрәңге авыл җирендә һәрчак бар, тиз генә кыстыбыен да ясап куябыз. Гөбәдия кебек затлы ризык әле соңрак килеп керде – сугыштан соңгы елларда гына. Ташкенттән Гөлчирә белән Тәслимә кайтканда пешереп карый идек, шуннан башланды...

Ул арада Тәти апаның камыры әзер булды. Ул аны җәяр алдыннан бераз ял итәргә, күперергә куйды да эчлек хәстәрләргә кереште. Дөгесен инде без килгәнче үк бүрттереп куйган иде. Бүртерүнең сере мондый икән: башта дөгене чистарталар, 1–2 кат салкын, берничә кат кайнар су белән югач, кайнап торган тозлы суга салып кайнаталар. Дөге таралып торсын өчен, суы дөгедән 6–7 тапкыр артыграк булырга тиеш. Кайнаганда, берничә мәртәбә болгатып алырга кирәк. Бүрткән дөгене, кайнар су белән юып, иләккә салып саркыталар.

Безгә кирәк булачак:



Фото: Луиза Янсуар

1. Камыр җәяргә әзер.

2. Корт белән эчлекне салабыз.

3. Йомырка уабыз.

4. Эченә дә май кирәк.

5. Өстенә камырны ябабыз.

6. Тышын майлыйбыз.

«Килен күрсәтү, чәйгә алу кебек йолалар бар иде. Никахтан соң яшьләрне туган-тумача, күрше-күлән белән якыннанрак таныштыру өчен эшләнгәндер инде бу, күрәсең. Чәйгә алу мәҗлесләренә берничә яшь пар чакырыла, табын әзерләнә. Килен күрергә килгәннәр үзләре дә буш кул белән килми. Никахтан соң, яшь парны кыз йортына чакырып берничә көн кунак итү гадәте дә булган. Үз заманының туй сәяхәте кебек булган инде бу».

Тәти апа әзерләп куйган җимешләрен юып чистартты да, гөбәдия эченә салырга янә май эретте. Аннан камыр җәяргә кереште.

– Әзер камырга кул ябышмасын өчен, сыек май өстәп җибәрәм, – ди.

«КЕР ҮЗЕБЕЗГӘ!..»

Тәти апа камыр җәя башлады. Җәймәсе күзгә күренеп зурая, түм-түгәрәк үзе. Мондый идеаль түгәрәкне заманында үземнең әбием җәйгәндә күзәтеп торып соклана идем... Ул арада мин:

– Ә сез Мәҗит абый белән ничек таныштыгыз? – дип, сүзне романтик якка борып җибәрдем.

Монда да сүзне җор телле Мәҗит абый элдереп алды:

– Бик кызык булды ул, – ди, мут елмаеп. – Шулай берсендә урамга чыккан идем, карыйм, Мөршидә басып тора – кулына мәктәпкә йөри торган букчасын тоткан. Әйдә, нишләп урамда торасың, кер үзебезгә, дидем дә алып кердем!

– Чынлап шулай булдымы? – дип гаҗәпләнәм.

– И шаярта, җаным! – ди Тәти апа. – Алай тик торганнан гына алып кайтып утыртмады инде...

Мәҗит абыйлар йортына килен булып төшкәндә, унсигезе туларга ике ай калган була Мөршидә апаның. Мәҗит абый 27 яшьлек карап торырлык егет була. Бу матур гаиләдә бер-бер атлы тупырдап торган балалар туа, хәзер инде оныклар куандыра. Мөршидә апа башта медпунктта эшли, аннары сыер сава.

– Оныклар – үзе бер куаныч, – ди ул. – Без бит үзебезнең балаларның үскәнен эш белән күрмәдек тә. Кайнанам бик булышты, шөкер. Мин яшь-яшь башым белән килен булып төштем бит, үз кызы кебек кабул итте. Аш-суга бик оста иде, таба ашын гел пешерде. Безнең заманда өйләрдән утны кичке 10да алалар иде, иртәнге 4тә бирәләр. Хәзерге кебек җан рәхәте кая ул?! Минем үземне туган-тумача, тирә-күрше туйларга, төрле кунакларга табын әзерләргә чакыралар иде – өйдә дә әзерләп бирә идем, барып та пешердем. Уңа иде камыр ашларым, шөкер...

Тәти апа, тыйнаклык саклап, үз теле белән әйтмәгән генә икән, аннары белдем: баксаң, алар Мәҗит абый белән туйларга, бәйрәмнәргә чыгыш ясарга, аларны алып барырга да чакырулы булганнар. Икесе дә бик матур җырлыйлар. Кама Тамагында «аргыш» сүзе кулланылышта булмаса да, күңелемнән генә Тәти апага мин аны беркетеп куйдым.

ТӘТИ АПАНЫҢ ЭЧКЕ СӘГАТЕ

Табаны майлады да, әзер җәймәне таба читеннән чыгып калырдай итеп җай гына урнаштырды. Гөбәдия, югарыда әйткәнебезчә, катлы-катлы булуы белән башка бәлешләрдән аерылып тора. Тәти апаның гөбәдиясендә алар менә нинди тәртиптә:

1нче кат – җәймәгә корт җәябез;

2нче кат – әзер эчлекне, ягъни бүрттерелгән дөге белән кушылган парланган йөземне салабыз;

3нче кат – өстенә каты итеп пешерелгән 6 йомырканы уып таратабыз;

4нче кат – юка гына иттереп янә дөге белән йөземнән гыйбарәт эчлекне өстибез.

– Олы табада пешергәндә, эченә 10–12 аш кашыгы эретелгән сыер мае салам, – ди Тәти апа. – Кече табага – 6–7 кашык та җитә. Мае мулдан булса, яхшырак инде. Дөге майны ярата ул...

Аннары, өстенә юка гына итеп җәйгән камырны япты да, табадагы камыр җәймәсенең тышка чыгып калган яклары белән тоташтырып, чит-читләрен бик матур итеп бөрмәләп тә куйды. Өстен майлады һәм чеметеп кенә шикәр, тоз, он сибеп җибәрде. Гөбәдиябез духовкага юл алды.

– Сәгатен карап торганым юк инде, җаным, кайчан өлгергәнен эчке сәгатем белән сизәм... – дип елмайды Тәти апа.

Искәрмә: 1) җаным – Келәнчегә кайтсагыз, аеруча Тәти апаларга кунакка сугылсагыз, бу сүзне ике җөмләнең берсендә ишетеп, колагыгыз көн буе иркәләнәчәк; 2) гөбәдиянең әзерләнү вакыты – 45–50 минут.

Тәти апа гөбәдияне икене пешерде ул көнне. Икенчесен махсус безнең өчен – кунакларга дип. Икенче көнне өй тутырып балалары, оныклары кайтырга тиеш иде – иртәгә икәү генә җитмәс, күбрәк әзерлисе булыр, дип сөйләнде, безне озатканда.

– Гөлсинә кызым да бик оста пешерә гөбәдияне, Гөлкәебез дә әзерли, әмма һәр кайтканнарында: «Әни, безнеке алай ук килеп чыкмый, син пешергәнне ашыйсыбыз килә», – диләр. И рәхәт шул сүзне ишетү...

PRESSA.RU

БАШКАЛАБЫЗ БОРЫНГЫРАК ТҮГЕЛМЕ?

Республикабыз территориясендә борын-борыннан яшәп килгән халыкларның биш меңгә якын тарих-археология истәлекләре сакланып калган. Шуларның ике меңгә якыны болгар чорына карый. Болгар, Биләр, Суар, Җүкәтау, Тубылгытау, Кашан, Ашлы, Чаллы, Кирмән ише болгар шәһәрләрен укып-ишетеп кенә булса да белмәүчеләр юктыр дип уйлыйм. Без ул истәлекләрне хаклы рәвештә, горурланып, халкыбыз тарихының җәүһәрләре дип йөртәбез. Шул җәүһәрләр арасында Казан кремле, борынгы Казаныбыз аерым урын били.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Гаҗәеп үзенчәлекле һәйкәл ул безнең Кремлебез! Аның мәһабәт таш диварлары, мәшһүр Сөембикәсе, калынлыгы дүртәр-бишәр метрга җитә торган культура катламы халкыбызның бөтен тарихын үзенә сыйдырган, сеңдергәндер кебек. Ләкин менә шул тарихны узган гасырның 90нчы елларында гына тирәнрәк итеп өйрәнергә мөмкинлек туды. Әлбәттә, беренче чиратта башкалабызның «туган елын» ачыкларга кирәк иде. Казан кремле җирлегендә 1994 елдан башлап үткәрелгән археологик казу эшләре нәтиҗәсендә бу сорауга ачыклык кертә торган яңа материаллар тупланды. Әлеге материалларны өйрәнеп, галимнәребез Казан каласына моннан 1000 ел чамасы элек, ягъни X гасыр ахыры – XI гасыр башында нигез салынган булуын расладылар.

1000 еллык юбилей матур гына үтеп китте, әмма башкалабызның «яшенә» кагылышлы сораулар калды. Һәм ул сораулар күпләрне бүген дә борчый. Берәүләр (алар арасында мөхтәрәм академик Мирфатыйх ага Зәкиев тә бар) Казан күпкә борынгырак, ул моннан 1100, 1500, хәтта 2000 ел элек барлыкка килгән булырга тиеш дип уйлыйлар, икенчеләре исә, киресенчә, ул – Алтын Урда яисә ханлык чорында гына нигезләнгән «яшь» кала, ә яманаты чыккан борынгы чех акчасын, имештер, казылмаларга археологлар үзләре үк ташлаган, дип тәкърарлый. Шунысын да искәртеп үтик: бәхәсләшүчеләр арасында башлыча фәннән ерак торучы дилетантлар өстенлек итә. Ничек кенә булмасын, сорауларны җавапсыз калдырырга ярамый.

Казанны тагын да борынгырак итеп күрсәтергә теләүчеләр колагына: шәһәрләр бары тик дәүләтчелек шартларында гына барлыкка килә алалар. Борынгы община строенда яшәүчеләрнең социаль-экономик үсеше әле шәһәрләр корырлык дәрәҗәдә югары булмаган. Безнең Урта Идел төбәгендә беренче дәүләт – Идел Болгарстаны – IX гасыр ахырында гына барлыкка килә. Нәкъ шул чорда, хәтта бераз соңрак, ягъни моннан 1100 ел чамасы элегрәк, Болгар, Биләр, Суар ише калаларга нигез салына. Тагын да борынгырак шәһәрләр бездә юк. Дөрес, соңыннан шәһәрләр калкып чыккан уңайлы җирләрдә кешеләр элек-электән яшәгән. Казан кремле территориясендә генә дә, мәсәлән, таш (б.э га кадәр VIII–IV меңьеллыклар), бронза (б.э. га кадәр II меңьеллык), элгәреге тимер гасырлары (б.э га кадәр I меңьеллык) чорында ясалган эш һәм сугыш кораллары, чүлмәк китекләре табылган.

Казан үзенең 1000 яшеннән борынгырак булырга мөмкинме? Теоретик яктан караганда, бу сорауга уңай җавап бирергә була, чөнки казылмалардан чыккан табылдыклар арасында X йөзгә карый торганнары да бар (мәсәлән, кулдан гына әвәләп ясалган балчык савыт-саба, гарәп дирһәме). Күпләрнең тынычлыгын югалткан чех акчасы да 930нчы елда сугылган. Әмма датасы төгәлрәк (±25–50 ел) билгеле булган башка табылдыклар юк. Шуңа күрә, хәзергә 1000 еллык дата белән чикләнеп торыйк.

Казанны XIV гасыр ахырларында яки Олуг Мөхәммәт чорында, XV гасырда гына салынган, дип уйлаучылар исә булган фактларны күрмәмешкә салыналар. XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башларында Кремльдә табылган акча хәзинәләре составында Алтын Урда акчалары күп. Кабан шәһәрлеге (элеккеге Архиерей дачасы) территориясендә 1297 елга караган кабер ташы билгеле. Төрле төзелеш, җир казу эшләре вакытында килеп чыккан очраклы табылдыклар арасында (алар Татарстан Милли музеенда саклана) хәтта монголларга кадәрге чорга караган әйберләр дә бар.

1970нче елларда атаклы галимебез Альфред Хәсән улы Халиков Казан кремлендә казу эшләре алып бара һәм XII–XIII йөз башларына караган табылдыкларга юлыга. Әмма ул җитәкләгән экспедициянең төп фәнни казанышы Казан кремлендә тупланган күп гасырлык культура катламының стратиграфиясен һәм хронологиясен нигезләүдә иде. Стратиграфия, гади тел белән әйткәндә, төрле чорда тупланган катламнарны аерып алу һәм тасвирлап язу дигән сүз. Безнең археология гыйлеме, нинди генә борынгы кала яки авыл урыны казылмасын, аның культура катламын өйрәнүдән башлана. Бу – эшебезнең иң җаваплы һәм иң катлаулы өлеше. Альфред Халиков үзенең бөтен игътибарын нәкъ менә шул борынгы катламнарга юнәлтә, аларны таба, үзенчәлекләрен өйрәнә һәм, нәтиҗәдә, Кремльнең бүгенге көндә дә иң камил саналган стратиграфик шкаласын төзи. Менә ул:

I катлам – XIX–XX гасырларда тупланган (без аны «хәзерге заман катламы» дип атыйбыз);

II катлам – XVI гасырның икенче яртысында, XVII–XVIII гасырларда тупланган (гадәттә «рус катламы» дип йөртәбез);

III катлам – Казан ханлыгы чорында, 1445–1552 елларда тупланган («ханлык катламы»);

IV катлам – Алтын Урда чорында, Казан мөстәкыйль билек (кенәзлек) үзәге булган вакытларда, ягъни XIII гасырның икенче – XV гасырның беренче яртысында тупланган («Алтын Урда катламы»);

V катлам – башкалабызның «балачагын» чагылдырган иң астагы, димәк, иң борынгы катлам. Яңа табылдыкларга нигезләнеп, без әлеге катламның хронологиясенә генә төгәллек керттек: ул X гасыр ахырында – XI гасыр башында һәм монголларга кадәрге чорда тупланган. Әйтергә кирәк, бу стратиграфия һәм хронология бәйсез экспертларыбыз – Мәскәү, Петербург һәм чит ил галимнәре тарафыннан да танылды.

Уртача калынлыгы 3–4 метр, кайбер урыннарда исә 10–12 метрга җитә торган культура катламының стратиграфиясенә басым ясап сөй-

Казан Кремле казылмаларында табып алынган таш гасыр чоры хезмәт кораллары.

Казан Кремле казылмаларында табылган таш балта калдыклары. Б.э.к. II меңьеллык.

Казан Кремле казылмаларында табылган тимер сөңге. Б.э.к. VIII–VII йөзләр.

ләвемнең сәбәбе шунда: мондый «ясалма» катламнар кеше яшәгән җирдә генә туплана һәм ул гади катлам гына түгел – биредә әйбер табылдыклары да бар, торак йорт урыннарының, хуҗалык һәм оборона корылмаларының калдыклары да, шул заманда казылган кечкенә генә чокыр эзләренә кадәр саклана. Аңлашыла ки, әлеге катламны, шәһәрнең датасын борынгылатам дип, өстән ташлап (ул акча түгел ич!), соңрак тупланган катламнар астына урнаштырып булмый.

Акча дигәннән. Әйе, Чехия дәүләтенә нигез салучы кенәз Вацлав тарафыннан 929–930нчы елларда сугылган акча табылган иде шул. Аның бүгенгегә кадәр дөньяда бердәнбер иң борынгы чех акчасы икәнен без ике елга диярлек сузылган тикшеренүләрдән һәм, шул уникаль табылдыкка багышлап, Прагада махсус симпозиум үткәрелгәннән соң гына белдек. Казанның туу елын исбатлауга аның катнашы юк диярлек. Үзегез күреп торасыз: чех акчасы Казан салынганга кадәр 70 ел элек сугылган. Ул бары тик шәһәребезнең элгәредән үк халыкара сәүдә пункты булганлыгын гына раслый. Әйдәгез, чех акчасын онытып торып (гүя ул булмаган да!), иң борынгы катламнан чыккан башка табылдыкларга тукталып үтик.

Менә ул табылдыклар: муенса төймәләре, бакырдан ясалган беләзекләр, йомшак шифер ташыннан ясалган орчык башы, тимер ук очлары, ат йөгәне бизәге, каеш пряшкәсе... һәм, әлбәттә инде, археологлар өчен иң кыйммәтле табылдыклар – чүлмәк китекләре. Әйе, керамика безнең фәндә үзләренә әллә никадәр мәгълүмат туплаган табылдыклардан санала. Шуңа күрә бик җентекләп, кызыксынып өйрәнәбез аларны.

Өстәлемдә – дистәләгән-йөзләгән чүлмәк китекләре. Мин аларны ике төркемгә бүлеп куйдым. Зур гына төркемдә махсус җайланмаларда формалаштырып, яхшылап яндырылган, кызыл-көрән төстәге югары сыйфатлы савыт-саба ватыклары. Аларны болгар бабаларыбыз монголларга кадәрге чорда – X–XIII гасыр башларында ясаганнар.

Икенче төркемдәге керамикага күз төшерик. Тупас кына итеп кулдан әвәләп ясалган кара-көрән төстәге чүлмәк китекләре. Дулкынга охшатып һәм сырлап төшерелгән бизәкләре дә бар. Бик кызыклы табылдыклар! Мондый савыт-сабалардан безнең болгар бабаларыбыз VIII–X гасырларда – әле алар Хәзәр каганлыгына буйсынып яшәгән дәвердә үк файдаланганнар. Ул XI гасырга кадәр яшәгән болгар шәһәр-авылларын казыганда еш очрый, аннан соңгыларында юк. Моннан бик кызык нәтиҗә килеп чыга: бүгенге Кремль территориясенә болгарлар X гасыр азакларында килеп чыгалар. Башка табылдыклар да бу фикерне раслыйлар.

Менә сердоликтан (кызыл карлыган төсендәге асылташтан) ясалган шарсыман муенса төймәсе. Бик борынгы чокырдан килеп чыкты. Мондый төймәләрне археологлар башлыча VIII–XI гасыр катламнарында табалар. Тагын бер төр төймәләр – тау бәллүреннән (хрусталеннән). Элгәреге мәҗүси болгарларның Танкеевка зиратыннан күп чыга алар. XI гасыр урталарына кадәр модада булып, аннан соң сирәк кулланылганнар. Өченче төр төймәләр тагын да борынгырак. Алар кара төстәге пыяладан ясалган, ак түгәрәк эчендәге зәңгәр «күзләр» белән бизәлгән. Мондый төймәләрдән җыелган муенсаларны VIII–X гасырларда гына тагып йөргәннәр. Коңгырт-кызыл төстәге пыяладан ясалып, өслегенә дулкынсыман ак бизәкләр төшерелгән озынча төймәнең датасын археологлар бары тик X гасыр белән билгеләләр. Кем белә, Биләр-Болгар, Суар һәм Җүкәтау ише эре калалардан ераграк урнашкан Казан якларында да мондый төймәләр бәлки әле XI йөз башларында да модадан чыгып бетмәгәндер?

Баш-башлары юанаеп килгән бакыр беләзекләр гадәттә күрше мари һәм удмуртларның IX–XI гасырларга караган каберлекләрендә очрый. Ат йөгәне каешын бизәү өчен ясалган бронза тәңкәләр бездә бик сирәк табылдыклардан санала, әмма Вен-

Казан Кремле казылмаларында табылган чех динары. X гасыр.

Казан Кремле казылмаларында табылган гарәп дирһәме. X гасыр.

X–XI гасыр башында яшәгән борынгы болгарларның Казан Кремле казылмаларында табылган кулдан ясаган чүлмәк китекләре.

Казан Кремле казылмаларында табылган груша рәвешендәге XI гасыр асма бизәге.

Казан Кремле казылмаларында табылган бакыр беләзекләр. XI гасыр – XIII гасыр башы.

гриядә X гасыр урталарына кадәр күмелгән каберлекләрдә еш табыла.

Сүз дә юк – кызык табылдыклар. Тик болар гына Казанның XI йөздә үк кала (крепость) буларак яшәгәнен раслый алмыйлар әле. Монголларга кадәрге дәвердә махсус нгытылган торак пунктларын гына шәһәр дип йөрткәннәр. Шәһәр халкы башлыча һөнәрчелек, сәүдә, хәрби эш белән шөгыльләнгән. Казу эшләрен дәвам итеп, Казанның иң борынгы нгытмаларын, йорт һәм хуҗалык корылмаларын ачарга кирәк иде. Шөкер, бу ачышлар да ясалды. Благовещение соборы янында казыганда борынгы нгытма эзләренә – балчыктан өеп ясалган биек вал һәм аның өстенә куелган агач стена калдыкларына тап булдык. Бу нгытмаларны XI йөз башында төзегәннәр (элегрәк булмаса әле). Димәк, безнең алда гади авыл түгел (табылдыклар арасында урак, чалгы ише әйберләр дә юк), бәлки яхшы ук нгытылган торак пункты. Бары тик хәрби крепость кына ул дип әйтү дә дөрес булмас, чөнки табылдыкларга карагыз: күрше урыс кенәзлекләреннән китерелгән шифер орчык башлары, пыяла беләзекләр, йозаклар, Иранның Рей һәм Кашан шәһәрләрендә эшләнгән ялтыравыклы нәфис савыт-сабалар, Балтыйк диңгезе буеннан китерелгән гәрәбә, Венгриядән, Чехиядән, ерак гарәп илләреннән кайткан әйберләр. Әйе, боларның барысы да Казан халкының эчке һәм тышкы сәүдә белән тыгыз бәйләнгән булуы турында сөйли. Шик юк: борынгы Казан – Идел Болгарстанының төньяк чикләрен саклау өчен махсус төзелгән хәрби нгытма гына түгел, ә зур елга буенда урнашкан эре сәүдә үзәге дә булган икән. Казанның барлыкка килүендә халыкара сәүдә хәлиткеч факторлардан саналырга тиеш, дип уйлыйм.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: табылдыкларның датасын башта үзебез билгеләдек, аннан соң аларны чит ил галимнәренә – бәйсез экспертларга күрсәттек. Мәсәлән, муенса төймәләрен Голландия галиме профессор Йоһан Кальмер, ат йөгәнен бизәү өчен кулланылган бронза тәңкәне Будапешт университеты профессоры Иштван Фодор тикшерде. Чын сенсациягә әверелгән чех акчасын, Мәскәү һәм Петербург нумизматларыннан соң, Прагадан доктор Ярмила Һаскова җентекләп өйрәнде. Борынгы катламнан табылган көмеш дирһәмнең X йөз башында ук (920нче елга кадәр) сугылган булуын Каһирәнең Айн-Шамс университеты профессоры Гадел Совелам һәм Мөхәммәд әл-Сәид Гамәледдин исбатлады.

Галимнәрнең бердәм фикере шул иде: Казан кремлендә табылган иң борынгы әйберләр һәм, димәк, бирегә болгар бабаларыбызның килеп урнашу вакыты X гасыр ахырына – XI гасыр башына карый. Шул чорда – элегрәк тә түгел, соңрак та! – хәзерге Кремль калкулыгында беренче торак пункты – болгар каласы барлыкка килә.

Археологлар тарафыннан тәкъдим ителгән әлеге дата соңгы елларда фәнебездә киң таралган яңа ысуллар – агач күмерен радиоуглерод (C14) һәм керамиканы термолюминесцент ысуллары кулланып тикшергәннән соң янә бер мәртәбә расланды. Бу эштә безгә Вена университетыннан доктор Петер Штадлер һәм Берлин дәүләт музееннан профессор Йозеф Ридерер бик теләп ярдәм иттеләр.

Тагын шуны искәртеп үтәргә кирәк дип саныйм: нинди генә фәнни ысуллар кулланылмасын, археологик табылдыклар барыбер төп-төгәл датаны бирә алмый. Әйткәнемчә, Казанның барлыкка килү вакыты X гасыр ахырына – XI гасыр башына туры килә. Төгәлрәк билгеләп булмый. Алайса, 1005 ел каян килеп чыкты? – дип сорарсыз. Шартлы дата ул: 20– 25 елга иртәрәк, 20–25 елга соңрак нигез салынган булуы мөмкин башкалабызга. Шулкадәр борынгы тарихыбыз өчен бу төгәлсезлек әллә ни әһәмиятле түгел, минемчә. Казанның олуг юбилеен галимнәр тәкъдиме белән 2005 елда уткәрергә карар кылдылар. Хакыйкатьтән тайпылыш юктыр, дип уйлыйм.

PRESSA.RU

«ДӘҮЛӘТ ҮЗ ХАЛКЫ БЕЛӘН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШЕРГӘ ТИЕШ»

Индус ага Таһиров кебекләр турында «аяклы тарих», диләр – ул бөтен гомерен татар тарихын өйрәнүгә багышлап, академик дәрәҗәсенә ирешкән шәхес. 24 майда галимгә 80 яшь тулды. Индус Ризакович 30 елдан артык Казан федераль университетының тарихи фәннәр буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклау советын җитәкли. Шул рәвешле ул тарих белән кызыксынучы күп кенә яшьләргә канат куя. 1992 елдан ул, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетын оештыруда катнашып, 2002 елга кадәр аның рәисе була. Индус Таһиров 1995–2009 елларда ТР Дәүләт Советында депутат булып, иҗтмагый эшчәнлектә актив катнаша, аның ялкынлы чыгышларын бүген дә күпләр хәтерли.

Автор:
Линар Закиров

– ТАРИХКА КЫЗЫКСЫНУНЫ ТАТАРЛЫГЫМ УЯТТЫ

– Индус абый, балачагыгыз сугыш елларына туры килгән. Шул чордагы кайсы вакыйгалар, хис-кичерешләр аеруча истә калды?

– 1941 елның июнендә әтине фронтка озату. Аны озатырга бертуганы Кыяметдин абзый да барган иде. Шулчак әти безгә кибеттән мандолина алып бирде. «Мин кайтуга уйнарга өйрәнеп куегыз», – диде. Ул романтик рухлы, бик матур җырлый иде. Фронттан язган хатларында әтиебез сугышның туктап торган чагын: табигатьне, кошлар сайравын, хәтфә үләннәрне, тулышып пешкән җиләкләрне шулкадәр матур итеп тасвирлый иде. Әни аны озатырга Келәүле станциясенә кадәр китте. Кыяметдин абзый безне җитәкләде дә үзе: «Еламагыз, балалар. Әтиегез тиздән кайтыр», – ди, ә үзенең күзеннән яшь ага.

Әтиебез 1944 елның ноябрендә рота командиры вазыйфасында Латвияне азат иткәндә һәлак була. Аның Аутц өязендә җирләнгәне турында хәбәр килде. Аспирантурада укып йөргән чакта әтинең каберен эзләп чыгып киттем.

Ригага килеп җиткәч, автобуска күчеп утырдым. Бергә барган латышлар, кем икәнлегем, каян килүем белән кызыксына башлады. Әтием турында сөйләгәндәге хис-кичерешләрем аларның үзәгенә шулкадәр үтеп керде, барысы да, була гына күрсен, дип теләде. Аутцка барып җиткәч, хәрби комиссариатта: «Аутцның беркайчан да өяз булганы юк. Республика военкоматына барыгыз, анда шушы эш белән фәлән полковник шөгыльләнә», – дип, кабат Ригага җибәрделәр.

Чыксам, тагын шул ук автобус һәм шул ук кешеләр. Гөнаһ шомлыгына, коеп яңгыр ява башлады. Автобус туктады. Латышлар, хәлемә кереп, шоферга, бернигә дә карамастан юлыбызны дәвам итик, диделәр. Кузгалдык. Шәһәргә кергәч, халык автобус йөртүчегә хәрби комиссариат янына ук килеп туктарга кушты. Юкса, ул бит рейс автобусы. Латышлар безне яратмый, дибез. Дөрес сүз түгел, бик яраталар.

Мин килеп җитүгә, хәрби комиссариатта эш вакыты тәмамланып килә, офицерлар өйләренә кайтырга җыена иде. Фәлән полковникны ничек табарга була, дип сораша торгач, берзаман ул үзе каршыма килеп чыкты. Полковник мине кабинетына алып кереп, документларны тапты да әтинең Салдус шәһәрендәге туганнар каберлегендә җирләнгәнен әйтте.

Икенче елны шул шәһәргә барып, исемлектә әтине табуын таптым, әмма истәлек ташында исеме юк. Исемен яздырырсыз, дип старшинага акча биреп калдырдым.

Бер елдан энем Энгель белән әнине алып бардык. Аны кунакханәгә урнаштырдык та үзебез каберлеккә киттек. Карасак, ташта әтинең исеме юк. Болай булмый, дип райкомга барып, беренче секретарь янына кердек. Ул телефон аша хәрби комиссариаттагыларны, «хәзер үк эшләп куегыз», дип пыр туздырды. Барып карасак, исеме, чыннан да, язылган. Әни әти җирләнгән туганнар каберлеге янында намаз укыды. Шуннан туфрак алып кайтып, гөл утыртты. Алар әниебез бу дөньядан киткәнчегә кадәр чәчәк атып утырды.

– Мандолинада уйнарга өйрәндегезме соң инде?

– Барыбыз да өйрәндек. Әнинең бертуган абыйсының кызы Тәнзилә мандолинада бик матур уйный иде, әтигә шул тәэсир иткән булган, күрәсең.

– Тарих белән кайчаннан кызыксына башладыгыз?

– Нишләп безнең төбәк автономия республика гына, дәүләтчелегебез кайчандыр булдымы икән, дип яшь чактан уйлана башладым. Тарих белән кызыксынуымны татарлыгым уятты.

Әти сугышка киткәч, әнине Түбән Чыршылы авылына мәктәп директоры итеп билгеләделәр. Заманында анда бик зур мәдрәсә булган, Һади Атласи, Ризаэтдин Фәхретдин укыткан. Сугыштан соң Шөгергә кайттык. Шул чактан бирле бик күп укый идем. Без, бер төркем малайлар, тезелешеп, китапханәгә китәбез дә китаплар алып кайтабыз, аннары аларны алышып-алышып укыйбыз. Латин шрифтында басылган китаплар күп иде, инглиз телен өйрәнгәч, ул хәрефләр безгә ят булмады. Әниебез татар теле укытучысы иде, туган якны һәм туган телне ярату аңардан килә.

Фото: Александр Эшкинин

PRESSA.RU

– САБАН ТУЕНДА КАТНАШУ БЕРКЕМГӘ ДӘ ТЫЕЛМЫЙ

– Сез Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының беренче рәисе дә бит. Ул вакытта нинди максатларны беренче урынга куеп эш иттегез? Аларга ирешә алдыгызмы?

– Татарның проблемалары күп, ул төрле халыклар арасында төрле җирләргә чәчелеп яши. Сеңү, югалу кебек куркыныч күренешләр хәзер дә бар. Сибелеп яши торган татар халкы үзен бер милләт итеп тоеп яшәсен, дигән максат белән эшләдек. Төбәкләрдә татарларның җирле оешмалары безнең катнаштан башка барлыкка килгән иде инде, бу татарның уянган вакыты иде.

Күчмә утырышларыбызны төбәкләрдә еш үткәрдек. Конгрессның башкарма комитетына Татарстанның матбугат, мәгариф, мәдәният министрлары керә иде, утырышларга җирле хакимият вәкилләрен дә чакырып, сөйләшү дәүләти төстә узды.

Бик күп губернаторлар белән аралаштым, татарларның русларга, Россиягә бернинди куркыныч тудырмаганын, киресенчә икәнлеген исбат итеп эшләргә туры килде. Свердловск өлкәсе губернаторы Эдуард Россель, Удмуртиянең беренче президенты Александр Волков, Саратов өлкәсе губернаторы Дмитрий Аяцков белән якын мөнәсәбәттә идек. Татарларга бер тапкыр да каршы чыкканнары булмады.

Чит илләр арасыннан Төркия белән махсус рәвештә эшләргә туры килде. Беренчедән, төрекләр безгә тугандаш халык, икенчедән, анда моннан киткән күп татарларыбыз, хәтта татар авыллары бар. Төркия хакимияте безгә һәрвакыт тиешле игътибар күрсәтте. Истанбул губернаторы безне капка төбендә үк каршы алып, капка төбенә кадәр озатып җибәрде. Америкада, күп булмаса да, күренекле шәхесләребез бар. Вашингтондагы, Нью-Йорктагы милли оешма җитәкчеләре белән дә очрашулар үткәрдек.

– Конгрессның бүгенге эшчәнлеген күзәтәсезме? Аны, Сабан туе үткәрү өчен генә җаваплы оешмага әйләнеп калды, дип еш кына тәнкыйть утына тоталар.

– Чит төбәкләрдә Сабантуй үткәрүне дә без башлап җибәрдек. Ләкин ул вакытта бәйрәмебез милли горурлыкны уята торган искиткеч үтемле чара иде. Бүген ул, бәлки, формаль рәвешкә кереп барадыр.

Конгресс эшчәнлеген читтән генә күзәтәм. Аның аппараты бик зур, диләр. Андый аппарат һич тә кирәк түгел, кеше күп булган саен, оешмадагы система бюрократиягә әйләнә. Без эшләгәндә үз куышыбыз да юк иде, Ирек мәйданындагы хәзерге бинаны соңрак кына алдык. Безнең аппаратта 7–8 кеше генә иде.

– Сабан туеның интернациональ бәйрәмгә әверелүен хуплыйсызмы? Әллә ул үзебезнеке генә булып калырга тиешме?

– Татарлар кунакчыл халык. Сабан туе – безнең бәйрәм, ә менә андагы кунаклар кемгә килгәнлекләрен белергә тиеш. Сабан туеның миллилеген, һичшиксез, беренче урынга куярга кирәк. Анда катнашу берәүгә дә тыелмый, килсеннәр, күрсеннәр. Без аны Вашингтонга, Истанбулга да барып үткәрдек.

– СЕЗ РОССИЯДӘН ЧЫГАСЫЗМЫ ӘЛЛӘ?

– Дөньяда татарларга мөнәсәбәт ничек? Россия халкының мөнәсәбәтеннән аерыламы?

– Мәскәүдә Фәрит Фәрисов исемле милли җанлы активист бар, ул Мәскәү татарлары турында фильм да чыгарды. Аның: «Выше татар только небо», – дип әйткән сүзе бар. Милли горурлык булганда, тел дә, гореф-гадәт тә саклана. Татар факторы бүген искиткеч зур. Россия белән Татарстан мөнәсәбәтләре башка юнәлештә корылган, без бит 1990 елның августында Декларация кабул иттек, ә ул бүтән өлкә-республикаларның килешүләреннән аерыла.

Үзебезне Россия составында түгеллегебезне күрсәтү өчен, әлбәттә, көрәшергә туры килде. Әгәр Татарстанны Россия составында итеп күрсәткән булсак, СССРга Россия аша гына керү булыр иде. Мәскәүдә моны шактый вакыт аңламый да тордылар, бер ел Декларация уңаеннан мөнәсәбәт белдерелмәде. Татарстан союздаш республика булырга әзерләнеп тә йөрде. Шул турыдагы килешүгә кул кую вакыты якынлашкан саен, Мәскәүдә уйлана башладылар. Россия һәм Татарстан Президентлары – Борис Ельцин белән Минтимер Шәймиев сөйләшеп, шушы мәсьәләне тикшерү өчен ике комиссия төзелде. Мәскәү делегациясен Ельцинның уң кулы – Россиянең дәүләт секретаре Геннадий Бурбулис җитәкләде, ә безнекен – республика вице-президенты Василий Лихачев. Делегациябезгә министрлар, Дәүләт Советы депутатлары да керде. Ул вакытта депутат түгел идем әле, ләкин Минтимер Шәймиев мине делегация җитәкчесенең урынбасары итеп билгеләде. Моңа ризасызлык белдерүчеләр дә булды. Әмма Шәймиев: «Нәрсә эшләргә кирәклеген үзем беләм», – дип кырт кисте.

РФ Хөкүмәте рәисе урынбасары Сергей Шахрай: «Сез Россиядән чыгасызмы әллә?» – дип сорады. «Россиягә үз теләгебез белән кергәнебез дә булмады. Шуңа күрә бу соравыгыз урынсыз», – дидем. Шуннан соң ул: «Россиядән чыкмыйсыз һәм аның составына кермисез дә булып чыгамы?» – диде. «Дөрес фикерлисез, Сергей Махійлович», – дидем. Ләкин кул куярга берничә көн кала, ГКЧП килеп чыкты. СССР беткәч, 1992 елда Мәскәү делегациясе белән янә очраштык.

– Шул очрашу нинди нәтиҗәләргә китерде?

– Россия делегациясенә күптән түгел генә кертелгән милләтләр эше буенча министр Валерий Тишков да сөйләшүләр вакытында: «Сез Россиядән чыгасызмы әллә?» – дип сорады. Бурбулиска карадым да: «Геннадий Эдуардович, бу сорауга җавап бирәсезме?» – дип эндәштем. Ул Тишковка карады да: «Татарстанга мондый ахмак сораулар бирмәгез», – диде. Ахыр чиктә, берничә килешү имзаланды.

Шуннан соң икътисадый мәсьәләләр буенча килешү әзерләдек. Мин финансист та, икътисадчы да түгел, әмма ТР Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров шушы делегациягә керүемне сорады. Мәскәү делегациясен Россия хөкүмәте башлыгы Егор Гайдар җитәкләде. Атнадан артык сөйләшүләр алып барып, Татарстанда милли банк төзү турында килешенде. Нефть мәсьәләсе дә кузгатылды. Без ул вакытта елына 28,5 миллион тонна кара алтын чыгара идек. Яртысын үзебездә калдырабыз, дип сөйләштек.

Ике делегациянең соңгы очрашуында Мөхәммәт Сабиров беренче булып миңа сүз бирде. Егор Гайдар: «Сезнең Декларацияне таныйбыз», – дигәч, «Бубликтагы тишекне таныгандай таныйсыз», – дип, кызып китеп әйттем. Бу сүзем Гайдарның да ачуын китерде. «Череп беткән нефть сәнәгате белән нәрсә эшләргә җыенасыз соң?» – дип тузына башлады. Сабиров ярдәмгә килде: «Сатарбыз», – диде. «Кемгә?» – дип сорады Гайдар. «Сезгә. Казан ханлыгы чорындагы кебек», – дигәч, барысы көлеште дә, хәлләр җайланды. Шулай итеп, Мәскәүдән милкебезне танытып кайттык.

Индус ага Таһиров хатыны Люция ханым һәм улы Илдар белән.

– ТАТАРЛАР – ТӨРКИЛӘРНЕҢ ИҢ ЗАТЛЫ ТАМЫРЛАРЫННАН

– Бер әңгәмәгездә: «Кешене ышандыру, күндерү сәләтем бар», – дисез. Бу осталыкка ничек ирештегез?

– Ул ата-ана тарафыннан бирелгән һәм белем белән ныгытылган сәләт. Эшлекле сөйләшүгә әзерлекле булып барудан күп нәрсә тора. Мәскәү белән Татарстан делегацияләрендә катнашучылар да, теге вакыттагы очрашып сөйләшүләр фәнни семинар рәвешендә үтте, диде. Теге як безгә сорау бирә, без аргументлар нигезендә җавап бирәбез, алар тагын каршы сөйли. Шул вакыттагы сөйләшүләр барышында Мәскәү безнең өстенлекне таныды.

– Әйтик, Татарстан союздаш республика булып танылды, ди. Аның яшәешен, булмышын ничек күз алдына китерер идегез? Татарстан элеккеге союздаш республикалар сыман Россия белән чиктәш түгел, аның үзәгендә урнашкан бит.

– Андый сорауны еш бирделәр. Союздаш һәм автономия республикалары бертигез булырга тиеш, дигән прицыпны һәрчак алга сөрдек. Башкортостанга да безнеке сыман декларация кабул итәргә тәкъдим иттек. Алай эшләсәгез, мөмкинлекләрегез күбрәк булачак, дип аңлаттык. Алар үз республикаларын 1917 елның декабрендә үк игълан иткән, ягъни ул декрет белән туган республика түгел. Башкортостанның, Украинаныкы сыман, бик зур хокуклары танылa, ә ул вакытта Украина бәйсез дәүләт сыман санала иде. Башкортостанның хәтта тышкы эшләр алып бару хокукы була. Гражданнар сугышының нәтиҗәсе билгеле булгач, 1,5 елдан соң килешү гамәлдән чыгарыла.

Сезнең хокукларыгыз бозылган, шуларга таянып, яңа декларация кабул итә аласыз, дидек үзләренә. Ләкин башкортлар аны үзләренең Югары Советы аркылы үткәрә алмады, каршы көчләр күп булды. Шәймиев бик борчылды: «Фикердәшләрсез калдык», – диде. «Минтимер Шәрипович, алар бит бернәрсә югалтмады, заманында Россиягә ирекле рәвештә керүләрен таныганнар. Шуның өчен алар өстенлекләргә ия булган. Ә безнең Россиягә ирекле рәвештә кергәнебез юк», – дидем.

Татарстанның Россия эчендә яки тышында булуы әһәмиятле түгел. Мәскәүдә, ә башка төбәкләр нишләр, дигәч, безнең анда эшебез юк, алар белән үзегез сөйләшегез, дидек. Ул төбәкләрнең Мәскәү белән безнең сыман дәрәҗәдә сөйләшергә мөмкинлекләре һәм әзерлекләре булмаган, бүген дә юк. Без Президент атамасын саклап кала алдык, ә алар?

Татарстанны читтәге руслар горур республика дип атый иде. Геннадий Бурбулисның да: «Татарстан башкаларны үзе артыннан ияртә торган әхлакый вектор булдыра», – дип әйткәне бар. Татар факторы шушы була инде. Татарстан һәм татарлар бүген Россиянең иң ныклы терәкләренең берсе. Союздаш республика турында килешүгә кул куеп өлгергән булсак, СССР таркалса да, без бәйсез дәүләт булыр идек инде.

– Бүгенге глобальләшү шартларында татарны милләт буларак кем саклап кала ала? Шушы җәһәттән татар элитасына нинди өметләр баглыйсыз?

– Татарны бетерергә тырышу 1552 елдан бирле бара. Нәрсә генә эшләнмәде, ни генә кыланмадылар, нинди генә законнар чыгарылмады. Татарны бетереп булмый, чөнки безнең тамырларыбыз тирәндә.

Күптән түгел «Голос Евразии» китабының тәкъдир итү кичәсе узды, әлеге хезмәттә татар атамасының Кытай чыганакларында ике мең ел элек барлыкка килүе турында язылган. Ни өчен Кытай җырларында татар моңы ишетелә? Чөнки Кытай тирәсендә яшәгән бабаларыбыз Казан тирәсенә күчеп киткәндә, кытайларга моңыбызны бүләк итеп калдыра. Бу тамырларыбызның тирәнлеген күрсәтә. Аны йолкып алып булмый.

Татарлыгыбызга ислам, ягъни болгар тамырлары да килеп кушыла. Кытай ягыннан килгән татарлар кыргыйрак булса, болгарлар бөтенләй башка. Биредә шәһәрләр төзү, җир эшкәртү сәнгате иң югары биеклеккә җитә. Ул вакытта Европада андый шәһәрләр булмый, Парижда пычрак суны әле тәрәзәдән түгә торган булалар. Бездә җәмәгать бәдрәфләре, сүүткәргечләр дә эшләп тора. Татарлар төркиләрнең иң затлы тамырларыннан барлыкка килгән, дип әйтергә яратам.

Дингә махсус игътибар бирергә тиешбез. Халкыбыз исламны кабул итмәгән булса, бәлки, татарлар хәзерге рәвештә сакланып калмаган да булыр иде. Бүгенге дин әһелләре дә татарлыгыбызны беренче урынга куеп эш итәргә тиеш.

Иң авыр елларда – XIX–XX гасыр чигендә татарлар яңарыш кичерә, бернечә ел эчендә утыздан артык газета-журнал барлыкка килә. Аның өчен элита, журналистлар, аларны чыгару өчен матди чаралар кирәк. Бу халыкның яшәү көчен күрсәтә. Башка төрки һәм төрки булмаган халыкларга йогынтыбыз зур булган. Чуваш, мариларны әйтмим дә, алар һәрвакыт безнең йогынтыда яши.

Телне элита һәм халык үзе сакларга тиеш. Татарлык бит кешенең канына сеңгән, тел балада туганчы ук була. «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән», дигәндәй, Аллаһ биргән телне беренче булып әни кеше ачарга тиеш... Теге закон, бу закон юк, дип хөкүмәткә кизәнәсе урынга, башта өеңдә эшлә, балаңны татар итеп дөньяга чыгар. Шуннан соң ул бернәрсәгә дә бирешми торган булачак. Бүгенге татар элитасы бик көчле, ул Казанда гына түгел, бөтен җирдә бар. Татарлыкны саклаучылар – язучы-шагыйрьләр генә түгел, араларында гап-гади татарлар да күп.

Дәүләткә дә дәгъвалар бар. Ни өчен әле татар теле дәүләт теле түгел? Хөкүмәт бүген үз халкы белән татар телендә сөйләшергә тиеш. Әгәр сине татар кешесе булганга министр иткәннәр икән, үз халкың белән матур итеп татарча сөйләшә беләсеңме? Министрлык материаллары да татар телендә чыгарга тиеш, кызганыч, бүген эшләр шушы рәвештә алып барылмый.

– Дәвамчыларыгыз бармы?

– Яшьләр арасында тарихны әйбәт белүчеләр күп түгел, ләкин бар. 9 нчы классны тәмамлаган оныгым Каюм намаз укый. Кем булса да, намуслы, чын татар булып үссен. Тегендә бар, болай эшлә, дип аны кыстап йөрүче юк. Үзен кайсы өлкәдә күрә, шунда хезмәт куйсын, без аңа ярдәм генә итә алабыз.

PRESSA.RU

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИННЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

«Татарстан»ның китап киштәсен» уңышка ирешкән күренекле кешеләрнең китаплары белән тутыруны дәвам итәбез. Үз казанышларында китапның мөһим урын алып торуын алар һәрдаим ассызыклый. Һәрберсенең үз «киштәсе» бар, андагы басмалар да миссиясен тиешенчә башкарган: йә һөнәр сайларга булышкан, йә уй-фикерләрне дөрес юнәлешкә борып җибәргән, йә тирә-юньдәгеләрне, тормышны яхшырак аңларга ярдәм иткән…



Фәрит Мөхәммәтшин,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе



1. БАЛАЧАКТА УКЫРГА ЯРАТА ИДЕМ…

– Минем буын балалары өчен сугыш китаплары беренче урында булды. Алар әллә ни күп тә түгел, нигездә, мәктәп китапханәсеннән алып укый идек. Бу – Аркадий Гайдар, Лев Кассиль, Борис Полевой әсәрләре. Сергей Михалковны укырга ярата идем. Аның шигъриятендә иптәшлек, дустанә мөнәсәбәт, эшкә мәхәббәт кебек сыйфатлар хакында сүз бара, тәрбияви көче зур ул шигырьләрнең. Михалковның «Дядя Стёпа»сы, минемчә, һаман да якты совет балачагының символы булып кала бирә…



2. ЯҢА ГЫНА УКЫДЫМ…

– Ни кызганыч, эш белән китап укырга вакыт аз кала. Кыска вакытлы ял мөмкинлеге тиде дә, менә яңарак кына Венера Якупованың «Добро и зло российской журналистики» китабын укып чыктым. Ул журналист һөнәренең киләчәге хакындагы уйлануларны һәм әңгәмәләрне туплаган. Мине дә уйландырды…

3.
ИҢ ЯРАТКАН ӨЧ КИТАБЫМ

– Әлбәттә, иң беренче урында – Тукай әсәрләре, алар минем күңелдә генә түгел, һәр татарстанлы йөрәгендә эз калдыргандыр, дип уйлыйм. Нәкъ менә аның һәм әдәбиятыбызның нигезен тәшкил иткән башка татар язучыларының әсәрләре аша мин татар әдәби теленең матурлыгын тойдым һәм үз халкымның тарихын белә алдым…

Үз вакытында Гариф Ахуновның легендар романы – «Хәзинә»не йотлыгып укыдым. Хәтерлисездер, ул Татарстан нефтьчеләре тормышы турында.

Миңа китапларны еш бүләк итәләр, нигездә, болар – атаклы шәхесләрнең мемуарлары, аларда чор сулышы һәм шул чорда яшәүче кешеләрнең дөньяга караш-мөнәсәбәтләре ярылып ята. Күп кенә татар язучылары, мәсәлән, парламент белән тыгыз бәйләнештә – Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим һ.б. Минем татар телендә укыган иң соңгы китабым – Туфан Миңнуллин турында. Ул татар әдәбиятының классигы турындагы истәлекләрне туплаган. Туфан мине татар халкының язмышы турында киңрәк, тирәнрәк уйларга өйрәткән язучы ул.





4.
СЕЗГӘ УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ…

– Күренекле тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, ТР Фәннәр академиясе академигы Индус Таһировның 80 яшьлеге уңае белән басылып чыккан «По жизненному пути» китабын.

5.
КӘГАЗЬ КИТАПМЫ, ЭЛЕКТРОН ВАРИАНТМЫ?

– Миңа каты тышлы кәгазь китап электрон китапка караганда күбрәк ошый. Өстенлекне аңа бирәм. Кулга тотып, битләрен актарып була торган, типография буявы исе аңкыган китаплар беркайчан да үз укучысын югалтмас, дип уйлыйм.

6.
ТОРМЫШЫМДА КИТАПНЫҢ ТОТКАН УРЫНЫ

– Һәр китапның үз вазыйфасы бар. Кайберләре тәрбияле, икенчеләре уйландыра – фикерләреңне тәртипкә китерергә, билгеле бер эзлеклелеккә салырга булыша. Әлбәттә, китапның иң төп миссиясе – мәгърифәт нуры тарату, юкка гына аны гомер-гомергә «белем чыганагы» дип атамаганнар.

Ни кызганыч, замана кешеләренең китапка мөнәсәбәте үзгәрде. Аңа вакытлары калмый. Димәк, китапка мәхәббәтне кайтара алырдай, укуны пропагандалый торган акцияләр уздырырга кирәк. Әле яңарак кына «Россия-1» каналында күренекле кешеләр Лев Толстойның «Война и мир» романын укыдылар. Минемчә, мондый яңа формаларны бездә дә кертергә кирәк.

PRESSA.RU

Фото: Ната Смирнова

КИРӘКСЕЗ БАЛАЛАРМЫ?

Балаларны яклау көне алдыннан «Татарстан» журналы «кирәксез» балаларга, төгәлрәге, әлеге балалар үзләрен кирәксез итеп түгел, киресенчә, кирәкле, гомумән, бәхетле итеп тойсыннар өчен, без нәрсә эшләргә тиеш дигән темага багышланган түгәрәк өстәлгә белгечләрне һәм битараф булмаган кешеләрне чакырды.

Рөстәм Шакиров
әзерләде

Түгәрәк өстәл Республика балалар йортында узды, һәм бу сөйләшүгә аерым бер төсмер өстәде – биредә битарафлар һәм катнашмый утыручылар булмады.



ӘТИ-ӘНИСЕНӘ КИРӘК БУЛМАГАННАР

(ЯТИМ БАЛАЛАР ҺӘМ АТА-АНА ТӘРБИЯСЕННӘН МӘХРҮМ КАЛГАННАР)



Валентина ДЕРБЫШЕВА, волонтёр:

– Мин 2009 елда 12 яшьлек яшүсмер кызны гаиләмә тәрбиягә алдым. Аңа кадәр мин, волонтер булып, приютларга ярдәм. Үзем күргәннәрдән чыгып, балаларны гаиләгә алырга кирәк, дигән фикергә килдем. Чөнки бәйрәмнәр, бүләкләр һәм читтән торып кына аралашу, сүз дә юк, яхшы нәрсә, әмма тагын да мөһимрәк кыйммәтләр бар. Әйтик, гаилә мөнәсәбәтләре кебек.

Әмма, соңрак ачыкланганча, бу эштә без белмәгән киртәләр шактый икән. Аерым алганда, Каринага балигъ булырга бер ай кала, безгә опекадан шалтыраттылар һәм «коммуналь» түләүләр буенча бурыч барлыгын (ике йөз мең сумнан артык) хәбәр иттеләр. Әлеге бурыч кызның үз әнисе белән икегә бүленгән. Үз әнисе озак еллар түләмәгән. Мин баланы алганда, бу хакта сүз булмады. Ә бит шул вакытта ук әйтелгән булса, без тыныч кына алты ел дәвамында әлеге акчаларны түләп барган булыр идек.

Аннан соң алга торак мәсьәләсе килеп басты (Карина үз әнисе белән яши алмый, чөнки әнисе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән). Без тиешле гариза яздык, әмма безгә муниципаль торак юк дигән җавап килде. Һәм без шуннан соң гына чиратка бастык.

Ләкин үз тәҗрибәмнән (2014 елда мин тагын ике яшьлек малайны уллыкка алдым) чыгып ясалган иң мөһим нәтиҗә һәм мин бу турыда миңа киңәш сорап мөрәҗәгать иткән һәркемгә әйтәм: бала сезне сайларга тиеш, киресенчә түгел. Ул вакытта кире кайтарулар булмаячак. Чөнки аның ресурсы үзгәрәчәк, төзәләчәк һәм ул, генетик яктан тартылыш булган тормышны түгел, башканы сайлаячак. Аның мотивациясе булачак: «Минем бит бу кешеләр белән яшисем килә, нишләп мин алар әйткәнчә эшләмәскә тиеш әле?» Мин, үз күзәтүләремә таянып, шуны әйтә алам: мондый балаларның күбесе җәмгыятьтә җайлаша һәм уңай тормыш юлын сайлый. Мәсәлән, мондый тәрбия күргәннәр арасында, үз балалары тугач, алардан баш тартучылар бик аз. Димәк, аларга уңай социаль тәҗрибә тапшырылган, һәм алар үзләре дә нормаль ата-ана булганнар.

– Һәр ташландык бала, иртәме-соңмы, әти-әнисенең күзенә карар өчен, үз гаиләсен эзләп таба...

Тагын бер мөһим момент. Һәр ташландык бала, иртәме-соңмы, әти-әнисенең күзенә карар өчен, үз гаиләсен эзләп таба. Гаиләләрне торгызу, аларны яңадан социальләштерү юнәлешендә берәр җәмагать оешмасы (дәүләт, күрәсең, бу эшне үз өстенә ала алмый) эшләсә, яхшы булыр иде. Яисә балалар кабул итә торган профессиональ гаилә институты булдырылса. Ул очракта бала башында «бала – ата-ана» (соңгылары – үз ата-анасы да, уллыкка-кызлыкка алган әти-әни дә түгел, гомумән ата-ана) мөнәсәбәтләрен төзеп һәм яңартып булыр иде, бу исә тулыканлы, төгәлләнгән шәхес структурасын булдырырга ярдәм итәчәк. Йөрәктәге зур яраны нинди дә булса башка тискәре нәрсәләр белән төзәтергә тырышулар да булмас иде. Әмма, кызганыч, бездә катлаулы тормыш хәлләренә тарыган ата-аналарны төзәтү, адаптацияләү белән беркем дә шөгыльләнми.

Диана ХӘБИБУЛЛИНА, Республика тәрбиягә алу, опека һәм попечительлек үзәге җитәкчесе:

– Минем бу урында төгәллек кертәсем килә: бу эш белән шөгыльләнәләр. Элеккеге балалар йортлары һәм гамәлдәгеләре базасында эшләп килүче озата бару хезмәтләре функциясенә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгәннәр белән эшләү дә керә. Асылда әлеге хезмәтләр аларга үз хокукларын кире кайтарырга ярдәм итә. Татарстанда агымдагы елның дүрт ае эчендә 20 бала үз гаиләсенә кайтарылды.

Ә инде бирелергә тиешле торак мәсьәләсенә килгәндә, законда юкка гына 14 яшьтән чиратка басарга мөмкин, дип язылмаган. Ягъни алар үсәләр, чират бара. Бездә ел саен 300 гә якын бала торак ала.

В.Д. – Әгәр ул 14 яшьтә чиратка басарга өлгермәсә?

Д.Х. – Димәк, кайчан өлгерә, шул вакытта баса. Әлбәттә, аңа барыбер чиратта күпмедер вакыт торырга кирәк булачак, чөнки аңардан алданрак басканнар бар бит.

В.Д. – Мин бер очракны мисалга китерә алам, уллыкка алган гаилә турында. Анда әни кеше малаена: «Безгә, мөгаен, фатир бирмәсләр. Син көн саен, сумкаңны тотып, опека бүлегенә барып утыр!» – ди. Һәм ул чыннан да бер атна шулай йөри – шунда ук торак табыла. Ә инде кеше, ярар инде, түзәбез, көтик, минем янда яшәсә, тынычрак, дисә, мәсьәлә бер ел эчендә дә хәл ителмәскә мөмкин.



Изольда ЖУЙКОВА, «Гаилә канаты астында» ТР Төбәк иҗтимагый үзәге рәисе, ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы:

– Хәзер ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән социаль кунакханәләр ачыла. Казанда алар инде бар. Әйтик, бер кыз бала әбисе тәрбиясендә яши. Балигълык яшенә җитә, әбисе белән мөнәсәбәтләрен һич кенә дә җайлый алмый. Кая барырга? Әлеге кунакханәләр нәкъ менә шундый очраклар өчен төзелә дә.

Д.Х. – Бездә балалар йортлары базаларында постинтернатлар да бар. Һәм балаларның нинди дер проблемалары килеп чыга икән, аларга монда койка-урын бүлеп бирелә, алар күпмедер вакыт шунда яши алалар.

Гомумән алганда, Татарстанда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар белән хәлләр алай ук начар түгел. Бүгенге көндә барлыгы 11804 шундый бала теркәлгән, аларның 11142се гаиләләрдә тәрбияләнә. Исәп банкында бары тик 647 генә бала турында мәгълүмат калды, алар өчен дә ата-аналар эзлибез. Ел саен без гаиләләргә меңнән артык бала тапшырабыз, шул исәптән инвалид балаларны да (узган елны шундый 14 баланы гаиләгә алдылар). Шул ук вакытта, балалар йортларының саны кыскара бара: 2014 елда алар 12 иде, бүген – 8. Аларның кайберләре озата бару хезмәтләренә әйләндерелә.



ДӘҮЛӘТКӘ КИРӘКСЕЗЛӘР

(КЫЙММӘТЛЕ ДӘВАЛАУ ТАЛӘП ИТЕЛГӘН АВЫРУЛАРГА/ОРФАН АВЫРУЛАРГА ДУЧАР БУЛГАН БАЛАЛАР)

Алсу НАДРШИНА, Республика махсуслаштырылган балалар йорты директоры:

– Балаларны дәвалау, тернәкләндерү, медицина-психологик-педагогик тәрбия белән шөгыльләнүче учреждение җитәкчесе буларак, мин игътибарыгызны тагын бер нәрсәгә җәлеп итәргә телим. Безнең барлык законнарыбызда ярашмау, эшләнеп бетелмәү очраклары бар, шуның аркасында контрольлек итүче ведомстволар белән проблемалар туып тора. Һәм аларның һәрберсе миңа нинди дә булса штраф сала.

Әйтик, Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән, медучреждениедән китерелгән бала шунда ук группага кертелә, дип билгеләнә. Роспотребнадзор исә әлеге баланы 21 көн карантин бүлегендә аерым тотарга куша.

Тагын бер мисал. Кайсыдыр анализның булмавы баланы балалар йортына урнаштыруга кертә була алмый диелгән документ бар. Ләкин бала, шуңа да карамастан, озак вакыт ҮРХндә яши, нәкъ менә аның берницди дә анализлары һәм документлары булмаганга күрә. Бу кай ягы белән начар? Менә ни белән: бала хастаханәдә булганда күнекмәләрен югалта, үсешендә тоткарлана. Ул безгә берничә айдан соң гына килеп эләгә. Медучреждениеләрнең күбесендә, мәсәлән, дефектологлар, башка төр тар белгечләр юк. Балалар йортында исә тиешле белем һәм күнекмәләре булган барлык белгечләр дә эшли, бездә комплекслы медицина-психологик-педагогик тернәкләндерү уздырыла. Ә бу вакыт эчендә бала үсә алыр иде. Әлеге барлык анализларны без үзебез дә эшләтә алабыз бит. Баланың документлары белән дә безнең социаль хезмәткәрләребез шөгыльләнә ала, алар да эшли бездә. Кайчак балалар безгә туу турындагы таныклыклары һәм полислары булмаган килеш тә эләгәләр – без аларны үзебез ясатабыз. Болар барысы да тәрбиягә алу процессын да шактый кыенлаштыра, чөнки, гафу итегез, үсешендә артта калган баланы алырга атлыгып тормыйлар.

Шуңа күрә без, беренчедән, балаларның клиникада булу вакытларын кыскарту, аларны тизрәк безгә китертү ягында. Икенчедән, безнең эшчәнлекне тулысынча регламентлый, законнарның төрлечә укылышын юкка чыгара һәм ведомствоара эш итүләрне җайлый торган бердәм кагыйдәләр җыелмасын булдырырга кирәк.

Д.Х. – Бу балалар чыннан да хастаханәләрдә ярты ел да, бер ел да, ел ярым да яши алалар. Җитмәсә, әлеге вакыт эчендә бер генә документ та эшләнмәскә, инвалидлык та бирелмәскә мөмкин. Буш урыннары җитәрлек булган ике зур Балалар йорты эшләгәндә ул балаларны хастаханә бүлекләрендә яшәтүнең ни мәгънәсе бар соң?

И.Ж. – Өстәвенә, хастаханәләрнең үзләре бу проблемалардан гарык булганны да исәпкә алсак. Балалар арта бара, клиника персоналына төрлечә тырышырга, иза чигәргә туры килә. «Гаврош» балалар приюты ремонтта чагында бер хастаханәнең ташлап калдырылган балалар бүлегеннән шалтыраттылар: балалар инде шулкадәр күп, аларга нинди кием кидерергә, нәрсә эшләргә белмиләр. Һәм без аларга памперслар, башка кирәк-яраклар җыйдык. Ягъни анда да үзләрендә озаграк тоткарлау теләгеннән генә тотмыйлар балаларны.

Ольга ТИМУЦА, Ретт синдромы белән авыручыларга ярдәм итү ассоциациясе идарәсе рәисе, ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы:

– Татарстанда якынча 500 кеше сирәк авыру белән интегә, һәм аларның яртысы – балалар. Бу санга әле бары тик реестрга кертелгән авырулар белән авыручылар, димәк, дәвалау белән тәэмин ителүчеләр генә керә. Шул ук вакытта Россиядә әлеге реестрга кертелмәгән 230 авыру теркәлгән исемлек кабул ителде.

Шуларның берсе-Ретт синдромы, минем олы кызым да шуның белән авырый. Мин һәрвакыт безгә чагыштырмача җайлы туры килде, дим, чөнки без Татарстанда яшибез. Әлеге чирнең беренче билгеләре күренә башлауга, дәваханәдән башлап, барлык хезмәтләр дә бик тиз эшләделәр. Безне генетика үзәгенә җибәрделәр, аннан – Мәскәүгә, анда диагноз куелгач, Татарстанга кайттык – инде ул вакытта эшли торган «Кояшлы» тернәкләндерү үзәгенә.

Ләкин, гомумән алганда, Россиядәге вазгыять башкачарак, һәм ул 20 ел эчендә үзгәрмәде диярлек. Диагноз соң куела, бу исә дәвалану һәм тернәкләнүне соңарып узу дигән сүз, мондый очракта бала инде беркайчан да йөреп китә алмаска мөмкин. Шул ук вакытта табиблар бик еш кына: «Сез берни дә эшли алмаячаксыз, дәвалау юк, бу бала белән шөгыльләнергә кирәкми, сәламәт бала табыгыз», – диләр. Әлеге этапта мондый балалардан баш тартуны кисәтү өстендә эшләү мөһим, чөнки бу сүзләрдән соң, балаларның күбесе дәүләт учреждениеләрендә кала. Икенче төрле әйтсәк, күтәрелгән темабыздагыча кирәксезгә әйләнә.

Сирәк авыруларга дучар булган балаларга кагылышлы тагын бер проблема – аларны социаль тормышка, мәгариф системасына җәлеп итү. Минем кызым бер генә көн дә мәктәптә укымады, һәм мин инклюзия проблемалары белән никадәр генә шөгыльләнсәм дә, әлегә мондый категория балалар өчен нинди дә шатлыклы киләчәкне күрә алмыйм.

Янә бер проблема аларны олы тормышка кертеп җибәрүгә карый. Чөнки балигъ булганчыга кадәр алар белән тернәкләндерү үзәкләре шөгыльләнә, алар өчен даими акцияләр уздырыла, бездә теге яисә бу яктан балаларны үзләренә җәлеп итә торган төрле коммерциячел булмаган ассоциацияләр һәм фондлар бар. Ә менә олылар белән бөтенләй башка хәл.

Һәм, әлбәттә, кыйммәтле дару препаратлары белән тәэмин итү мәсьәләсе. Татарстанда мукополисахаридоз белән авыручы бер бала, хәтерем ялгышмаса, елына 40 миллион сумлык дәвалау ала. Ләкин безнең икенче балабызда да шул ук авыру, һәм ул дәва ала алмый. Әлбәттә, мондый мәсьәләләрне хәл итү җәмәгатьчелекне һәм ММЧларын кушуны таләп итә, чөнки, ни кызганыч, башкача эш бармый. Җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итү дә һәрвакытта да ярдәм итми.

Әлеге проблеманы чишү өчен нинди дә конкрет ысуллар булырга тиеш. Барыбызга да аңлашыла ки, федерация субъектлары берүзләре генә моны хәл итә алмый, бу алар дәрәҗәсе түгел. Татарстан кебек имин төбәк тә, елына 40 миллион сумлык дәвалау таләп ителгән бала пәйда булуга, аптырашта кала. Шуңа күрә без, шул исәптән Иҗтимагый палата исеменнән дә закон чыгаручыларга җаваплылыкны федераль үзәккә күчерү тәкъдиме белән чыгабыз.

МӘКТӘПКӘ КИРӘКСЕЗЛӘР

(ИНКЛЮЗИВ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ)

Гөлназ САБИРОВА, аутист бала әнисе:

– Дүрт ел элек минем улыма «балалар атипик аутизмы» диагнозын куйдылар. Хәтерлим, тулы бер консилиум җыелган комиссиядә безгә болай диделәр: «Сезнең язмышыгызга шулай язылган, түзегез. Бүген аутизм, аннан соң шизофрения һәм башкалар». Ә аннан соң бик дәрәҗәле табиб үзем генә булганда бөтенләй куркыныч сүзләр җиткерде: «Балагыз 13 яшендә төнлә булмәгезгә кереп, сезне балта белән чабарга мөмкин. Ишекләрегезне бикләп йоклагыз. Һәм тагын ирегезнең сездән китәчәгенә әзер булыгыз». Миңа калса, мондый мөнәсәбәт балалардан баш тартуга китерә. Мондый вазгыятьтә ата-анага психологик тернәкләндерү таләп ителә, ә монда аларны куркыталар.

8 яшебездә без яшәү урыны буенча гадәти мәктәпкә бардык. Мәктәп директоры нәкъ менә хәзер мәктәпләргә инклюзив белем бирү кертелә дип ышандырды. Килегез, янәсе, проблемалар булмаячак. Безгә анда артык игътибар бирмәделәр, документлар һәм белешмәләр таләп итмәделәр. Без өйдә укучы идек, ләкин без өйдә утырмадык – мин баланы мәктәпкә йөрттем. Педагогның буш дәресе булганда, без баладан артык игътибарлылык таләп ителмәгән дәресләр белән шөгыльләндек – «Әйләнә-тирә дөнья», хезмәт һ.б. лар. Бала өчен шулай итеп ниндидер аралашу, социальләшү барлыкка килде, бала үсте, педагогка да уңайлы иде. Башка балалар аны кыерсытмадылар. Һәм, гомумән алганда, безгә барысы да ошый иде, без ике ел укыдык.

Аннан соң безгә башка гадәти мәктәпкә барырга туры килде. Дөресен генә әйткәндә, кеше аркылы – башкача без коррекцион мәктәпкә эләгер идек. Хәзер өченче сыйныфта укыйбыз, бала ниндидер уңышларга ирешә – ул укый, яза, төрле фигураларны бик яхшы кисә һәм буйый белә, йөзә (без тагын өйдә укырга тиеш булсак та, мәктәптә шөгыльләнәбез). Һәм мин бер нәрсәдән куркам: башлангыч мәктәпне тәмамлагач нишләрбез, химия һәм тарих кебек махсус предметлар укытыла башлагач, ул бу программаны үзләштерә алмаячак. Һәм ул вакытта безнең мәктәптән китүебезне сорарлармы?..

Светлана ЛЮБИНА, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм йомгаклау аттестациясе бүлегенең әйдәп баручы консультанты:

– Мәктәптән китүегезне сорый алмаячаклар. Коррекцион мәктәпкә бары тик билгеле бер вакытка кадәр генә күчереп була. Предметларны үзләштерү белән чыннан да кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин, анысы – икенче мәсьәлә.

Г.С. – Әмма гомумән мин инвалид баланы мәктәпкә урнаштыру мәсьәләсен билгеле бер регламентка ярашлы рәвештә эшли торган комиссия хәл итәргә тиеш, дип уйлыйм. Бала куркыныч тудырырга мөмкин, гаиләдә ул үзен бер төрле тота, мәктәптә – башкача. Минем үземә баламның сыйныфташларының әти-әниләре аның тәртибенә карата зарлансалар, һәм бигрәк тә кыерсыта башласалар, уңайсыз булыр иде. Бу очракта мин үземне якларга тиеш булам, ә моны эшләр өчен минем кулымда ниндидер документ булырга тиеш. Анда минем баламның ниндидер тестлар һ.б. лар аша үтеп, шулар нигезендә мәктәпкә кергәнлеге күрсәтелергә тиеш.

С.Л. – Инклюзив белем бирү – бүген һәркем ишеткән, бик еш яңгырый торган тема. Һәм аңа мөнәсәбәт шактый төрле.

Статистикага караганда, бездә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балаларның яртысы гомумбелем бирү мәктәпләрендә укый, икенче яртысы – элек без атап йөрткәнчә, махсус коррекцион учреждениеләрдә (хәзер – «СМЧ балалар мәктәпләре»). Шуңа күрә инвалид балалар бездә социумнан читләштерелгән дип әйтеп булмый.

Аңлашыла ки, сүз бүгенге көнгә кадәр белем бирү кырына җәлеп ителмәгән яисә физик мөмкинлекләре үзенчәлекләре аркасында белем бирү оешмаларына йөри алмаган авыр чирләргә дучар булган балалар турында бара. Республикада әлеге каршылыкларны юкка чыгару буенча билгеле бер эш алып барыла. Бу «Уңайлы мохит» программасын кертү дә (программа буенча республиканың 299 мәктәбендә уңайлылыклар булдырылган), педагогларны укыту да, әлеге балалар барырга тиешле мәктәпләрдә аларның укуы өчен шартлар тудыру да, әти-әниләр берләшмәсе белән эшләү дә.

Моннан тыш, бездә психологик-медицина-педагогик комиссияләр (ПМПК) шактый җитди эш алып бара. Әлбәттә, баланың белем алу траекториясен иң беренче чиратта әти-әниләр билгели. Моның белән бергә, әлеге балалар өчен ПМПК үтү дә мәҗбүри, анда медицина хезмәткәрләре, психологлар, дефектологлар ата-анага баланың үзенчәлеге, аны укытканда нинди проблемалар туарга мөмкинлеге һәм бала өчен кайсы программа иң кулае булачагы турында аңлаталар. Әмма ата-аналар еш кына бу мәгълүматны дөрес кабул итеп бетерми. Алар, без закон буенча махсуслаштырылган коррекцион мәктәпкә түгел, гомумбелем бирү оешмасына йөри алабыз, дип белдерәләр.

Шул ук вакытта авыр чиргә дучар булган бала, әйтик, гадәти гомумбелем бирү мәктәбенә укырга керә икән, анда логопед, дефектолог, психолог кебек тар белгечләр эшләргә тиеш, чөнки алардан башка әлеге баланың белем алу юнәлешен дөрес итеп алып бару мөмкин түгел. Ләкин мондый ставкалар бүген штатта бөтенләй каралмаган – алар бары тик коррекцион мәктәпләрдә генә бар.

Татарстанда барлык коррекцион мәктәпләр дә сакланып калды. Бүген анда үсешләрендә авыр тайпылышлар булган балалар өчен барлык шартлар да тудырылган. Барлык педагоглар да тиешле методикалар буенча эшлиләр. Моннан тыш, узган елдан башлап, без әлеге мәктәпләрне СМЧ балалар укыган гомумбелем бирү мәктәпләре укытучылары өчен стажировка үтү мәйданчыгы булаларак та билгеләдек. Һәм тагын шуңа басым ясыйсым килә: хәзер гомумбелем бирү мәктәпләрендә укучы СМЧ балалар сәламәт балаларга исәп тоткан уку стандартлары буенча бирелә торган белемне үзләштерәләр. Менә шуңа күрә дә белем алуда кайбер проблемалар туып тора. Ләкин 2016 елның 1 сентябреннән беренче сыйныфтан СМЧ балалар өчен федераль уку стандарты кертелә башлаячак. Моннан тыш, ниһаять акыл ягыннан калышкан балалар өчен стандарт та барлыкка килде.

Люция САМАТОВА, Казанда СМЧ балалар өчен 4нче интернат-мәктәп директоры:

– Безнең интернат-мәктәптә ДЦП белән авыручы балалар укый – Татарстанның 16 районыннан килгән 173 кеше.

Кызганыч, авыр чирләргә дучар булган инвалид балалар саны арта бара. Әйтик, узган елны без беренче сыйныфка 14 бала кабул иттек, аларның 9ы бөтенләй йөрми. Әлбәттә, мондый бала белән дәресләрдә әнисе утыра. Һәм менә күз алдына китерегез: сыйныф бүлмәсендә 14 бала һәм шунда ук 9 әни утыра. Ә устав буенча безнең сыйныфларда 10–12 баладан да артык булмаска тиеш. Ләкин әти-әниләр балаларын мәктәпкә алуыбызны үтенеп-үтенеп сорыйлар, һәм, билгеле инде, аларга ярдәм итәсе килә. Моннан тыш, устав буенча безнең мәктәп мөстәкыйль хәрәкәтләнә алмаган баланы кабул итәргә тиеш түгел. Ләкин мин үзем һәр очракта комиссиягә, җаваплылыкны үз өстемә алам дип, гариза язам.

Шулай итеп, безнең мәктәптә һәрвакыт 40ка якын әни була, алар өчен берниндиишартлар да юк. Мәсәлән, бездә ике корпуска – бергә тоташтырылган уку һәм йокы корпусларына – бер лифт. Һәм мөстәкыйль йөри алмаган баланың әнисе коляскага утырган баланы этажлар буйлап, гафу итегез, сөйрәп йөрергә мәҗбүр була. Ә бит кайбер балалар инде зур, буйга әниләреннән дә озынрак. Укытучыларга да җиңел түгел, аларның һәр дәресе – ачык дәрес. Һәм бу һәр сыйныфта шулай. Ә безнең мәктәптә 100 ата-ана булса нишләргә?

– Әгәр ата-аналарны әзерлибез, аларга балаларының үзенчәлекле булуын, балага үсеш программасын сайлап, аны социальләштереп һәм үз-үзенә хезмәт күрсәтергә өйрәтеп булуын аңлатабыз икән, җәмгыять мондый балаларны кабул итәчәк.

В.Д. – Минем комиссияләрдә дежур мөнәсәбәткә юлыккан ата-аналар турында берничә сүз әйтәсем килә. Алар үз балаларыннан баш тартмасын өчен, чыннан да эшләргә кирәк – һәркайсы белән. Менә элегрәк «даун» балалар турында, алар бөтенләй бала түгел, интернатка тапшырырга кирәк, дип сөйлиләр иде. Ә инде без мондый балалары туган ата-аналар белән эшли башлагач, баш тартулар азайды.

Әгәр ата-аналарны әзерлибез, аларга балаларының үзенчәлекле булуын, балага үсеш программасын сайлап, аны социальләштереп һәм үз-үзенә хезмәт күрсәтергә өйрәтеп булуын аңлатабыз икән, җәмгыять мондый балаларны кабул итәчәк. Һәм балалары сәламәт ата-аналар да, үз балам янында мондый баланы күрергә теләмим, дип йөз чөермәячәк. Җәмгыять мондый балаларның да булуын, үзенең идеаль кешеләрдән генә тормавын белергә һәм аңларга тиеш, дип саныйм мин. Шул исәптән – бездә чит һәм кирәксез балаларның булмавын да.

Балалар кирәкле һәм бәхетле булсын өчен, түбәндәгеләр кирәк:

– Бала сезне сайларга тиеш, киресенчә түгел. Ул вакытта кире кайтарулар булмаячак.

– Гаиләдә рухи һәм әхлакый традицияләрне ныгытырга. Мондый гаиләдә, ничек кенә авыр булмасын, беркайчан да баланы ташламаячаклар.

– Гаиләгә бала кабул итүче әти-әниләрдәге җаваплылык. Аларны өйрәтергә кирәк, һәм моның белән бездә 2012 елдан рәсми эшли торган тәрбиягә бала алучы ата-аналар мәктәбе шөгыльләнә.

– Балаларны клиникаларда озак тоткарламаска, аларны тизрәк Балалар йортына күчерергә. Анда баланың үсеше өчен барлык шартлар да тудырылган.

– Кыйммәтле дәвалау таләп ителгән балалар өчен финанс җаваплылыгын федераль дәрәҗәгә күчерергә.

– Баласына куелган авыр диагноз турында ишеткән ата-аналарны психологик тернәкләндерү өстендә эшләргә.

– Белем бирү юнәлешен дөрес итеп билгеләргә.

– Интернат-мәктәпләргә проблемаларын хәл итәргә булышырга, аерым алганда, сыйныфлардагы балалар санының күп булуын.

PRESSA.RU

«МИН – КОРБАН, ДИП, БИРЕШҮ – ИҢ ҖИҢЕЛ ЮЛ»

Ник Вуйчич – иң соклангыч затларның тормышта ни өчен топ-модельләргә бөтенләй охшамаган булуы хакында.

Визит карточкасы

Ник Вуйчич дөньяга аяксыз-кулсыз булып туа. Мөмкинлекләре чикле булуга карамастан, Австралиядәге гадәти гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы беренче бала була. Ике югары белеме бар. Өйләнгән, ике ул әтисе. Вуйчичның какшамас ихтыяр көче, тормышны яратуы һәм юмор хисе җир йөзендәге миллионлаган кешене рухландыра. Бүген аның аудиториясен 10 млн нан артык кеше тәшкил итә, еллык лекцияләр графигы исә 250дән артык чыгышны үз эченә ала.

Артка борылып карыйм да, балачак елларымның бәхетле булуын аңлыйм. Гаиләбезгә һәртөрле кыенлыклар кичерергә туры килүенә карамастан, тормышта шатлык-сөенеч тә, кызыклы мизгелләр дә күп булды. Нәкъ башка олы абыйлар кебек үк, мин дә сеңлем белән энекәшемне җәфалый идем. Бу яктан минем балачагым башкаларныкыннан берни белән дә аерылып тормады. Июнь аенда әтиемнең «Воспитание совершенно несовершенного ребенка» дигән китабы дөнья күрәчәк – ул, ниһаять, ни генә булмасын, үзенең барыбер бәхетле әти булуы турында башкаларга да сөйләр өчен өлгереп җитте.

Мөмкинлекләре чикле булган балаларның гадәти белем бирү мәктәпләрендә укуын табигый хәл дип саныйм. Бу барлык балалар өчен дә менә дигән тәрбия мәктәбе – һәр ике як монда күп нәрсәгә өйрәнә ала. «Үзенчәлекле» балаларга мондый аралашу үз-үзләренә ышаныч тәрбияләү һәм фикерләү рәвешен үсешкә, тормыштагы кыенлыкларны җиңә белергә юнәлдерү өчен стимул бирә. Гадәти балаларга исә үзләрендә кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү өчен әйбәт күнекмә. Мин башкалар белән бергә гомуми мәктәптә укыдым. Каныккан чаклары да булды, мыскыллаганнары да. Әйе, мин әзәрлекләүчеләрем булдыра алганны эшли алмый идем – кулларым да юк, аякларым да. Мин алар өчен кулга җиңел генә төшереп була торган корбан булдым. Әмма көннәрдән бер көнне һәммәбез өчен дә өмет чаткысы балкыды – мин үземне көчсез дип саный башлаудан туктадым, һәм классташларым моны күреп-сизеп алды. Югары классларда инде мин сыйныфыбызның президенты идем – моны классташлар үзләре хәл итте.

Сабыйлары язмышы өчен көрәшүдән туктаган әниләрнең өметсезлеге җимергеч көч булып әверелә. Бу дөньяда явызлык болай да чиктән ашкан. Андый әниләрнең балалары еш кына үзләренең мөһим зат булуларын, тормыштагы миссиясен аңламый, үз алларына максатлар куярга өйрәнеп үсми. Алга барыр өчен каян көч алсын алар? Мин – корбан, дип, бирешү – иң җиңел юл. Күз алдында тормаганга, үзең күрмәгәнгә генә, тормышта синең өчен берни дә мөмкинлекләр ачылмаячак, дип уйлау – зур хата. Минем андый хатын-кызларга киңәшем бар – ышанырга өйрәнегез. Үзегезгә, балагызга, Аллаһка. Сабыегызда Аллаһтан иңгән мәхәббәт орлыгы бар, менә шуны тәрбияли, үстерә башлагыз. Бирешкән кешеләрне күрсәгез, аларны да шуңа рухландырыгыз.

Өлкәнәя төшкәч тә, уңышка ирешүемә карамастан, тормышымда күңелсезлекләр булмый тормады. Җаваплылык шулкадәр баса башлады ки, көннәрдән бер көнне мин тәмам төшенкелеккә бирелдем. Кешеләр каршында чыгыш ясаулар да Аллаһ тарафыннан бирелгән миссия һәм яшәү мәгънәсе түгел, ә бурыч булып кына тоела башлады. Ә бит кешеләргә ярдәм итү миңа һәрчак сөенеч китерә иде. Бу халәткә яңадан кайту өчен ике ай вакытым китте, әмма сәламәтләнү процессының үз өстенлекләре дә булды. Мин, түбәнгә тәгәрәвемне анык аңлаган хәлдә, үз алдыма куйган сорауга җавап таба алмый иза чиктем. Ни өчен без үз тормышыбыз турында шундый мизгелләрдә генә уйлый башлыйбыз икән – теләгән нәтиҗәләргә ирешә алмаганда? Уңышсызлыклар да – тормыш тарафыннан бирелгән бик әһәмиятле дәресләр, без ул дәресләрне үзләштерергә тиеш. Ә боегып, төшенкелеккә бирелеп яшәү – чын гариплек менә шул инде. Җан гариплеге.

Өмет беркайчан да үлми, мин моны чын күңелдән ышанып әйтәм. Ул бөтен киртәләрне үтеп чыгарга булыша, без күз алдына да китереп карамаган яңа мөмкинлекләр ача. Үҗәтлек һәрвакыт үз җимешләрен китерә. Бирешмичә, үз дигәнебезне иткәндә, тырышканда, без юлыбызга ярдәм күрсәтә алырдай кешеләрне китереп чыгара торган импульс җибәрәбез. Кылган гамәл беркайчан да җавапсыз калмый! Хыялыгыздан баш тартырга ниятләсәгез дә, түземлекне җыеп, тагын бер генә көн, бер генә атна, бер генә ел тырышып карагыз... Ышаныгыз, алга таба сезнең белән булачак хәлләргә үзегез үк гаҗәпләнәчәксез.

Мин үзем белгән иң соклангыч затларның тормышта топ-модельләргә бөтенләй охшамаган булуын ассызыкларга яратам. Аларның матурлыгы, якыннан белә башлагач, тагын да ачыларак төшә. Ул матурлык күзне камаштырырдай була кайчак. Без бер үк вакытта камил дә, камил түгел дә – әйе, без һәрнәрсәдән мәгънә таба алыр, матурлык күрер өчен шулай яратылган. Элизабет Кюблер-Росс исемле психиатр болай ди: кешеләр витражларга охшаган, алар кояш чыккач ялтырыйлар һәм балкыйлар, әмма караңгы төшкәч, чын матурлыклары бары эчке нур яктыртса гына күренә ала. «Әнә шул эчке нурны саклагыз, сез чыннан да матур һәм кабатланмас», – дип өстәр идем үземнән.

PRESSA.RU

#БЕЗБАРЫБЫЗДАБАЛАЧАКТАН

1 июньдә «Татарстан», традиция буенча, аклы-каралы балачак белән төсле балачак арасындагы аермаларны эзләде. Һәм тагын бер кат инанды: фотографияләрдә ул нинди генә төстә булса да, сурәтләрнең каһарманнары өчен балачак алыштыргысыз сөенеч һәм бәхет чыганагы.

Татарстанлыларның бәхетле балачагы менә шушы өч сүзгә сыеп бетә.



Рабит Батулла, язучы: «Балык тоту, сәпиттә йөрү, кәлҗемә җыю».

Сөембикә Җиһаншина, ТР Милли китапханә директоры: «Бер сүз белән генә әйтә алам – иң бәхетле чак».

Айдар Фәйзрахманов, ТР Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле җитәкчесе: «Уфалла арбасы, чалгы тотып печән чабу, мал-туар асрау».

Айрат Хәйруллин, Әлмәт муниципаль районы башлыгы: «Күк йөзе, якты көн, могҗиза».

Фоат Әбүбәкеров, Г.Камал театрының камера оркестры җитәкчесе: «Наманганның кызу кояшы, яланаяк кайнар комнан су коеныргa йөгерү, көн буе шаулап торган базар».

Алсу Тимергалина, рәссам: «Авылдагы зур бакча, фантастик әсәрләр, сәнгать мәктәбемдәге искиткеч педагогым Рәшит Төхфәтуллин».



Рамилә Габбасова, 8 яшь:
«Әти-әни, су буе, курчагым».

Ралинә Габбасова, 8 яшь:
«Уенчыклар, әкият китабы, балалар бакчасы».

Илназ Бәдертдинов, 3 яшь:
«Тиен, зур йөкләр ташучы машина, комлык».

Зөлфия Фәезова, 3 яшь:
«Әти-әни, тәмле ризыклар, җәй».

Суфия Дмитриева, 4 яшь:
«Сине бөтенесе дә ярата, бөтен нәрсә рөхсәт ителә, синең белән дус булырга телиләр».

Ильяс Сираев, 5 яшь:
«Кәнфит-уенчыклар, әбием белән апаем (энекәше)», садигым (садигы - «Бәхетле балачак»).

1 июнь – Балаларны яклау көне уңаеннан «Татарстан» журналы Лаештагы балалар йортына юл тотты. Алъяпкычларын киеп алып, балаларны җәлеп итеп, бирерә чып-чын кулинар шоу оештырдылар – ананас белән шашлык һәм имбирьле печенье әзерләделәр. Балаларга үз куллары белән хәстәрләгән ризыкны ашау аеручa күңелле булды. Алар сыйланган арада десертка туңдырма да өлгерде – яшел туңдырма! «Ник ул яшел?» – дип шау-гөр килеште яшь кулинарлар. «Чөнки, ул бөтнектән!» – дип елмаештык без. **Шулай итеп, балалар өчен генә түгел, үзебез өчен дә бәйрәм оештырдык!**

«ТУКАЙ АБЫЙСЫН БЕЛӘ...»

1 июнь – Балаларны яклау көне булгач, бу ай, иң беренче чиратта, сабыйлар, гаилә белән бәйләп күзаллана. Июньнең китап киштәсен әзерләгәндә дә, шуны исәптә тотып, яшь гаиләләргә мөрәҗәгать итәргә булдык. Нинди алар – заман гаиләләре: нинди китаплар укыйлар, балаларын нинди рухта тәрбиялиләр.

1. Балачакның иң шәп китаплары?
2. Үз балагызга нинди китаплар укыйсыз?
3. Әти-әниләргә балаларына нинди китаплар укырга киңәш итәр идегез?
4. Сезнеңчә, өлкәннәрнең балалар тормышындагы проблемаларга карашын үзгәртә алырдай китаплар ниндиләр?
5. Иң соңгы укыган китабыгыз?
6. Кайсы формат якынрак – кәгазь китапмы, электрон вариантмы, аудиокитапмы?
7. Китап киштәсен еш тулыландырасызмы? Иң соңгы сатып алган китабыгыз нинди?

– ФАНТАЗЁР БУЛЫР ӨЧЕН ӘКИЯТ УКЫРГА КИРӘК

Язып алды:
Луиза Янсуар

**Илнур Закиров, Г.Камал театры артисты,
Динә Закирова, Г.Камал театры оркестры музыканты**

1. Динә:
– Минем яраткан китапларым – «Көнгә күренмәс Көмеш-Сылу» һәм «Чегән әкиятләре». Әле дә шул китапларны күргәч, берәр әкиятен булса да кабат укымый калмыйм. Илнур да бәләкәй чагында әкиятләргә битараф булмаган, хәзер дә әкиятләрне үз итә.
Илнур:
– Николай Островскийның «Как закалялась сталь» китабы. Әтиемнең китап киштәсендә аның татарчага тәрҗемә ителгән варианты тора иде. Минә кечкенә чакта шуннан да шәп, мавыктыргыч китап юк иде минем өчен.

2. Динә:
– Кызыбыз Зәлиянең яраткан китабы – «Шүрәле» әкияте, аңа әле ике яшь тә юк, әмма «Шүрәле»не Тукай абыйсы язганын белә, һәм аны үзенчә «Туку» дип атый.
Илнур:
– Тукайның «Шүрәле»сен, балалар өчен язган башка әсәрләрен күпме укысаң да туймый. Без аны матур итеп, театральләштереп укыйбыз инде.

3. Илнур:
– Әбиемнең әйткән сүзләрен һич онытасым юк: «Балага кечкенә чагында әкиятләрне күп укысаң, фантазёр булып үсә!» – дип кабатларга ярата иде ул. Менә үзем фантазёр – артист булып йөрим инде хәзер... «Көнгә күренмәс Көмеш-Сылу» әкият китабын һичшиксез укырга кирәк!
Динә:
– Үзебезнең татар, рус һәм дөнья классикасын укырга һәм белергә кирәк. Үсә төшкәч, балалар аны үзләре дә укый алалар бит. Классика шуңа да классика инде – ул кешелекнең бөтен тарихын туплаган, классик әсәрләрне укып, кеше психологиясен дә өйрәнеп була.
Илнур:
– Гомумән, исеме яңгыраган, кеше теленнән төшми торган, вакыйга буларак кабул ителгән китаплар белән танышып барырга тырышабыз. Дөньядан артта калып булмый бит.

4. Динә:
– Бала тугач, баланы дөрес тәрбияләү турындагы китапларны күп укыдык. Әле кызыбыз туганчы ук укый идек аларны. Үзең бала вакытта хәтердә калган кичерешләргә генә таянып бала тәрбияләп булмый.

5. Динә:
– Илнур белән «Зөләйха күзләрен ача» китабын ярыша-ярыша укый башладык.
Илнур:
– Захар Прилепинның «Черная обезьяна», «Обитель» әсәрләре.

6. Динә:
– Кәгазь китап!
Илнур:
– Электрон вариантны бик озак укып булмый, күзне авырттыра һәм боза. Хәер, Иван Вырыпаевны мин нәкъ менә электрон вариантта укыйм, аның язганнары бик ошый.

7. Динә:
– Китапларны еш сатып алырга тырышабыз, хәзер киштәбез бигрәк тә балалар китаплары белән тулып бара. Соңгы алган китап – Фаил Шәфигуллинның биографиясе, аның турындагы истәлекләр, әлегәчә бастырылмаган хатлары, багышлаулар тупланган җыентык.

–ДИНИ ҺӘМ МИЛЛИ ТӘРБИЯ – БЕРЕНЧЕ УРЫНДА

Рушан Хәялиев, юрист,
Раилә Хәялиева, журналист

1. Раилә:
– Без кечкенә чакта Рушан белән икебез дә озак кына зәңгәр тышлы калын «Татар халык әкиятләре» китабы белән «мавыкканбыз». Фатих Кәримнең «Гармунчы аю белән җырчы маймылы», Габдулла Тукайның «Шүрәлесе», «Су анасы», Һади Такташның «Тәүфыйклы песие» – икебез дә укып үскәнбез аларны. Зуррак үскәч, бик кызыксынып татарча фантастик әсәрләр җыелмасын – «Мәҗаралар дөньясында» китабын уку хәтердә.

2. Раилә:
– Зөбәрҗәт белән Тукайның «Кәҗә белән сарык» әсәрен, 2011 елда «Татарстан китап нәшрияте»ндә басылып чыккан «Балачак энциклопедиясен», рус халык әкиятләрен, Астрид Линдгренның Лотта исемле кыз турындагы әсәрләрен бик яратып укыйбыз, сөйлибез һәм карыйбыз.
Рушан:
– Әйе, балалар өчен нәшер ителгән китаплар, беренче чиратта, карарга кызык булырга тиеш, дигән нәтиҗә ясадык үз тәҗрибәбездә.

3. Рушан:
– Дини һәм милли тәрбия бирер өчен файдалы булырдай классик әсәрләрне.
Раилә:
– Болар – Габдулла Тукай, Абдулла Алиш һәм татар язучыларының башка әдәби әкиятләре, хәзер балалар өчен дини әдәбият та күп («Пәйгамбәрләр кыйссалары», «Звёздочки в темноте» һ.б.). Аларның яхшы ягы шунда: бу китаплар әйләнә-тирәне, бала белергә тиешле нәрсәләрне гап-гади, җиңел генә итеп аңлатырга булыша.

4. Раилә, Рушан:
– Без югарыда санап чыккан китаплар шундыйлар. Балага кечкенәдән дөньяның камиллеген һәм матурлыгын, яшәү мәгънәсен аңлату, иң беренче чиратта, дини һәм милли тәрбия аша килә, дип уйлыйбыз.

5. Рушан:
– Аркадий Гайдарның «Тимур и его команда» әсәре. Мин аны кечкенә вакытта укымаган идем, соң булса да, уң булды менә.

Раилә:
– Гөлсинә Галимуллинаның «Алтын ачкыч» әсәре.

6. Рушан:
– Гомернең шактый өлеше машинада узу сәбәпле, аудиоформатны бик уңайлы, дип табам. Татар әдәбияты күбрәк әлеге заманча форматта булсын иде!
Раилә:
– Ә мин, киресенчә, китапны кыштырдатып, исен, бар рәхәтен тоеп укырга яратам.

7. Рушан:
– Тулыландыру тизлеге уку тизлегеннән зуррак, кызыгабыз да алабыз. Китап кибетләре нишләп шулкадәр үзенә тартадыр безне?!
Раилә:
– Интернеттан заказ бирүне дә хуп күрәбез. Соңгылары – Гөлсинә Галимуллинаның берничә китабы.





– МАШИНАДА, ВЕЛОСИПЕДТА – ТЫҢЛЫЙБЫЗ, ӨЙДӘ – УКЫЙБЫЗ

Тәбрис Яруллин, Бөтендөнья Татар яшьләре форумы рәисе, Аида Сәйдәш, фотограф

1. Тәбрис:
– Минем өчен – Толкиен. Аның «Властелин колец» китабын мәктәп елларында өч мәртәбә укып чыктым.
Аида:
– Маргарет Митчелл. «Унесённые ветром».

2. Тәбрис:
– Ризаэтдинга балалар китапларын сайлап-сайлап укыйбыз, татар китаплары белән беррәттән, чит ил авторларыныкын да.
Аида:
– Төрле телләрдән татар теленә тәрҗемә итеп укыйбыз. Татар, рус халык әкиятләре аңа кечкенәдән таныш. Иң еш укый торган китапларның берсе – Эва Эриксон һәм Барбру Линдгренның Макс мажаралары. Берничә китапчыкка тупланган алар. Китапчыклардагы каһарманның исеме, аңлашылганча, Макс, әмма без улыбызга Ризаэтдин дип укыйбыз һәм сөйлибез. Шуңа күрә, Ризаэтдин бик тырышып Макс эшләгән гамәлләрне башкарырга омтыла. «Юлбасма» нәшриятын, «Үчтеки» проектын бик яратабыз.

3. Тәбрис:
– Аида әйткәнчә, Ризаэтдинга 3 яшь тулганчы, Эва Эриксон һәм Барбру Линдгренны укыдык, бик мавыктыргыч, башкаларга да киңәш итәм. Балага үз-үзен тотарга өйрәнер өчен дә файдалы.
Аида:
– Хәзерге вакытта бик күп танылган психологлар, педагоглар үз тәҗрибәсе белән уртаклаша, кирәкле киңәшләрен бирә. Минем иң яраткан авторларым: Людмила Петрановская, Лариса Суркова, Шалва Амонашвили, Юлия Гиппенрейтер.

4. Аида:
– Шалма Амонашвили. «Искусство семейного воспитания».
Тәбрис:
– «Хроники Нарнии», анда бик мавыктыргыч әкияти сюжет булса да, балалар өлкәннәр дөньясы һәм зур проблемалар белән бәрелешә.

5. Тәбрис:
– Джек Лондонның «Мартин Иден» әсәре.
Аида:
– Абдулла Алиш әкиятләре.

6. Тәбрис:
– Велосипедта барганда, аудиокитаплар тыңлап бару – әйтеп бетергесез рәхәт процесс, ә өйдә укысаң, әлбәттә, кәгазь вариант.
Аида:
– Тәбрис белән килешәм, минем очракта да машинада барганда – аудиоформат, өйдә – кәгазь китап.

7. Аида:
– Яңа китапларны ай саен сатып алам. Кайбер вакытта ешрак та була. Соңгылары – Kumon дәфтәрләре һәм «Мәгариф» нәшриятында басылган китаплар.
Тәбрис:
– Тулыландырабыз, әлбәттә, соңгы арада күпләп алып кайткан китаплар шәһәр үсеше, урбанистика белән бәйле иде. Алар Казанда узган китап фестивалендә алынды.



МАХСУС ПРОЕКТ

— 12нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

Леонид Якунин, ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе, июнь аенда үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

Леонид Александровичның хезмәт биографиясе башта Түбән Камада, аннары Казанда нефть-химия җитештерүләрендә аппаратчы вазыйфасыннан башлана. Казанда ул смена башлыгы һәм «Оргсинтез» заводының профком рәисе дәрәҗәсенә күтәрелә. Соңрак юбилярның хезмәт юлы финанс-икътисад ягына борылыш ясый – ул РФ Хөкүмәте каршындагы финанс академиясен тәмамлый, Россия Федераль салым хезмәтенең ТР буенча Идарәсе җитәкчесе урынбасары булып эшли. 2014 елда, ТР Дәүләт Советы депутаты итеп сайлангач, Леонид Александрович анда иң мөһим комитетларның берсенә җитәкчелек итә башлый.

Леонид Якунин – ТР һәм РФнең атказанган икътисадчысы.

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт» ААҖ директоры, V чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты

Эшкә җаваплы мөнәсәбәт үрнәге

Хөрмәтле Леонид Александрович! Юбилеегыз белән ихлас котлауларымны кабул итегез!

Сезнең тормыш юлыгыз – зур җаваплылыкка ия булган нык ихтыярлы һәм көчле рухлы кеше юлы ул. Сезнең компетентлы, инициативалы булуыгыз һәм тулысынча бирелеп эшли белүегез уңышлы һөнәри һәм сәяси эшчәнлегегезнең шарты булып тора. Эшкә дөрес мөнәсәбәт, оештыру таланты һәм алдан күрүчәнлегегез Сезгә һәрьяктан уйланылган карарлар кабул итәргә һәм республикабыз иминлеген күтәрүгә юнәлтелгән киң күләмле проектларны уңышлы рәвештә тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Чын күңелемнән Сезгә иң кыю идеяләрегез һәм планнарыгызның тормышка ашуын, ныклы сәламәтлек, бәхет һәм озак еллар дәвамында уңышлар телим! Коллегаларыгыз, якыннарыгыз һәм туганнарыгызның күңел җылысы, ярдәме һәрвакыт Сезнең тормышыгызны тулыландырып торсын, ә уңыш барлык эшләрегездә юлдаш булсын!

АЛЕКСЕЕВСК ПАТРИОТЫ

Владимир Козонков, Алексеевск муниципаль районы башлыгы, июнь аенда үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Владимир Константинович менә 12 ел инде Алексеевск районы белән җитәкчелек итә. Уңышлы эшчәнлегенең нәтиҗәләре дә күренеп тора: аңа тапшырылган территориядә хуҗалык итүнең күп төрләрен берләштергән оешмалардан торган югары үсешле агросәнәгать комплексы да, шактый саллы төзелеш секторы да, ТТПнда 30 процентлы өлеше булган кече һәм урта эшмәкәрлек тә бар. Һәм шунысы да бик мөһим: монда милләтара татулык һәм дуслык хөкем сөрә. Районлагы әлеге ышанычлы позициянең сәбәбе шунда: Владимир Козонков гомере буе Алексеевск җирендә хезмәт итә һәм аны энәсеннән җебенә кадәр белә.

Владимир Козонковның казанышлары «Намуслы хезмәт өчен» һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре белән билгеләп үтелгән.

Владимир Козонков

Алексей Демидов,
Татарстан Республикасының Хисап палатасы рәисе

Туган якның уңышы хакына

Хөрмәтле Владимир Константинович! Минем өчен Сезне 60 яшьлегегез белән котлау бик кадерле вакыйга!

Без Сезнең белән күп еллар элек Алексеевск районы дип аталган искиткеч матур җирдә танышкан идек. Бу якта муллык булдыру эшенә Сез бик күп елларыгызны багышладыгыз.

Сезнең үзегез туган, укыган, хезмәт һәм тормыш тәҗрибәсе туплаган кече ватаныгызны ничек кадерләвегез турында ишетеп кенә белмим. Анда элеккечә үк Сезнең ихтирамга лаек әниегез Клавдия Емельяновна яши, аңа хөрмәт белән баш иям һәм озын гомер телим!

Күптән дәвам иткән танышлыгыбыз елларында мин Сезне сәнәгать һәм кешеләр язмышы турында чын күңелдән кайгыртучы белгеч, җитәкче буларак кына түгел, ә туган ягына эш сәгатьләрен генә түгел, бөтен буш вакытын да багышлаучы ышанычлы, ихлас, ачык кеше буларак та белдем. Аучылык, Камада балык тоту, учак янында гитарада уйнап җырлау – йөрәгенә бик тә якын булган һәм аңа җаны-тәне белән бирелгән үз туфрагында яшәгән кешенең гади дә, үзенә лаеклы да мавыгулары бу. Әлеге сыйфатларыгызга кушып, Сез әле менә дигән гаилә башлыгы, искиткеч ике кыз тәрбияләп үстергән бәхетле эти дә.

Мин туган ягыгызның Сезнең өчен һәрвакыт чиксез энергия һәм рухи көч чыганагы булуын, армый-талмый эшләвегезнең үзегезгә йөзләтә кайтуын телим. Алга таба да шундый ук тырышлык һәм илһам белән туган ягыгыз һәм Татарстан Республикасы иминлеге хакына хезмәт итәрсез, дип ышанам. Сезгә һәрвакыт бәхет, уңыш, сәламәтлек, иминлек, якыннарыгызның һәм фикердәшләрегезнең хуплавы юлдаш булсын! Алга атлавыгызны дәвам итегез, юлыгызда киртәләр һәм каршылыклар азрак булсын!

PRESSA.RU

Энгель Нәвәпович Фәттахов, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Мәгариф һәм фән министры, июньдә үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Асия Тимирясова,
В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университет (ИЭУП) ректоры

Күркәм хезмәтегездә уңышлар юлдаш булсын!

Хөрмәтле Энгель Нәвәпович! 55 яшьлек юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын җитәкли башлавыгызга әле чагыштырмача аз вакыт узса да, Татарстан мәгарифе системасының барлык өлкәләрендә Сезнең җитәкчелек астында шактый күп проектлар тормышка ашырылды. Аларның һәркайсы инновацион сыйфатка ия, һәм һәркайсын күркәм максат – укыту һәм тәрбиянең сыйфатын күтәрүгә омтылыш берләштерә. Татарстанның Россия мәгариф системасы лидерлары арасында булуы Сезнең балалар һәм яшьләрнең киләчәген кайгыртуыгыз нәтиҗәсе дә ул.

Зур абруйга ия булуыгыз һәм эшкә зирәк мөнәсәбәтегез Татарстанның укыту һәм тәрбия киңлекләре мәнфәгатьләрен саклап калуда һәрвакытта да мөһим роль уйнады һәм киләчәктә дә шулай булыр, дип ышанам. Бүген безнең университет алдынгы белем бирү технологияләрен эшкәртү һәм тормышка ашыруда федераль дәрәҗәдәге җитди фәнни-белем бирү үзәге һәм эксперименталь мәйданчык булып танылган икән, монда Сезнең дә хезмәтегез бәяләп бетергесез.

Хөрмәтле Энгель Нәвәпович! Сез педагогика идеалларына тугрылык һәм үсеп килүче яшь буынның һәм аларның остазларының язмышы өчен зур җаваплылык хисе тоеп эш итәсез. Киләчәкне һәрчак күздә тотып һәм аны узып эшләү, стратегик уйлый һәм максатка ирешү өчен үз артыгыздан ияртә белү кебек гаҗәеп сыйфатларга да ия Сез. Белем һәм тәрбия бирү системасының комплекслы үсешенә зур шәхси өлеш кертүегез өчен рәхмәт Сезгә. Оештыру сәләтегез һәм иҗади якын килә белүегез Татарстан мәгарифе һәм фәненең яңа мөмкинлекләрен ачуга озак еллар дәвамында ярдәм итәр, дип ышанам.

В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП) студентлары һәм хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне туган көнегез белән тәбрик итәм! Барлык планнарыгыз тормышка ашсын, киләчәгегез зур казанышларга, күркәм уңышларга һәм халык файдасы өчен башкарылган эшләрдән чиксез канәгатьләнү хисенә бай булсын! Алга таба да сүнмәс яшәү дәртен саклап калуыгызны, иминлек, нык сәламәтлек һәм озын гомер телим!

Реклама

Юсуп Якубов,
Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе ректоры

Киң колачлы уртак проектлар һәм уңышлы тормышка ашырылган идеяләр күбрәк булсын!

Хөрмәтле Энгель Нәвәпович! Идел буе спорт һәм туризм академиясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 55 яшьлегегез белән котлыйм!

Бүгенге мәгариф – Татарстан үсешенең стратегик юнәлешләреннән берсе. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы республикада юкка гына иң мөһим тармакларның берсе булып исәпләнми. Бай җитәкчелек тәҗрибәгез һәм шәхси сыйфатларыгыз әлеге тармак җитди үзгәрешләр кичергән шактый авыр чорда аның белән җитәкчелек итәргә мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән Идел буе спорт һәм туризм академиясе мәйданчыгында күпсанлы белем бирү проектлары тормышка ашырыла. Укучыларның халыкара, бөтенроссия һәм республика предмет олимпиадалары, студентларның һәм яшьләрнең белем өлкәсендәге форумнары, фәнни конференцияләре уздырыла. Үзара бәйләнешләребез инде җимешләрен дә бирә. Безнең төбәк, белем бирү мәйданчыгы буларак, талантлы һәм перспективалы яшьләрне торган саен күбрәк җәлеп итә.

Сезгә алга таба да уңышлар, озак елларга иминлек һәм сәламәтлек телим. Масштаблы уртак проектлар һәм уңышлы тормышка ашырылган идеяләр күбрәк булсын! Ә безнең мәгариф өлкәсендәге бергәлек һәм алдынгы уртак тәҗрибә Татарстанда гына түгел, аннан читтә яшәүче укучыларга һәм студентларга да файдалы булачак.

Реклама

ИҖАДИ ХЕЗМӘТ ТӘҖРИБӘСЕ

Азат Нигъмәтҗанов

Азат НИГЪМӘТҖАНОВ, Казан башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, июньдә үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Азат Робертович башкарма комитетта тыйнак кына «шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре» дип аталучы юнәлешкә күзәтчелек итә. Чынлыкта шәһәр хуҗалыгы җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләнгән җаваплылык зонасы очсыз-кырыйсыз – ул төзелеш, архитектура, шәһәр төзелешен хәл итү, торак программалары, метрополитен һ. б. эшләрне үз эченә ала. Һәм аларны башкарырга юбилярга иң әүвәл аның төзелеш эшендә мастердан алып эре компания җитәкчесенә кадәр булган зур тәҗрибәсе ярдәм итә.

Азат Нигъмәтҗановның хезмәтләре «Казанның мең еллыгы хөрмәтенә» медале һәм «ТРның атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем белән билгеләп үтелгән.

Марат Дәүләтбаев,
«Татгазстрой» ЯАҖ
генераль директоры

Уңышның сере – профессиональлектә һәм хезмәт сөючәнлектә

Хөрмәтле Азат Робертович! «Татгазстрой» ЯАҖ һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 55 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Сез һәммә нәрсәгә дә үз көчегез белән ирештегез. Профессиональлек, хезмәт сөючәнлек һәм намуслылык – тормыш юлыгызның нигезендә әнә шулар ята. ТР Газлаштыру программасы елларын коллектив хезмәтчәннәре бүген дә аерым бер җылылык белән искә ала һәм ул чорда сезнең янәшәдә булулары белән горурлана. Профессиональ үсеш баскычларын Сез «Татгазстрой» ЯАҖ коллективының күз алдында уздыгыз һәм шактый зур уңышларга ирештегез. Бүген исә, гаять мөһим мәсьәләләрне хәл итә барып, тулы бер шәһәр төзелеше комплексын җитәклисез.

Сезгә барлык профессиональ идеяләрегезнең һәм ниятләрегезнең тормышка ашуын, күңел күтәренкелеге, гаилә иминлеге, Казаныбыз иминлеге хакына хезмәт шатлыклары телибез!

PRESSA.RU

Рәис Нургали улы Миңнеханов, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгы, июньдә үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Рамил Нотфуллин,
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы

Барлык эшләрегез һәм башлангычларыгыз кешеләрнең рәхмәте булып әйләнеп кайтсын!

Хөрмәтле Рәис Нургалиевич, юбилей көнегездә районыбызның башкарма комитеты, барлык балтачлылар һәм үз исемемнән Сезгә тирән ихтирам хисләребезне һәм иң изге теләкләребезне җиткерә алуыбызга ихлас шатбыз!

Алга таба да барлык эшләрегезгә һәм башлангычларыгызга уңыш юлдаш булуын, яңа биеклекләр яулавыгызны һәм һәр көнне якыннарыгызның җылысын, мәхәббәтен тоеп яшәвегезне телим!

Сезнең бөтен гомерегез туган җирегез Саба районы белән тыгыз бәйләнгән: хезмәт юлыгызны урман хәзерләү мастеры булып башлагансыз, урман сәнәгатенең күп кенә җитәкче урыннарында эшләгәнсез һәм бүген муниципаль район башлыгы постын билисез. Кайда гына булсагыз да, үзегезне миһербанлы, һәр эштә башлап йөрүче, максатына ирешә белүче, кешеләрне үз артыгыздан ияртә һәм аларның хезмәтен оештыра алучы кеше итеп күрсәттегез, барлык тармакларга да заманча алдынгы технологияләрне кыю рәвештә керттегез.

Нәкъ менә Сезнең зирәк җитәкчелегегез һәм һәрдаим камиллеккә омтылуыгыз нәтиҗәсендә районда сәламәтлек, белем бирү, агросәнәгать комплексы һәм торак төзелеше өлкәләрендәге милли проектларны тормышка ашыру буенча уңышлы эш алып барыла.

Сезнең җитәкчелек чорында районның социаль-икътисадый үсешендә зур үзгәрешләр күзәтелде, халыкның яхшырак тормышта яшәве дә елдан-ел сизелерлек була бара.

Без, балтачлылар, Сезнең авыл җирлегендә мул тормыш чынбарлыгын һәм үсеп килүче яшь буын өчен яңа мөмкинлекләрне бергәләп төзергә омтылуыгызны хуплыйбыз.

Рәис Нургалиевич, һәрнәрсәгә уңай караштa торуыгызны, үз көчегезгә ышануыгызны киләчәктә дә саклап калырсыз һәм һәрвакыт шулай яшь күңелле булырсыз, дип ышанам. Якташларыгыз һәм бөтен Татарстан иминлеге хакына яңа проектларыгыз, билгеләнгән планнарыгыз һәм хыялларыгыз чынга ашсын.

Ныклы сәламәтлек, бәхет, һәрнәрсәдә иминлек һәм уңыш телим!

Васыйл Гыйззәтуллин,
«Саба урман хуҗалыгы» ДКУ урманчысы – җитәкчесе

Саба җиренең чәчәк атуы хакына

Хөрмәтле Рәис Нургалиевич! Саба урман хуҗалыгы коллективы һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихластан тәбрик итәм!

Бүген Саба районы – табигатьнең кеше тарафыннан саклана торган гаҗәеп матур почмагы гына түгел, безгә, төп сабалыларга, аның Татарстан Республикасының уңышлы һәм динамик үсеш кичерүче территориясе икәнен аңлау аеруча рәхәтлек бирә.

Күп еллар дәвамында уңышлы эшләп килү Сезнең исем белән бәйле. Сезнең тырышлык нәтиҗәсендә муниципаль хакимият һәм районыбыз предприятиеләре һәм оешмалары уртак җиңүне күздә тоткан хезмәттәшлек режимында яши. Район хакимияте үзеннән торган бөтен нәрсәне дә эшли. Ул һәрвакыт бизнес белән уртак телгә килергә әзер, аның үсеше белән даими кызыксынып тора һәм килеп туган мәсьәләләрне оператив төстә хәл итә. Районда сәнәгать мәйданчыклары, кече һәм урта эшмәкәрлек, авылда хуҗалык итүнең кече формалары уңышлы үсә. Болар барысы да төп максатка – сабалылар тормышының дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә.

Сезгә нык сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс көч һәм энергия, барлык кызыклы яңа проектларыгызның уңышлы рәвештә тормышка ашуын, бәхет, гаилә иминлеге телим!

Гомерегез – бәхетле, бәхетегез гомерле булсын!



Реклама

Илдус Зарипов,
ТР Теләче муниципаль районы башлыгы

Исеме зур хәрефтән язылырга тиешле җитәкче

Рәис Нургалиевич, юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Сез – исеме зур хәрефтән языла торган Җитәкче, һәм бу – тормышыгызның төп нигезе. Профессиональлек, кешеләрне үз артыгыздан ияртә, аларны туплый һәм фикердәшләрегез итә белү – абруегызның төп чыганаклары әнә шулар. Озак еллар Саба районында эшләү нәтиҗәсендә күптән инде Сез аның халкы өчен җирнең чын хуҗасына әйләндегез. Җир – районның төп байлыгы. Авыл хуҗалыгы үсешенә зур игътибар бирүегез дә гаять әһәмиятле, чөнки район үсешенең нигезендә беренче чиратта әнә шул ята. Авыл хуҗалыгы эшчәннәрен борчый торган проблемаларны бөтен нечкәлекләре белән белгән, авыр хезмәтләрен хөрмәт иткән хәлдә, Сез аларның алдынгы башлангычларын хуплыйсыз, мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә булышасыз.

Безнең районнарны җылы күршелек мөнәсәбәтләре берләштерә. Без Саба җирендәге вакыйгаларны игътибар белән күзәтеп барабыз, уңышларыгыз белән горурланабыз һәм Сезгә сокланабыз. Моңа зур шатлык белән карыйбыз: күрше җирендә бар да яхшы була икән, димәк, без дә үзебезне бәхетле сизә алабыз. Халык тормышының сыйфатын яхшырту өчен булдыра алганның бөтенесен дә эшләвегез тирән ихтирамга лаек.

Минем иң төп теләгем шул: барлык игелекле эшләрегез Сезгә халыкның рәхмәте булып әйләнеп кайтсын. Яхшылык беркайчан да онытылмый. Кеше җаны-тәне белән үз эшенә, халкына бирелгән, аның бүгенгесе һәм киләчәгенә битараф түгел икән, ул чакта нәтиҗә дә уңай булачак. Гомер буе һәр сукмагы, һәр чишмәсе кадерле булган туган районыңда эшләү бер яктан – бик рәхәт, икенче яктан бик тә җаваплы, дип уйлыйм.

Сез җәй башында – табигать, уянып, бөтен көчләрен һәм җаннарын биреп эшләгән кешеләргә җавап йөзеннән үзенең байлыкларын юмарт өләшергә әзерләнгәндә тугансыз. Холкыгыз максатка омтылучанлык, эшкә дәрт-сәләт кебек сыйфатлар белән аерылып тора. Республика районнарында Сезне таныйлар һәм хаклы рәвештә җаваплы, алдан күрә белүче җитәкче, профессионал-фикердәшләр командасын тупларга һәм аны югары нәтиҗәләргә юнәлдерергә сәләтле яхшы белгеч буларак бәялиләр. Барлык бу шәхси сыйфатларыгыз бүген дә күзгә күренеп тора. Кешеләрне, үзегез туып-үскән районның актив яңарышын кайгырту, якташларыгызның мөһим проблемаларын хәл итү – профессиональ тормышыгызда төп юнәлешләр. Хезмәт яшендәгеләргә дә, пенсионерларга һәм балаларга да Сез тигез дәрәҗәдә игътибар бирәсез.

Хөрмәтле Рәис Нургалиевич! Бу күркәм бәйрәмегездә Сезгә алга таба да зур хезмәт уңышлары, барлык планнарыгызның тормышка ашуын теләргә рөхсәт итегез. Яңа креатив проектларны гамәлгә ашырырга, үзегез җитәкләгән Саба районы халкына тагын да мулрак тормышта яшәргә насыйп булсын!

Кешенең күңеле белән яшь калуы – яхшы күренеш. Күңел күтәренкелегегезне беркайчан да җуймагыз, йортыгызда бәхет һәм бәрәкәт булсын! Куйган максатларыгызга ирешү юлында бервакытта да тукталып калмавыгызны һәм һәрвакыт, һәр эштә иң яхшы нәтиҗәләргә генә ирешүегезне телим. Үзегезгә һәм якыннарыгызга иминлек, ныклы сәламәтлек һәм яхшы кәеф юлдаш булсын! Юбилеегыз белән!

Реклама

PRESSA.RU

Нургаян Тимергалиев,
«Саба районы ТКХның Шәмәрдән Күптармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖ генераль директоры

Сабалылар район уңышлары белән горурлана

Хөрмәтле Рәис Нургалиевич!

Саба муниципаль районы Татарстан Республикасында күптән инде эшчәнлекнең төрле өлкәсендә әйдәп баручы булып танылды. Районның социаль тормыш, төзелеш һәм авыл хуҗалыгы, мәдәният һәм спорт өлкәләрендәге уңышлары сабалыларда туган яклары, хезмәтләренең матур нәтиҗәләре белән горурлану хисләре уята. Сүз дә юк, монда Сезнең зур хезмәтегез ята, Рәис Нургалиевич!

Хезмәт баскычының барлык басмаларын Сез этаплап үттегез һәм бөтен гомерегезне районга багышладыгыз дип, һич арттырусыз әйтергә мөмкин. 1999 елда Саба районы хакимияте башлыгы постына килеп, менә инде 17 ел дәвамында туган ягыбызның гади халкы мәнфәгатьләре сагында торасыз. Һәм бу, һичшиксез, алдан күрүчәнлек һәм фикердәшләр командасы туплый белү сәләтен таләп итә.

Сезгә дөрес карарлар кабул итә, стратегияне һәм алга таба хәрәкәт итү тактикасын билгели белү хас. Грамоталы җитәкчелек итү, югары профессиональлек, җаваплылык һәм эшкә сәләтлелек, таләпчәнлек һәм куелган максатларга ирешә белү холкыгызның аерылгысыз өлеше булып тора.

«Саба районы ТКХның Шәмәрдән Күптармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖнең күпсанлы хезмәт коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне ихлас күңелдән 55 яшьлегегез белән котлыйм! Һәрвакыт уңышлар юлдаш булсын, ә ышанычлы дусларыгызның ярдәме озын хезмәт юлыгызда маяк булып торсын. Сәламәтлек, шәхси бәхет һәм якыннарыгыз белән аңлашып яшәвегезне телим!

Реклама

Бисмилләһир-Рахманир – Рәхим!
Әссәламе-галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!
Кадерле мөселман кардәшләр!

Сезне барлык мөселманнар өчен изге булган Рамазан ае һәм алда көтә торган Ураза бәйрәме белән котлыйбыз. Бу изге ай мөэмин-мөселманнарның рухи камиллеккә, иман ныклыгына, мәрхәмәт һәм шәфкатьлелеккә һәм ислам традицияләрен ихтирам итүгә омтылышын гәүдәләндерә.

Мәгълүм булганча, хаҗ ислам динендә һәр мөселман үтәргә омтыла торган баганаларның берсе. Кызганыч, хаҗ оештыру белән бәйле чыгымнар аркасында, күп кенә мөэмин-мөселман кешесе аны үти алмый.

Хаҗ кылырга ниятләгән гади мөселман кешеләренең финанс мөмкинлекләрен чит илләрнең уңай тәҗрибәсе буенча җиңеләйтү максатыннан, акча җыю системасын искә алып, Россия мөселманнарының Үзәк Диния Нәзарәте һәм Ислам финанслар йорты мондый системаны Россиядә куллану мөмкинлеге бирә торган Россия мөселманнарының «Хәйрия Хаҗ Фонды» дигән Бердәм хаҗ үзәген булдырды. Фонд барлык хаҗ кылучылар өчен Аллаһ кануннарына яраклаштырып, хаҗ кылуның бердәм стандартын эшләде.

Россия мөселманнарының «Хәйрия Хаҗ Фонды» Бердәм хаҗ үзәге хаҗның коммерциячел булмаган оештыручысы булып санала, һәм ул Россия мөселманнарының хаҗ оештыру буенча Советында аккредитацияләнде. Ташламалы турлар «Хәйрия Хаҗ Фонды»ның «Ислам финанслар йорты» ААҖ белән партнерлык программалары, шулай ук аз керемле мөселманнар өчен шәхси хәйрия ярдәме хисабына финанслана. Фонд коллективы даими рәвештә чит илләрнең һәм үзебездәге югары дини уку йортларында әзерлек үтә, алар анда бердәм стандарт дәрәҗәсендәге хезмәтләндерүче персонал квалификациясен ала. Без сезнең һәм гаиләгезнең Аллаһ йортына сәфәре уңайлы һәм хәлдән килердәй булсын өчен барысын да эшлибез. Сезгә иминлек, Аллаһ рәхмәте һәм бәрәкәт иңсен!

Хаҗ Фонды дирекциясе.

Хаҗ 120 мең сумнан башлана!

«Хаҗ һәм Гомрәне Аллаһ ризалыгы өчен кылыгыз»

(«Әл–Бәкарә» сүрәсе, 196нчы аять).

БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ХАДЖ ФОНД
ALL RUSSIAN CHARITY HAJJ FOUNDATION

Хаҗ Фонды

Хаҗ кылу үсешенә ярдәм итүнең Бөтенроссия фонды

Яр Чаллыдагы вәкиллек
8-8552-912-848,
8-953-482-75-50

Россия Хаҗ-миссиясенең «кайнар линиясе» телефоны
8-800-555-15-15
Шалтырату бушлай

www.hajjfund.ru

Реклама

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ «ТРАПЕЗА» КОМПАНИЯСЕ БАЛАЛАРНЫ ЯКЛАУ КӨНЕНДӘ КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘР – ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ МАРТ САНЫ ГЕРОЙЛАРЫНА ТӘМ-ТОМНАР БҮЛӘК ИТТЕ.

PRESSA.RU

Татарстан – яхшы кешеләргә генә түгел, гаҗәеп кызыклы риваятьләргә дә бай төбәк. Кайсы гына районга барып төшмә, үз якларына хас төгәллекләр белән тулы борынгы хикәятләрне сөйләп бирүче барысыннан да хәбәрдар кеше һәрвакыт табыла. «Татарстан» журналы республикабыз риваятьләрен туплады һәм бу саннан алар белән сезне дә таныштыра башлаячак.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: КЫЗЛАР ТАВЫ

Аксубай районының Татар Сөнчәләсе авылыннан төньяктарак зур гына калкулык бар. Җирле халык өчен ул изге урын – аны «Кызлар тавы» дип йөртәләр. Авыл кешеләре, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр, бирегә дога кылырга, Ходайдан үзләрен ярлыкавын сорарга йөри. Авыл әбиләре әлеге тауның башында җирле риваять каһарманнары – кызлар җирләнгән, шуңа күрә ул урын изге, дип сөйлиләр. Араларында иң чибәре һәм фаҗигалерәк язмышка тарыганы бай кызы булган, ди.

...Бу хәл бик күптән була. Комсыз бай үзенең кызын икенче бер байга кияүгә бирергә ниятли. (Була бит шундый аталар!) Әмма кызы аңа буйсынырга теләми:

– Яратмаган кешегә чыкмыйм! – ди.

Ярсыган ата кызын кияүгә аның ризалыгыннан башка гына бирергә карар кыла. Моны ишеткәч, кыз шул ук төндә хезмәтче кызлары белән туган йортыннан качып китә. Ә ачуы кабарган бай шунда ук хезмәтчеләрен аны эзләргә чыгарып җибәрә.

Кызлар куе урманда, иркен болыннарда озак качып яшиләр. Шактый вакыттан соң, Сөлчә елгасының күләгәле ярлары буена килеп чыгалар.

– Моннан да матуррак җирне таба алмабыз. Биредә безнең яңа йортыбыз булачак! – ди бай кызы.

Озакламый Сөлчә ярында зур таш йортның стеналары калкып чыга. Күрәсең, борынгы заманда кызлар да төзү эшләренең серләрен белә торган булган. Яңа урында алар бик дус яшиләр, бар нәрсәне тигез бүлешәләр. «Кызлар йорты»нда яшәүче качкыннарга авыр язмышларын үзгәртергә теләгән башка кызлар да килеп кушыла башлый.

Йортларына берничә тапкыр юлбасарлар һөҗүм итә, әмма кызлар аларга да каршы тора ала – нәкъ амазонкалар кебек! Тик дошманнары торган саен күбәя бара (шулай булмыйча, кызлар бик чибәрләр бит), шуңа күрә алардан саклану өчен ныгытма төзергә керешәләр. Ул чакта аларның авыллары кечкенә генә шәһәргә әйләнгән була инде. Кызлар зур ташлардан дивар торгызалар, аны туфрак өеме белән әйләндереп алалар. Озак та үтми, дошман һөҗүмнәренә каршы торырлык ныгытма әзер була.

Ныгытманың даны бөтен тирә-юньгә тарала. Хәбәр качкын кызның атасына да килеп ирешә. «Кызлар йорты» диварлары янына килеп, ул кызына ата-анасы ихтыярына буйсынырга, ә ныгытманы үзенә бирергә боера.

– Мин дусларыма хыянәт итмим, иркемне һәм намусымны сатмыйм! Гомеремнең азагына кадәр үземә үзем хуҗа булып яшисем килә! – дип җавап бирә кыз.

Бай хезмәтчеләренә ныгытманы камап алырга боера.

– Хәзер үк бирел, юкса, сугышчыларыма сине көч белән буйсындырырга кушачакмын! – ди ул.

Кыз кабат баш тарта. Һөҗүм башлана. Кызлар гаҗәеп дәрәҗәдә кыю һәм җитез булсалар да, байның кораллы гаскәренә каршы торырга көчләре җитми. Аларны әсирлеккә алалар. Күп кенә сугышчыларын югалтудан һәм кызының баш имәвеннән ярсыган бай хезмәтчеләренә ныгытма эчендә зур чокыр казырга һәм кызларны шунда ташлап, тереләй күмәргә боера. Шулай эшлиләр дә... Ә «Кызлар йорты»н нигезенә кадәр җимереп бетерәләр – янәсе, башкаларга да сабак булсын! Диварлар ишелеп төшеп, кызларның каберен каплый...

Тора-бара бу урынны «Кызлар тавы» дип атап йөртә башлыйлар. Ә үз иреге хакына һәлак булган кызларның батырлыклары турындагы хикәят бүген дә яши.

Риваятьне Аксубайның туган якны өйрәнү музее директоры Әлфия Нурәхмәтова сөйләде

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН БУ
САННЫ ЭШЛӘДЕЛӘР:

– «ЯШЬ ПРОФЕССИОНАЛЛАР» ЧЕМПИОНАТЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘР

– VIII ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ САММИТТА КАТНАШУЧЫЛАР

– ЯР ЧАЛЛЫ ҺӘМ ПИТРӘЧНЕҢ ЯШЬ СПОРТЧЫЛАРЫ

– РЕСПУБЛИКА СУЛЫКЛАРЫ ЯЗМЫШЫНА БИТАРАФ БУЛМАГАН ЧИСТАЙЛЫЛАР

– РУС ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШҮЧЕ ГАЛИМНӘРНЕҢ ХАЛЫКАРА АССОЦИАЦИЯСЕ ВӘКИЛЛӘРЕ

– ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫ

– ТАТАРСТАННЫҢ КИТАП ЯРАТУЧЫ ГАИЛӘЛӘРЕ

– КАМА ТАМАГЫ КЕЛӘНЧЕ АВЫЛЫННАН ГОМӘРОВЛАР ГАИЛӘСЕ

– ЯТИМ ҺӘМ АВЫРУ БАЛАЛАР ЯЗМЫШЫНА БАГЫШЛАНГАН «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛДӘ» КАТНАШУЧЫЛАР

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

АЛАР «ТАТАРСТАН»
ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛДЫЛАР

ӘЙ СЕЗ?

Язылу кампаниясе
25 июньгә кадәр озайтылды!

Реклама. 16+